www.madanizhomga.ru

Мәдәни җомга

1995 елның июленнән башлап чыга

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 50 (1415) 23 декабрь 2022 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:
madani_zhomga madanizhomga
madani_zhomga

2

Башкортстанда милли горурлык хисен уяту, тел-милләтне саклау юнәлешендә алып барылган эшләрдән үрнәк һәм гыйбрәт алырга кирәк.

8

Узып барган 2022 елда күренекле галимнәр, әдипләр, мәдәният әһелләре арабыздан китте...

12

Рәссам, колакча чигү техникасын да актив торгызучы Әлфия Нурхәммәтова үз эшләрендә һәр татар күңеленә якын манзараларны сурәтләргә омтыла.

Гаярь аргамакта җилеп барган Үз җайдагын күтә Казан да!..

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Япониядә япон телендә язылган беренче татар теле дәреслеге басылып чыкты.
- Башкортстан Язучылар берлеге рәисе итеп 34 яшьлек язучы һәм журналист Айгиз Баймөхәммәтов сайланды.
- Чаллы язучысы һәм шагыйрә Әлфия Ситдыйкованың «КамАЗ» заводын төзүчеләр турындагы «Дөнья тәгәрмәче» повесте Төркиядә нәшер ителде.
- «Белем җәүһәрләре» татар интернет-проектлары бәйгесенең Гран-при бүләгенә – «Җәүһәрләрнең җәүһәре» исеменә «Шаян ТВ»телеканалының рәсми сайты лаек булды.
- Чуашия Республикасы Шыгырдан авылындагы «Мөслимә» мәчет-комплексында музей ачылды.
- Композитор, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Луиза Батыр-Болгари Россия мөселманнарының иң югары бүләге – «Әл-Фәхр» мактау ордены белән бүләкләнде.
- Түбән Кама театрында аның баш режиссеры, директоры Рөстәм Галиевнең «...Чаклар» («...Времена») китабы тәкъдим ителде.
- КФУның Милли мәдәният һәм мәгариф югары мәктәбе студенты Илзирә Галимбикова «Ел студенты – 2022» илкүләм бәйгесенең «Ел старостасы» номинациясендә җиңү яулады.
- Әтнә театры Кырлайдагы Г.Тукай Әдәби-мемориаль музей комплексында иммерсив экскурсия уздырды.
- КФУның Филология һәм мәдәнияттара багланышлар институтында «Заманча шрифт дизайны һәм каллиграфиянең этномәдәни тенденцияләре» дип исемләнгән күргәзмә-конференция үтте.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Илдар СӘГЪДӘТШИН, Татарстан китап нәшриятының генераль директоры:

«Элек телевизорны розетка янына барып кабыза идек бит, хәзер диванда яткан көе генә төймәгә басасы. Басма китапны кибеткә барып сатып алырга кирәк. Ә бу очракта аудиокитап булып, ул үзе өйгә килеп кергән. Балаларны мәктәпкә, бакчага илткәндә, машинада мин ешрак «Татар халык әкиятләре»н куям. Тыңлап барырга мәҗбүрләр. Машинадан төшеп китә алмый бит бала... Тиктормас бала-чага өчен китап пропагандалауның бер дигән чарасы инде бу».

СЫНАМЫШЛАР

25 декабрьдә агачларга бәс сарса, алдагы елда иген уңар ● 25 декабрьдә иртән тын булып, йомшак кына кар яуса, ашлык уңар; әгәр кар көндез яуса, чикләвек күп булыр; җылы һәм буранлы булса, җәй салкын килер ● 25-27 декабрьдә тамчы тамса, 29 июньдә кырау төшәр; кыяр, тары уңмас, карабодайга килешер.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **8 сәгать 12 минутта** чыкты, һәм ул **15 сәгать 12 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **7 сәгать 00 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **5 минутка озыначак** һәм киләсе җомгада, ягъни **30 декабрьдә 7 сәгать 05 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

23 декабрь – язучы Газиз Фазлый улы Мөхәммәтшинның тууына 90 ел (1932–1972).

24 декабрь – тел галиме, фольклорчы, дәреслекләр авторы Хуҗа Габделбәдигъ улы Бәдигыйнең тууына 135 ел (1887–1940);

– актёр, Татарстанның халык артисты Дэллюс Гали улы Ильясовның тууына 100 ел (1922–1981).

25 декабрь – опера җырчысы, Башкортстанның, Россиянең халык артисты, Ленин ордены кавалеры Габдрахман Сөләйман улы Хәбибуллинның тууына 120 ел (1902–1969);

– Татарстанның халык язучысы, Г.Тукай бүләге иясе Мөсәгыйть Мөдәррис улы Хәбибуллинның тууына 95 ел (1927–2019).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Декабрьнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көннәрне исегезгә төшерәбез: 25-28 декабрь.**

* * *

Гадәттә, яңа айдан айның беренче чирегенә кадәр **(23-30 декабрь)** организм кысылуга бара. Мондый көннәрдә үз-үзеңә физик йөкләмә бирү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: **25 октябрьдән 31 декабрьгә кадәр** бөер һәм бәвел куыгы актив булучан. Шушы вакыт аралыгында аларны ныгыту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

Бүген җомәдел әүвәл аеның 29 нчы көне

ҖАН АВАЗЫ

Вахит ИМАМОВ

БАШКОРТЛАРДА МИЛЛИ РУХ ИСӘН

Башкортстанга соңгы ике ел эчендә ун мәртәбә сәяхәт ясадык, андагы 40 районны манзара кылып чыктык. Әнкәй яклап туганнарым гомер буе Уфа каласында яшәгәнгә күрә, шәхсән үзем ут күршеләр башкаласын 50 ел дәвамында күреп беләм. Сәяхәт саен Салават Юлаев һәйкәле, телевидение бинасы, Башкорт дәүләт университеты, күршеләр һич тә кирәкмәскә күккә чөя торган Халыклар дуслыгы монументы янына, элек Ленин исеме белән аталган ял бакчасына бармый калмый идем. Уфада сәүдәгәрләр моннан ике гасыр элек үк төзегән мәһабәт сарайлар да, татар байлары кәрниз-фронтоннарын челтәрләп бизәгән агач йортлар да исән, андагы әллә ничә урам XX гасыр башын хәтерләтеп, әле дә үзенә тартып тора. Мондый борынгылык һәм милли йөзне тагын Алабуга, Бәләбәй, Бөре, Белорет, Тубыл, Әстерхан, Кырымдагы Судак калаларының аерым бистәләре генә саклап кала алды, ни кызганыч, безнең Казан архитектура ягыннан милли йөзен күптән җуйды инде.

Соңгы 30 ел эчендә Башкортстанда булып узган яңарышлар гаҗәеп сокландыра. Барча республиканы колачка алып булмас, аерым районнарга, аларда калыккан һәйкәлләргә күз йөгертик әле.

Атаклы Салават исемен йөртүче район ук башлыйк. Район үзәге булган Олы Малаязда, авылның иң үзәгендәге иркен бер урында Салаватның музей-комплексын булдырганнар. Өч катлы мәһабәт, зур сарай, аның каршындагы мәйданда каһарман һәйкәле, тирә-юньдә Урал тауларыннан кайтарып утыртылган дистәләгән төрле сирәк агач, периметр буйлап гаҗәеп рәшәткәләр. Музей дигәннәре монда гына тәмамланмый, кайнар теләк белдергән сәяхәтчеләрне 20 чакрымдагы Салават мәгарәсенә дә алып китә. Анда 1774 елның көзендә Салават качып яткан кыя эчендәге, озынлыгы белән 91 метрга сузылган таш мәгарәне генә түгел, гүзәллеге белән ихтыярсыз рәвештә һәркемне гашыйк итәрдәй Йөрүзән елгасы, Урал урманнары, алар эчендәге абагаларны күреп сокланасың. Шушы мәгарә өстендәге яланда елына дистәләрчә тапкыр чаңгыда һәм велосипедта «Салават бәйгеләре», мәгарәдән кул сузымындагы чишмә янында «Башкортстан гүзәле» бәйгесенә чыккан кызлар арасында коянтәләп су ташу конкурсы, ә Малаяздагы музей мәйданында ел дәвамында мәктәп укучылары арасында төрле олимпиада һәм фестивальләр үткәрелә. Салаватны мәңгеләштерү һәм күккә чөюдә инде нindидер яңалык уйлап табу, «могез» чыгару да мөмкин түгел сыман иде, юк, әйгенәм, тагын бер сфера эзләп таптылар бит!

Менә хәзер теләсәк-теләмәсәк тә, без республика башлыгы Радий Хәбиров алдында баш иярגә мәҗбүр. Чыбык очын ничек кенә яшерергә маташмыйк, башкаларга үрнәк айдәманның үзеннән башлана шул.

Шушы башлык янына кайсыдыр идеолог кереп, Салаватның туган авылы Тәкәй урнашкан бер утчай төбәкнең 1939 елгы бүленеш вакытында Чиләбе өлкәсе мәйданына күчерелеп калуы турында хәбәр итә. Гамьсез башлык, мөгаен, моңа игътибар да биреп тормас, уч төбедәй мәйдан өчен көрәшеп йөрүне ваклану дип кенә санар иде. Әмма Хәбиров Тәкәй урнашкан төбәкне әүвәл шәхсән үзе барып бәяли. Әйләнә-тирәсен яшел таулар әйләндереп алган, уртадагы казанлыкны икегә бүлеп аккан инеш һәм чишмәләрне, терлек йөртү өчен гаҗәеп уңай яланнарны күреп, үзе дә таң кала. Аннары һич тә тарсынмыйча Чиләбе губернаторы янына чыгып китә, аны да үгетләп, шушы тау һәм яланлыкка алып килә. Күрше губернатор да чын хакыйкать белән сугарыла, күрәсең. Шуннан соң ике күрше өлкә башлыгы да тиешле кәгазьләр әзерләп Мәскәүгә юл ала, кырыкмаса-кырык чиновник кабинетларын айкап чыга һәм ахырда – элек Тәкәй авылы урнашкан төбәк Башкортстан республикасына кайтарып бирелә. Тиешле оешмалар заманча проектлар әзерли һәм республика башлыгының фәрманы да хасил була – Тәкәй авылы урынында С.Юлаевка багышланган яңа музей-комплекс төзергә! Ул фәлән йөз миллион сумга төшәчәк гигант төзелеш 2023 елның язында канат җәеп җибәрәчәк инде...

Башлык Р.Хәбировның шәхсән үзе башлаган икенче бер изгелеге – үзе татар булса да, Бөек Ватан сугышы чорында 112 нче Башкорт дивизиясен җитәкләгән Миннегали Шәйморатов данын мәңгеләштерү. Аның чишмә башы белән Татарстанда яшәүчеләр дә беркадәр хәбәрдардыр. Р.Хәбиров шәхсән үзе Мәскәү юлларын таптап, 1920 елның 30 мартында М.Шәйморатовка Россия Герое дигән исем бирдерттерде. Бернечә айдан соң ук башлыкның «Уфа каласы үзәгендә Шәйморатов истәлегенә һәйкәл куелачак», дигән фәрманы дөнья күрде. Меңәрләгән-миллионлаган кеше аңа әзерлек эшләрен бөтенләй сизмәде дә. Бактың исә, Р.Хәбиров үз территориясеннән чыкмыйча, Урал тавында төзелеш өчен яраклы ак мәрмәр чыгару карьерын эзләтеп таптырган, ул гына да түгел, вертолет белән ике атнага бер мәртәбә очып, һәйкәл пантеонына җитәрлек мәрмәр әзерләү эшен күзәтеп торган, кирәк чакта ярдәм кулын да суза белгән икән.

Аннары без телевизор һәм интернет аша Шәйморатов һәйкәленең ачылу тантанасын күрдек. Шәйморатовның татар булган көе Башкорт дивизиясен җитәкләп дан алуы, анысыннан да бигрәк – аңа хөрмәт – татар халкын да, башкорт милләтен дә уяткан. Һәйкәлне ачу тантанасына Башкортстанның иң ерак районнарыннан да меңәрләгән халык автобус һәм поезд вагоннарына төяләшеп килгән. Башкорт дивизиясендә яу кылып йөргән каһарманнарның балалары, оныклары яңаклары буйлап аккан күз яшьләрен дә яшереп тормаган, һәммәсе дә, бердәм булып, Радий Хәбировка рәхмәт сүзләрен генә тәкърарлаган. Шулай итеп, Р.Хәбиров бер Шәйморатовка гына түгел, Бөек Ватан сугышын кичкән йөз меңнәрчә ветеранга, берочтан үзенә дә мәңгелек һәйкәл куйды. Бер генә як та үпкәләрлек түгел, ул милләте буенча татар булган, әмма башкорт республикасы өчен җан атып яшәгән Шәехзадә Бабич белән Мостай Кәримгә дә һәйкәлләр калкытты бит. Бердәм дуслык хакына, милли рух хакына. Шунысы гына кызганыч, Россиядә Радий Хәбиров кебек, милләтенең рухи сафлыгы, уяулыгы өчен җан аткан башка җитәкче юк...

Ноябрьдәге соңгы сәфәр вакытында Шәйморатов һәйкәлен үзебез барып күрдек. Йә Аллаһ, бу кадәр дә камил һәм заманча пантеон төзеп була икән! Мәйданның арткы ягын 12-13 метр биеклектәге мәрмәр колонналар түгәрәкләп алган, аларда башкорт гаскәренең яу кораллары, 112 нче Башкорт дивизиясендә каһарманлык кылып Советлар Союзы Герое исеменә лаек булган 78 яугир исемлеге. Ә уртада, шул ук 12-13 метр биеклегендәге пьедесталга куелган 15 метрлы Шәйморатов һәйкәле. Барчасы да ап-ак мәрмәрдән, ә Шәйморатов һәйкәле белән аның пьедесталына беркетелгән башкорт ыруларының символы булган кошлар, 1812 елгы Ватан сугышына китеп, Парижны яулаган башкорт полкларын, атаклы Салаватны, 1942-1943 елларда Шәйморатов канаты астында полк командирлары булган каһарманнарның фотосурәтләреннән күчереп ясалган портрет вә сыннар – ике йөз ел буена тутыкмаслык чиста бронзадан. Гади һәйкәл генә түгел, тулы комплекс. Шушы бөеклекне, мондый зур тарихны җанландыра белгән сынчы Сергей-Салават Щербаковка һәм, әлбәттә, шушы һәйкәлне аякка бастыру өчен бар егәрен биргән Радий Хәбировка рәхмәт!..

Гыйбрәтле сабагы шул: Шәйморатов Татарстан җирендә туган булса, бер гасыр вакыт узса да, без шанлы каһарманның сынын күрә алмас идек. Тәҗрибә зур: «Күк йөзенә күпме ялварсак та, аннан пилмән яумас», дигән төсле, үзебезнең хөкүмәт каршында 30 ел буена бил бөгәбез, әмма Казан каласында Олуг Мөхәммәт йә Алмыш хан, милләтпәрвәр Гаяз Исхакый йә Бөек Акмулла һәйкәленең калкып чыкканы юк. Хөкүмәт өчен Мәскәүгә озатылган салым кәрванында бер олау йә берәр тәгәрмәченең кимүе хәвефлерәк, димәк, милләтпәрвәр һәйкәл калыкмастыр...

(Дәвамы 5 нче биттә).

Килеп төртелгән тормыш

Киләчәк хакында фикер йөрткәндә, аңлашыла булыр, реаль тормыш чынбарлыгыннан чыгып эш итү лязем. Әлбәттә, сүзне иҗтимагый тормыштан башларга туры килә, чөнки ул шәхси яшәешне дә билгели, кайчакта хәтта аңа тәкъдири йогынты да ясый. Шул ук вакытта, мәсьәләнең икенче ягы да бар: кешенең шәхси яшәеше дә иҗтимагый тормышка тәэсир итә, шәхси үсеш билгеле бер биеклекне алгач, рухи вә матди үзгәрешләр җәмгыятьтә дә башлана. Чөнки иҗтимагый тормыш аерым шәхесләр яшәешенең тупланышлы чагылышы булып тора. Шәхеснең үсеше табигый рәвештә (илаһият кануннары буенча) барганда, җәмгыяви үсеш тә эзлекле бара, акрынлап һәм туктаусыз (эволюцион) үсеш кичерә һәм санның сыйфатка күчүе күзәтелә. Шәхеснең рухи вә матди үсеше ясалма киртәләр белән чикләнгән очракта, андый җәмгыятьтә тискәре потенциал туплана башлый һәм ул, билгеле бер бусаганы узгач, кискен (революцион) үзгәрешләргә дә китерә. Соңгысы тоталитар режимнарга хас һәм ул, гадәттә, илдә иҗтимагый вә сәяси системаның җимерелүенә һәм яңа хакимият урнашуына китерә. Яшәешкә мондый контекстта караганда, безнең перспектива ниндиерәк булып күренә соң?

Куелган сорауга мөмкин кадәр объектив җавап табу өчен, фикер йөртүебезне илдәге реаль хәлләрне компромиссыз ачыклаудан башлыйк. Әүвәл иҗтимагый тормышның рухи ягына тукталыйк. Зурдан алганда, бүген ул иҗтимагый аңы дистәләрчә ел бөекдержавачыл шовинизм рухындагы массакүләм пропаганда белән миңгерәтелгән халыкның җәмгыяви вә әхлакый яктан тирән кризис кичерүен, ул гына түгел, чарасызлыктан, аңың күмәк аңы хәтта гаммәви саташу халәтенә дә җитүен күрсәтә. Хактан да, халыкның агрессив күпчелеге хәзер бөекдержавачыл психоз халәте кичерә, бөтен дөньяны гаепли, ә читләшкәннәрне хәрби көч белән дә «акылга утыртырга» кыҗрый. Тормышыбызның матди ягына килгәндә, анысы инде сүзсез дә аңлашыла булыр: дөньяда иң зур территорияне биләгән һәм төп табигый ресурсларның өчтән бере өстендә утырган илнең күпчелек халкы патша заманында да чабаталы булып калган, совет чорында да чак очны очка ялгап яшәде, бүген исә күпләр совет чорын да сагынып искә ала. Илдә эчке сәясәт тоташтан тыюларга корылган һәм алар көннән-көн арта тора, ә тышкы сәясәттә «дөньяда тиңе булмаган» бу ил инде «читкә сөрелгән сукбай» дәрәҗәсенә төшерелгән. Тормышның килеп төртелүе шушы була түгелме соң?

Инде илдәге сәяси системага да бераз тукталыйк. Ә ул, Конституция формаль яктан сакланган хәлдә, барлык хакимият тармакларын да (башкарма хакимият, парламент, суд системасы һәм «дүртенче» хакимият) бер кешегә буйсындыруга корылган. Рөхсәт ителгән сәяси партияләр дә, асылда, әлеге режимга төрле яктан хезмәт күрсәтү белән мәшгуль. Демократия институтлары да (сайлау системасы, хокук яклау системасы, парламент эшчәнлеге, ватандашлар иреге һ.б.), чынлыкта, демократияне имитацияләү белән генә шөгыльләнә. Мисал өчен, президент каршында эшли торган кеше хокуклары һәм ватандашлар җәмгыятен үстерү буенча шура (СПЧ) эшчәнлеген алыйк. Аны тискәре хис-тойгылар уятучы шәхес җитәкләве (җөмләдән, оешма башына аның антиподы булган затны кую инде күптәннән гадәттә, мисалга ЛДПРны гына искә төшерик) үзе үк күп нәрсә турында сөйли. Күптән түгел президент указы белән СПЧ составында либераль карашлы соңгы әгъзалар да алыштырылды. Кызганычка, «дүртенче» хакимият белән дә охшаш хәлләр. Ә «пропаганда машинасы»на импульс югарыдан бирелә. Әйтик, узган атнада Президент В.Путин илдә быел фәкыйрьлек дәрәҗәсе түбәнәюе турында белдерде һәм саннар да китерде. Ә аларның ни дәрәҗәдә дөреслеккә туры килүен инде һәр кеше үз мисалында да белә ала. Хәлләрнең реаль торышы Татарстанда да бүген әллә ни аерылмый. Сәяси яктан аерма, бәлки, шунда гынадыр, ул хәзер 1994 елда федераль үзәк белән вәкаләтләрне бүлешү турында килешүне имзалаудан башланган чигенү процессының «җимеш»ләрен җыя. Күптән түгел республика Конституция судыннан ваз кичсә, бүген инде аның парламенты «президент» атамасын бетереп мәш килә. Эшләр алга таба да шулай дәвам итсә, финалның нинди булачагын чамалавы кыен түгел.

Ә илдәге хәлләр көннән-көн кискенләшә генә бара. В.Путин «Валдай» форумында бу җәһәттән, модератор соравына җавап биреп, хәтта ватандашлар бәрелеше баруын да өлешчә таныды. Алгы планга янә төп сорау чыга: ошбу кискен хәлдән чыгу юлын ничек табарга? Ә ул бар һәм узган язмаларда аның хакында сүз инде булган да иде. Бу мәсьәлә бүген Мәскәүне дә борчый кебек. Һәрхәлдә, яңа дөньяви тәртип һ.б. турында сүз дин әһелләренең күптән түгел Мәскәүдә үткәргән халыкара форумында да булган. Насыйп булса, ул хакта сүзебезне инде киләсе язмаларда дәвам итәрбез.

Фоат УРАЗАЙ.

Көллиятләрдә иҗади яшьләр укый

Казан технология һәм дизайн көллияте базасында һөнәри белем бирү уку йортлары студентлары арасында «Көмеш каләм» республика иҗади конкурсының йомгаклау туры узды. Бәйге быел алтынчы тапкыр үтте. Катнашучыларны көллият директоры Ирек Даутов сәламләде һәм конкурсның актуальлеген ассызыклап, аның Татарстан халыклары телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында оештырылуын һәм яшь иҗатчыларда милләтебезнең теленә, мәдәниятенә, үзенчәлегенә карата кызыксынуны арттыруга юнәлдерелгән икәнлеген искәртте. Быел иҗади бәйгедә Татарстанның Казан һәм Чаллы шәһәрләре көллиятләрендә укучылар катнашты. Алар үзләренең иҗатларын сәхнәдән һәм язмача формада тәкъдим итте. Сәхнәдән чыгыш ясаган студентның милли киемдә булуына, видео һәм фото материаллар кулланууына һәм газета-журналларда басылган, социаль челтәрләрдә чыккан материалларына игътибар бирелде. Шунысы аеруча сөендерде: БДИ, бердәм стандарт дигән нәрсәләр русча укытуга китерсә дә, туган телебездә иркен сөйләшә һәм иҗат итә торган яшьләребез хәтсез. Әйтик Чуашстанның Урмай авылында туып үскән, Казан сәүдә-икътисад көллияте укучысы Айшат Шәрипов жюри әгъзалары өчен чын табыш булды. Үсмернең «Ай һәм Кояш» дигән әсәре биш ай дәвамында «Идел» журналында басылган. Айшат шулай ук татар телендә бик матур шигырьләр дә яза. «Шигърият» номинациясендә исә жюри әгъзаларының күңелен Әгерҗедә туып үскән, хәзер Казан педагогика көллиятендә белем алучы Гөлназ Рәшитова иҗаты яулады. Кызның шигырьләрен «Ялкын» һәм «Идел» журналлары да үз укучыларына бик яратып тәкъдим иткәннәр. Милли сәнгатебезне сөючеләр Гөлназны узган ел һөнәри белем бирү уку йортлары студентлары арасында үткән «Татар кызы» конкурсының Гран-при иясе буларак та белә. «Интервью» номинациясендә исә Казан энергетика көллияте студенты Мөхәммәт Тимеровның әдәбият галиме Әлфәт Закирҗанов белән әңгәмәсе күңелләргә хуш килде. Катнашучылар конкурсны оештыруда башлап йөргән технология һәм дизайн көллияте мөгаллиме Гөлфизә Муллануровага рәхмәт белдерде.

Сөембикә КАШАПОВА.

«Агыйдел» сәхнә тотты

Актанышның «Агыйдел» җыр һәм бию ансамбле, «дәүләт ансамбле» статусы бирелүгә 10 ел тулу уңаеннан, Казанда юбилей концерты куйды.

Башкала тамашачысына ансамбльнең ун ел эчендә иң уңышлы дип саналган «Сөн буе татарлары», «Әстерхан татарлары», «Ай, былбылым», «Авыл яшьләре биюе» һәм башка композицияләре күрсәтелде. Концертта «Агыйдел» каршында оешкан «Ак инеш» балалар ансамбле дә чыгыш ясады.

Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә узган бәйрәм концертында Татарстанның мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин, Актаныш районы башлыгы Ленар Зарипов, Казандагы Актаныш якташлар җәмгыяте җитәкчесе Вәсим Вахитов, «Ак калфак» татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасы рәисе Кадрия Идрисова катнашты.

Л.Зарипов ансамбльнең уңышы дип, җыр-бию аша татар телен үстерүне атады. «Җыр да, моң да, бию дә, шигырь дә – барысы да булырга тиеш. Чөнки без шулар аша чал тарихлы татар телен алга этәрәбез. «Агыйдел»нең репертуарында күп милләт биюләре бар. Халыклар дуслыгы – безнең зур байлыгыбыз», – диде район башлыгы.

«Агыйдел ярлары кешенең күңеленә ямь, мәхәббәт бирә, моңландыра. Без бу талантны сүндерергә тиеш түгел. Алар Татарстанны гына түгел, Россияне – төрле милләт биюләре аша берләштерә, туплый!» – диде В. Вахитов.

Бәйрәм концертында Татарстанның атказанган артисты Лилия Муллагалиева, сәнгать юллары «Агыйдел» ансамблендә башланган Татарстанның атказанган артисты Газинур Фарухшин, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Азат Нургалиев чыгыш ясады.

Энҗе ГАБДУЛЛИНА

БЕРГӘ БУЛЫЙК!

«Мәдәни җомга»га 2023 елның I яртыеллыгына язылыр өчен санаулы көннәр калды. Газетага почтада гына түгел, өйдән чыкмыйча гына, интернет аша podpiska.pochta.ru сайтында да язылып була.

Соңга калмагыз!

Ярты елга язылу хакы – 725 сум 94 тиен.

«Мәдәни җомга»** газетасына Татарстанда язылу индексы – **П2355.

1 нче биттә - Уфада генерал Миңнегали Шәйморатов һәйкәле. Л. Лерон фотосы.

Мәдәни җомга
23 декабрь
№50, 2022

Өченче «Яңа татар җыры»

Халыклар дуслыгы йортында III “Яңа татар җыры” конкурсының финалы узды. Ике номинация буенча 200 гаризадан финалга 78 җыр узды. Җырларга Татарстанның халык шагыйре, жюри рәисе Рәзил Вәлиев, Татарстанның халык артистлары, композитор Резидә Әхиярова, җырчы Зөһрә Шәрифуллина, дирижер Миләүшә Тәминдарова, композитор, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Риф Гатауллин, җырчы, композитор Рәфис Хөснетдинов, ТНВ телеканалының әдәби-нәфис редакциясе җитәкчесе Фәридә Төхвәтуллина, музыкант, продюсерлар Рөстәм Сәрвәров һәм Айгөл Зәйнуллина, конкурсның генераль продюсеры Рифат Фәттахов бәя бирде.

Җырларның сыйфаты, татар эстрадасының киләчәге һәм катнашучыларның яшь аермасы турында матбугат очрашуында сөйләделәр. «Конкурсның максаты – татар җырын камилләштерү, милли эстраданы сыйфатлы әсәрләр белән баету. Былел III «Яңа татар җыры»на, узган ел белән чагыштырганда, азрак җыр килсә дә, алар күпкә сыйфатлырак. 95 автордан 200 җыр килүе дә татар халкының иҗат куәсе көчле булуын раслый. Моннан тыш конкурс төрле буын вәкилләрен җәлеп итте. Иң яшь катнашучы – Мөслимнән 15 яшьлек Илвир Габдрахманов, иң өлкәне – 92 яшьлек легендар җырчы Мәсгут Имашев. Катнашучылар арасында Илгиз Закиров, Дилә Булгакова, Гүзәлия кебек популяр авторлар белән беррәттән, әлегә зур танылу алмаганнары да бар», – диде генераль продюсер Р.Фәттахов. Уңыш сере белән танылган композитор Мәсгут Имашев бүлеште: «Җырның коры сүзләрдән генә торуы түгел, хис белән бәйле булуы мөһим», – диде ул. Иң яшь катнашучы Илвир Габдрахманов конкурс турында социаль челтәрләр аша белүен әйтте. II «Яңа татар җыры» лауреаты Радик Шәрәфиев быел да үз көчен сынап карарга булган. Конкурста ватанпәрвәрлек хисләре белән сугарылган җырлар да булды. Продюсер моны катнашучыларның илдәге вәзгыятькә битараф түгеллеге белән аңлата. Разил Вәлиев сүзләренчә, җырның эчтәлегенә аерым игътибар бирелә. «Конкурсның төп бурычы – бүгенге көндә халыкка кирәкле җырларны сайлап алып, тамашачыга җиткерү. Жюри рәисе буларак, беренче чиратта, шигырьгә игътибар итәм. Ул чыннан да шигырьме, шигърият кануннарына туры киләме? Музыкасы татарчамы, яңа яңгыраш өстиме, җырның сүзләре белән аның музыкасы тәңгәл киләме? Шуларның бөтенесе дә туры килсә генә, бу җырны тәкъдим итәбез», – диде ул, катнашучы авторлар өчен осталык дәресе үткәрү теләге булуын да җиткереп. Бәйгедә «Иң яхшы татар җыры», «Иң яхшы балалар җыры» номинацияләре каралган. Җиңүчеләрне быел да акчалата бүләкләр көтә: 1нче урын – 200 000 сум; 2нче урын – 150 000 сум; 3 нче урын – 100 000 сум; махсус приз – 50 000 сум. Конкурсны Татарстан Президенты ярдәме белән республикабызның Мәдәнияте министрлыгы һәм Рәшит Ваһапов фонды үткәрә. Гала-концерт 18 мартта узачак.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

«Апуш»тан яңа тамаша

Казанның «Сәйдәш» мәдәни үзәгендә «Апуш» татар театр студиясе үзенең икенче спектаклен – «Зоопарк-Әлифба» тамашасын күрсәтте.

Спектакльне шагыйрә Йолдыз Шәрәпова әсәре нигезендә Хәбир Ибраһимов сәхнәләштергән. «Башта мин шигырь нигезендә әзерләнәчәк спектакльнең нинди булачагы турында уйландым, драматургиянең үз законнары бар бит. Соңрак Хәбир Ибраһимов шалтыратты, ярдәм сорап аңа мөрәҗәгать иттем. Ул спектакль өчен текст әзерләде. Соңгы җыр спектакль өчен махсус язылды», – диде автор.

Спектакльдә «Сәйдәш» үзәге базасында эшли торган «Апуш» студиясенең 30 баласы уйный.

«Апуш» – Казан мэриясе өчен әһәмиятле проект. Балалар белән профессиональ остазлар эшләү барышында алар үз осталыкларын тагын да яхшырта. Бер елдан балалар чын артистлар булачак», – диде шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Гүзәл Сәгыйтова. Ул студия коллективының Йолдыз Шәрәпова әсәре буенча ачык имтихан күрсәтергә тиеш булуын, ләкин, дәртләнеп, әсәрне театр спектакле дәрәҗәсенә кадәр җиткерүләрен ассызыклады. Балаларның тырышлыгы аркасында чираттагы сәхнә әсәре барлыкка килгән.

Студиядә тәрбияләнүчеләр атнасына өч көн актерлык осталыгына, хореографиягә, сәхнә теленә, вокалга өйрәнә. Аларның беренче иҗат эшләре драматург Равил Бохараевның Мөдәррис Әгъләмов тәрҗемәсендәге «Апушның тылсымлы төшләре» спектакле булды. Бу спектакль «Театраль Идел буе» конкурсының республика этабында беренче урынны яулады.

Ренат Ибраһимов күңелләрдә яши

Россиянең һәм Татарстанның халык артисты, композитор, актер, режиссер һәм продюсер, быел 14 майда гомере өзелгән Ренат Ибраһимов һәркайсыбызның яраткан җырчысы иде. Аңа быел ноябрь аенда 75 яшь тулган булыр иде.

Мәскәүдәге Татар мәдәнияте йортында легендар артистка багышланган хәтер кичәсе узды. Аны «Әсәдуллаев йорты» һәм Татарстанның Россия Федерациясендәге вәкиллеге оештырды. Кичәгә килгән кунаклар арасында күренекле шәхесләр, танылган артистлар, Р.Ибраһимовның дус-кардәшләре, сабакташлары, туганнары, хатыны Светлана һәм балалары бар иде.

Кичә Россиянең атказанган артисты, опера җырчысы Владимир Кудашев, Татарстанның атказанган артисткалары Роза Хәбибуллина һәм Гөлчәчәк Галләмова һ.б. башкаруында матур җыр белән башланып китте. Артистның улы Солтан да тамашачылар игътибарына моңлы җыр тәкъдим итте.

Генерал-полковник Рәсим Акчурин, Россиянең Советлар мөфтие рәисе урынбасары Рушан Аббясов артист хакында матур хатирәләре белән уртаклашты.

Ренат Ибраһимовның 1999 елдан башлап уңышлы эшләп килгән Җыр театрында төрле музыкаль жанрларны популярлаштырырга тырышуын күпләр хәтерлиләр. Кичәдә Р.Ибраһимов башкаруында һәрбер җыр хитка әверелүе турында кабат-кабат искә алдылар.

Ренат Ибраһимов, чын татар кешесе буларак, туган телне саклап калу, аны киләчәк буынга җиткерү өчен күп тырышлык куйган. Тормыш иптәше Светлана белән бергә үстергән балаларын татар телендә сөйләшергә өйрәткән. Татар халкының мәдәниятен, гореф-гадәтләрен саклау аның өчен мөһим максатларның берсе булган.

Шундый ук максат белән эш алып барган «Татарлар һәм башка төрки халыкларның милли конгрессы» оешмасы вәкилләре Ренат Ибраһимов белән якын аралашып яшәде. Артист оешма җитәкчесе Рөстәм Ямалеев үткәргән бәйрәмнәргә һәм очрашуларга зур кунак булып чакырыла иде. Соңгы шундый күрешү ифтар кичәсендә узды.

Лилия ГАЛИМОВА.

Онытылмас баянчы

Татар җәмәгатьчелеге зур югалту кичерде. Виртуоз баянчы, аккомпаниатор, җырчы, композитор, Татарстанның халык артисты Рамил Сөләйман улы Курамшин каты авырудан соң вафат булды.

Р. Курамшин 1947 елның 16 июлендә Горький өлкәсе (хәзерге Түбән Новгород өлкәсе) Сергач районы Кучкай Пожары авылында укытучылар гаиләсендә туган. Әтисе һәм абыйсына ияреп, 5 яшьтән гармунда уйнарга өйрәнә. Һөнәри баянчы булу теләге белән 1964 елда Казанга килә. Казан дәүләт педагогика институтының музыка факультетында укый башлый. Ел ярым укыгач, Казан музыка училищесына күчә. Шул елларда ук Ф.Насретдинов, И.Ишбуляков, Р.Билалова, В.Шәрипова, Х.Гыйниятова, Ә.Галимова, Г.Рәхимкулов, З.Басыйрова һ.б. җырчыларга баянда уйный. Казан музыка училищесын тәмамлагач, Татар дәүләт филармониясендә эшкә билгеләнә. Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә дә хезмәт куя, егерме ел Илһам Шакировның концерт бригадасында эшли. Радиодан баян өчен үзе язган пьесаларны һәм татар халык көйләрен эшкәртеп уйный: 1975 елда татар баян музыкасында беренче зур күләмле әсәр – «Баян белән оркестр өчен концертино» яза. 1987 елда «Баян белән оркестр өчен икенче концертино»ны тәмамлый.

Р. Курамшин – музыка уку йортлары өчен дәреслекләр, йөзгә якын оригиналь әсәр, халык көйләре эшкәртмәләре, 200 дән артык җыр авторы.

● Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов имзалаган закон буенча, 2023 елда республика бюджетының керемнәр күләме 343,9 миллиард сум, чыгымнар күләме 371 миллиард сум булыр дип фаразлана, дефицит 27,1 миллиард сум тәшкил итәчәк. 2024 елда исә Татарстан бюджетының керемнәр күләме 367,4 миллиард сум, чыгымнар күләме 394,6 миллиард сум булыр дип көтелә, дефицит 27,2 миллиард сум тәшкил итәчәк.

● Татарстанда быел «Безнең ишегалды» программасына кергән барлык 1212 ишегалдында да ремонт төгәлләнгән. Өч елда исә барлыгы 3 меңнән артыграк йорт яны территориясе тәртипкә китерелгән. Программа буенча, биш елда барлыгы 6923 ишегалдын ремонтлау планлаштырыла.

● Татарстан Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматлары буенча, Татарстан хезмәт базарында мондый белгечләргә ихтыяҗ зур: машина йөртүчеләр (эш хакы аена 39500 сум) – 1600 вакансия; инженерлар (36800 сум) – 1300; табибләр (36800 сум) – 880; ашчылар (24500 сум) – 830; электр һәм газ белән эретеп-ябыштыручылар (39900 сум) – 788 вакансия.

(Дәвамы. Башы 2 нче биттә).

БАШКОРТЛАРДА МИЛЛИ РУХ ИСӘН

Чит-ят игътибар бирмәс, ләкин 1812 елгы Башкорт гаскәре составында мишәр һәм типтәр полклары да булуын, «башкортныкы» дип аталса да, 5 нче, 6 нчы, 19 нчы һәм 20 нче полкларның элекке Минзәлә өязе составына кергән, бүген исә Актаныш, Минзәлә, Сарман, Тукай, Мөслим, Әгерҗе районы авылларындагы татарлардан төзелүен дә без беләбез. Гомум саны белән 20 гә җиткән полкларны бүген дә оныклары горурланып искә алучы Илеш, Чишмә, Чакмагыш, Тәтешле, Балтач, Нуриман, Кушнаренко, Борай, Яңавыл, Краснокама, Калтасы, Туймазы, Шаран, Бакалы, Бәләбәй, Стәрлетамак, Стәрлебаш татарлары да төзешкән. Нәкъ шуңадыр, Шәйморатов һәйкәленең пьедесталында урын алган 1812 ел җайдаклары татарга да, башкортка да бердәй якын һәм кадерле. Һәм Бөек Ватан сугышы чорында дан алган 112 нче кавалерия дивизиясе белән дә нәкъ шулай. Ул да – яртылаш башкорт, яртылаш – татарныкы. Шуңа күрә ул бүген – татар белән башкортны берләштерүче символ. Шул ук вакытта, без «башкортныкы» дип аталган дивизия составында рус, мари, чуаш вәкилләре яу йөрүен дә онытмыйбыз. Тик төп сүзебез бүген башкачарак өлкәгә юнәлтелгән. Безне, Россия мәйданында яшәүче барча «вак» милләт вәкилләрен ике ел элек кенә республика яшьләренең Куштауны саклап калуы сокландырган иде, бүген инде Шәйморатов һәйкәле каршында да, андагы яшьләрнең сынмас рухы, милли чисталыгы алдында баш иябез. Без шуңа мөкиббән!..



● Һәйкәл пьедесталында 112 нче Башкорт дивизиясенә багышланган панно.

● Пьедесталның икенче ягында 1814 елда Париж каласын яулаган башкорт полклары.

(Игътибарыгызны читкә алмас өчен, бер тарафны җәяләр эчендә генә әйтеп үтим, дәшми түзә алмыйм. Башкортстан районнары һәм Уфаның үзе буйлап йөргәндә бик күп урамнарның һаман Цурюпа атлы кансыз комиссар исемен саклавын күреп гаҗәпләндем. Шушы вәхши җан 1919-1920 елларда продразверстка дигән сылтау белән, Башкортстандагы барча авыллар келәтен соңгы бөртек ашлыгына тикле талаттыра. Мәскәү алдында тугры вә күндәм булып күренергә маташкан җанварны шундук бәялиләр. Цурюпа Россиянең азык-төлек комиссары итеп билгеләнә һәм мәркәзгә күчеп утыра. Ә Башкортстанда 1921 елда башланган коточкыч ачлык ярты миллион халыкны кырып сала. Хөкүмәтләрнең Цурюпа һәм Бауман шикелле террор остасы булган большевиклар исемен бүген дә байрак итеп йөртүе тәмам шаккатыра).

Башкортстан яшьләренә мондый милли батырлык, сынмас-чигенмәс рух каян килә? – дигән сорау безне гел-гел бораулады. Соңгы сәяхәттә, Уфа каласын гизгәндә моңа җавапларны беркадәр ачыкладык. Шәһәр уртасындагы Акмулла һәйкәле янына баш ияргә баргач, шул мәйданда берьюлы 6 тарафтан «Акмулла исемендәге БАШКОРТ педагогика университеты» дип янып торган күрсәткеч такталар чиксез шаккатырды. Бәрәкалла, боларда педагогика институты һаман исән, Мәскәү кубызына биеп, аны юкка чыгармаганнар бит, дип ары эзләнеп киттек. Шушы бер педагогика университеты гына да 13 корпуста урнашкан булып чыкты. БАШКОРТ ТЕЛЕНӘ багышланган аерым факультет, аерым корпус яши! БАШКОРТ дәүләт университетына юл тотсак, 4 катлы төп корпусның бер каты тулысынча – БАШКОРТ факультеты! Йә Ходаем, Уфа бернинди тел тыюларга да игътибар итмәгән, боларның тел-мәктәпләрен кирза итек кигән прокуратура хезмәткәрләре дә таптап үтмәгән бит! Мәктәпләрендә дә башкорт телен хәтта атнасына биш сәгатькә кадәр укыталар. Һәм болар «акчасын Мәскәү түли», дигән ялган тылсымга алданып, авиация, медицина, нефть, төзелеш, авыл хуҗалыгы институтларын да бер федераль университет түбәсе астына куып кертмәгән! Боларда уку йортларының һәммәсе нәкъ совет чорындагыча исән-сау, һәммәсе мөстәкыйль. Шул ук вакытта Башкортстан Мәскәү казнасына 260 млрд сум тирәсе генә салым түләп килә, ә без «лидер» булгач, һәр ел саен 800 млрд сумга кадәр ясак озатабыз...

Янә бер татар әдибе хөрмәтенә куелган һәйкәлне күрик әле, дигән сылтау белән юлны дәвам итәбез. Безне алдына Мәҗит Гафури сыны куелган мәһабәт Башкорт академия театры каршылый. Айлык афишасын барлап чыксак, анда сыңар гына урыс, кытай, япон, осетин яки грузин әсәрләренең дә исеме юк. Барча драма авторлары да – фәкать башкорт белән татар. Әле алары да милли рухы, милли аһәңе булган, тамашачыга үз милләтең белән горурлану хисе сеңдерү өчен сайлап алынган. Мисалга, Гафури театры репертуарыннан бер драмага гына тукталыйк. М.Шәйморатовка Россия Герое исеме бирелүгә үк, Башкортстан кинематографчылар берлеге рәисе Зөһрә Буракаева әлеге каһарман турында шундук шаккатыргыч сәхнә әсәре дә язып өлгертте, ул ике-өч ай эчендә Гафури театры сәхнәсенә менде. Аны республика башлыгы Р.Хәбиров та тамаша кылды һәм Зөһрә ханымга С.Юлаев исемендәге Дәүләт премиясен бүләк итте. Труппа хәзер драманы Гафури театры сәхнәсендә кую белән генә канәгатьләнми, аны республиканың барча районнары буенча йөреп тә күрсәтә... Ягъни башкорт режиссерларына урысларның өч тиенлек «Алтын битлеге» дә кирәкми, болар кытай спектаклен әзерләп, Кытайдагы миллиард ярым халыкны аяктан егу турында да хыялланмый. Ә безнең Мәдәният министрлыгы нишләп фәкать Кытайда гына уйналачак драма куелышын хуплап яши, әллә безнекеләр гамендә «Мәскәүгә җибәрерлек акча» өчен «касса» туплау гына иң төп максатмы соң?..

Алдыбызда ике китап кибете, язучылар аларны урап үтә алмый. «Безнең китапларны татар халкы яшәгән чит регионнарга чыгармыйлар, совет чорындагы китап белән сәүдә челтәре бөтенләй җимерелде», дип гел зарлана идек. Ә монда «башкорт әдәбияты» белән «татар әдәбияты» дип язылган, игезәктәй охшаш ике бүлек япь-янәшә тора. Татар бүлегендә сәфәрдәшебез Рөстәм Галиуллинның өч китабы куелган, мин фәкыйрегезнең дә Мәдәният министрлыгы акча бирергә кызганмаган чакта чыгып өлгергән сайланма әсәрләрнең 4 томыннан бер китап ятып калган. Сатучылардан сораша торгач, шуны белдек: «Планета» исемле сәүдә челтәре Башкортстан буенча 64 шушындый кибет ачып өлгергән, ул челтәр татар китапларын да күпләп кайтара икән! Боларда – 64, бездә – өч кибет! Ә совет чорындагы 81 кибетле «Таткниготорг» челтәре «аренда һәм коммуналь чыгым өчен түләүне акламый», дип 30 ел элек үк юкка чыгарылды. Җир белән күк аермасы ошбу өлкәдә дә хөкем сөрә...

Башкорт әдәбиятына да игътибар итми калмадык. Сөбханалла! «Башкорт әдәбияты тарихы» – 16 том. «Башкорт теленең академик сүзлеге» – 10, «Башкорт халык иҗаты» – 18 том. Әле кичә генә 16 томлы «Башкортстан авылларының тарихы», 47 томлы «Башкорт ырулары тарихы» сатыла иде, инде юкка чыккан. Ә бездә «Татарстан авыллары тарихы» дигән сыңар китап та юк. Без дә чәчәк аткан булып саналабыз... Әле көнаралаш «лидер» дип күкрәк сугудан да тайчынмыйбыз...

Ә аннары җыелып утырабыз да, безнең мәктәпләргә кирза итек белән кереп, татар телен тыеп-таптап йөргән прокуратура хезмәткәрләрен, йә ФГОСны ел саен яңартып торган Россия Мәгариф министрлыгын сүгәбез. 2007 елда чыгарылыш имтиханнарын фәкать урыс телендә генә бирергә, дигән закон чыгарган чакта, Казандагы Камал театры янына нибары 700 ләп кенә яшүсмер җыелганны инде онытык без. Ә Уфада башкорт яшьләре БАШКОРТ университеты янына 15 мең булып чыкты, митинглары гына да өч тәүлек буе барды, аларны бернинди полиция дә таяк белән куып таратмады. 2017 елның ноябрендә безнең университеттагы бер төркем студентлар кулларына «Әлифба» тотып һәм «Туган тел»не җырлап, Дәүләт Советы янында ахыр чиктә карагруһчылар сәясәтен яклаячак телсез депутатларны каршы алган өчен, аларны шул ук газиз телне гомеренең соңгы сулышына чаклы сакларга һәм якларга тиешле мөгаллимнәр факультет деканы яисә карак ректор янына чакыртып та сүктерде, җинаять эше кузгату белән янап, башкача митингларда катнашмаска дигән ант кәгазьләренә имзалар да куйдыртты. Йә, шушындый кимсетү һәм мәсхәрәдән соң кайда яшьләр милли рухлырак та, иртәгә андый-мондый хәл туса, «лидер» республикада газиз милләте, туган теле, мөстәкыйль җөмһүрият өчен кемнәр көрәшәчәк соң? Без җавабын ачыкладык. Хәзер сезнең чират...

Автор фотолары.

(Дәвамы. Башы 47-49 нчы саннарда).

Рәис ЗАРИПОВ

ИКЕ ЙОЛДЫЗЛЫ ТАТАР

8 март көнне полк командиры Д.Бочко эскадрилья командиры М.Гәрәевне икенче Алтын Йолдыз медале белән бүләкләүгә тәкъдим итеп тутырылган документны имзалый. Өч биткә көчкә сыешып беткән документтагы соңгы нәтиҗә – сугышта ясаган 207 уңышлы хәрби очышлары вакытында күрсәткән батырлыгы, кыюлыгы һәм тәвәккәллеге өчен Гәрәев икенче Алтын Йолдыз медале белән бүләкләнүгә лаек. 18 мартта документ дивизия командиры имзасы төшкән нәтиҗә белән башлана, гвардия полковнигы С.Прутков (1945 елның 20 апреленнән авиация генерал-майоры) полк командиры тәкъдиме белән ризалаша һәм, шул ук вакытта, СССР Халык оборона комиссары И.Сталинның 1943 елның 4 маенда чыккан хәрби авиация берләшмәләренә кагылышлы Боерыгына сылтама да ясый. Шунысы игътибарга лаек: полк командиры да, дивизия командиры да үзләре чыгарган нәтиҗәләргә, "бүләкләнүгә тәкъдим ителергә лаек" дип куллары куйган, армия командующие генерал-полковник Т.Хрюкин исә, шәхсән кулдан язып, катгый рәвештә "ике тапкыр Советлар Союзы Герое исеменә лаек" дип, 28 мартта үз имзасын салган. Аннан соң документ "фронт командующие нәтиҗәсе" дигән җөмлә белән дәвам итә. 3 нче Белоруссия фронты командующие А.Василевский белән Хәрби совет әгъзасы генерал-лейтенант В.Макаров имзалары төшкән, әмма көне һәм ае күрсәтелмәгән нәтиҗә: "СССР Югары Советы Президиумының 1945 елның 19 апрелендә чыккан Указы белән 2 "Алтын Медаль" тапшырылып, Советлар Союзы Герое исеме бирелде".

Соңгы инстанция саналган фронт командованиесенең Мәскәүгә юлланасы тарихи документка карата мөнәсәбәте бераз аптыраштa калдыра һәм кайбер аңлашылмаучанлыклар китереп чыгара. Ни өчен фронт командующие белән Хәрби совет әгъзасы очучыны икенче алтын Йолдыз белән бүләкләү тәкъдимен, субординациягә ярашлы рәвештә һәм кертелгән тәртип буенча үз фикерләрен белдермичә, фәкать Югары Совет Президиумы Указына сылтама ясау белән чикләнгән? Шул Указга ярашлы рәвештә, ике "Алтын медаль" тапшыру нәрсәне аңлата? Әле житмәсә, "ике" санының цифр белән язылуы да бик серле. Гәрчә, кайбер нәрсәләр бик үк аңлашылып бетмәсә дә, куелган сорауларга җаваплар табарга мөмкин. Беренчедән, армия командующие имзалаганнан соң, бүләкләү документы 3 нче Белоруссия фронтына юллана, ә анда икенче Алтын Йолдызга тәкъдим ителүчеләр Муса Гәрәев белән генә чикләнми. Шуның нәтиҗәсе буларак, 15 апрель көнне Василевский белән Макаров, үзләрендә хезмәт итүче 7 Советлар Союзы Героен икенче Алтын Йолдызлар белән бүләкләү тәкъдиме белән илнең Халык оборона комиссары Советлар Союзы Маршалы Сталинга үтенеч юллый. Аннан күренгәнчә, Кенигсбергтан көньяк-көнбатыштарак тупланган дошман төркемен тар-мар итүдә һәм калания азат итүдә командование тарафыннан куелган бурычларны үтәүдә күрсәткән батырлыклары һәм тәвәккәллекләре өчен югары бүләккә икенче мәртәбә тәкъдим ителүчеләр – 43 нче армия командующие генерал-лейтенант Афанасий Белобородов, 1 нче һава армиясе командующие авиация генерал-полковнигы Тимофей Хрюкин, 36 нчы гвардия укчы корпусы командиры генерал-лейтенант Петр Кошевой, 76 нчы гвардия штурмлау авиациясе полкының эскадрилья командиры гвардия майоры Муса Гәрәев, 15 нче гвардия штурмлау авиациясе полкының эскадрилья командиры гвардия өлкән лейтенанты Евгений Кунгурцев, 126 нчы укчы дивизия составындагы 261 нче укчы полкының пулемет расчет командиры гвардия сержанты Иван Якименко һәм 268 нче укчы дивизиянең 997 нче укчы полкының батальон комсоргы Андрей Яналов. Дүрт көннән соң 3 нче Белоруссия фронтының 7 Советлар Союзы Героен икенче Алтын Йолдыз белән бүләкләү турында СССР Югары Советы Президиумының 19 апрельдә аерым Указы чыга. Шунысы игътибарга лаек: бүләкләнүче җиде кешенең бишесе – Хрюкин, Гәрәев, Кунгурцев, Мыльников һәм Паршин 1 нче һава армиясе вәкилләре.

Кызганычка, "ике алтын медаль тапшыру" мәсьәләсе бераз четереклерәк төсмер ала. Әүвәл шул тарихи мизгелне Муса Гәрәевнең үз истәлекләрендә ничек тасвирлануын бәян итү урынлы: "1945 елның 1 маен мин беркайчан да онытачак түгелмен. Без Кенигсбергтан 70 чакрым чамасы ераклыктагы Шипенбайль аэродромында тупланган идек... Әле кичтән үк дивизия командиры генерал С.Д.Прутковның, иртән иртүк дивизия штабына килергә кушкан боерыгын алган идек. Штаб, аңарчы, күптән түгел генә безнең полк торган Растенбург аэродромында урнашкан. Трофей итеп алган йөк машиналарының кузовларына утыру белән үзебезне ни өчен чакырулары турында баш вата башладык... Растенбургка дивизиянең бөтен полкларының очучылары җыелган иде, аэродромның бетон полосасында сафларга тезелеп, ни буласын көтәбез. Дивизиянең штаб башлыгы "төз басарга" дигән команда биреп, Прутковка доклад ясады. Аннары сафларыбыз каршына безнең һава армиясе командующие генерал Т.Т.Хрюкин чыкты. Безне 1 май бәйрәме белән котлаганнан соң, СССР Югары Советы Президиумы Указы белән миңа икенче Советлар Союзы Герое исеме бирелүен ирештерде һәм мине кочаклап:

– Синең өчен бик, бик нык шатмын, Муса, – диде.

Һәрвакыттагыча фәкать исем белән генә дәшә.

– Бу көнне мәңге исеңнән чыгарма. Әйт әле, тагын кемгә беркөнне берьюлы ике Алтын Йолдыз тапшырганнары бар? Гаҗәеп дәрәҗәдә сирәк күренеш! Бәлки бөтен сугыш чорында бердәнбер очрактыр!"

...Бөек Ватан сугышында 250 хәрби очыш ясаган, 30 тапкыр һава сугышында катнашып ике дошман самолетын бәреп төшергән, Ленин, өч Кызыл Байрак, III дәрәҗә Богдан Хмельницкий, Александр Невский, I дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары белән бүләкләнгән, ике тапкыр Советлар Союзы Герое исеменә лаек булган гвардия майоры Муса Гәрәев 24 июньдә Мәскәүдә үткән Җиңү парадында катнаша... Кышка керүгә, аңа туган якларга әйләнеп кайтырга туры килә, чөнки якташлары аны СССР Югары Советына депутатлыкка кандидат итеп чыгаралар, ә сайлаучылар белән очрашулар тагын күпме вакытны ала. Ниһаять, бар да тынычланды дип торганда, язгы көннәрнең берсендә табибләр тикшерүе һәр очучының сәламәтлеген энә күзеннән үткәрә. Белоруссия хәрби округының Лида каласында урнашкан 76 нчы гвардия авиаполкы составы өчен, сугыштан соң үткәрелгән иң җитди медицина комиссиясе тикшерүен күпләр дулкынланып каршылый. Чынлап та борчылулар урынсыз булмый, комиссия чыгарган нәтиҗәләр буенча М.Гәрәевнең якын дусты В.Протчевка самолетларда очу гомумән тыела, ул үзе исә хәрби авиация белән хушлашырга тиеш булып чыга. Ике дусның Мәскәү табибләренә күренүләре дә уңай нәтиҗә бирми. Бу хәлләрдән тәмам гаҗиз булып, берничә көн изаланган М.Гәрәев соңгы адымын ясый: ярдәм өмет итеп Хәрби-һава көчләренең кадрлар идарәсе ишеген кага. Идарә башлыгы аңа транспорт авиациясе аэродромына барып карарга куша. Часть командиры урынында булмаганлыктан, Гәрәевне аның урынбасары подполковник Владимир Зайцев кабул итә һәм ул да күкрәгендә ике Алтын Йолдыз бизәгән полк штурманы гвардия майоры Гәрәевкә фәкать эскадрилья командиры урынбасары вазыйфасын гына тәкъдим итү белән чикләнә. Шулай итеп, ул 2 нче махсус максатлардагы авиация дивизиясе составындагы 1 нче махсус максатлардагы транспорт авиациясе полкына эскадрилья командиры урынбасары вазыйфасына билгеләнә. Биредә М.Гәрәев Ли-2 һәм Ил-12 самолетларында ил җитәкчеләрен һәм югары командование составын төрле чараларга йөртүдә катнаша.

1948 елда ул иптәшләреннән күреп, документларын Фрунзе исемендәге Югары академиягә тапшыра һәм өч ел дәвамында, бөтен фәннәрне Бөек Ватан сугышы тәҗрибәсендә өйрәнеп, хәрби теория буенча белемнәрен камиллаштерә. Хәрби парадлар вакытында ул академия байрагын күтәреп уза. Бу мактаулы

вазыйфаны аңа кадәр, 1948 елда академияне тәмамлаган өч тапкыр Советлар Союзы Герое Александр Покрышкин башкара. 1951 елда югары хәрби белем алып чыккан подполковник Гәрәев аерым часть командирының очышларга әзерләү буенча урынбасары итеп билгеләнә. 1955 елның маеннан 1957 елның ноябренә чаклы – 6 нчы гвардия бомбага тоту авиациясе дивизиясе составындагы 600 нче хәрби-транспорт авиациясе полкы командиры.

1957 елда полк командиры полковник Муса Гәрәев, беркемгә дә әйтеп тормыйча, документларын Генштаб академиясенә юллый һәм ике ел буе шунда белем ала. 1959 елның сентябреннән ул – Мәскәү өлкәсенең Щелково каласында урнашкан 10 нчы махсус максатлардагы Кызыл Байраклы аерым авиация бригадасы командирының очышка әзерлек буенча урынбасары.

Дүрт ел дәвамында легендар очучы Ил-14 һәм Ил-18 самолетларында совет армиясе командованиесенең югары составын бөтен ил буйлап йөртә, Варшава килешүенә кергән барлык дәүләтләргә, шулай ук Кытайга, Югославия, Алжир, Әфганстан, Индонезия, Бирмага рейслар ясый.

Чирек гасыр дәвамында зәңгәр күкләрне иңләп йөзгән полковник Муса Гәрәев 1964 елда, сәламәтлеге буенча отставкага чыга һәм туган ягына әйләнеп кайта, Уфа каласында яши. 1965 елның октябреннән 1977 елның гыйнварына чаклы ДОСААФның республика комитеты рәисе булып эшли. Бу елларда ул әлеге мөһим оешманың төбәк бүлеген илдә иң алдынгылар исәбенә чыгаруга ирешә, аның материаль-техник базасын һәм мотоспортны үстерүгә саллы өлеш кертә. Шул уңышлары өчен Муса Гайсә улы 1971 елның 31 августында Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә.

Легендар очучыны республика ДОСААФына рәис итеп куюда аңа карата гаять уңай мөнәсәбәттә булган өч Алтын Йолдыз иясе А.И.Покрышкинның роле зур булган дигән фаразлар бар. Әмма бу дөреслеккә туры килми төсле. Чөнки, беренчедән, М.Гәрәев үз истәлекләрендә, үзенең Уфага кайтып, шул вазыйфага билгеләнүендә төп сәбәпче кеше дип, ул чактагы Башкорт өлкә комитетының беренче секретаре, Социалистик Хезмәт Герое, биш Ленин ордены кавалеры Зыя Нуриевне атый. Икенчедән, ул мәлдә авиация генерал-полковнигы А.И.Покрышкин Һавадан саклану гаскәрләре (ПВО) составындагы 8 нче аерым армия командующие һәм бер үк вакытта Киев хәрби округы командующиеның ПВО буенча урынбасары вазыйфаларын башкара, фәкать 1972 елның гыйнварыннан гына ДОСААФ Үзәк комитеты рәисе итеп билгеләнә. М.Гәрәев үз истәлекләрендә Зыя Нуриевне бик җылы хисләр белән тасвирлый, ә менә 1969 елда аны алыштырган булачак Социалистик Хезмәт Герое һәм биш Ленин ордены белән бүләкләнәчәк Мидхәт Шакиров турында бер җөмлә дә язмый. Сәбәбе – дорфа, тупас, надан һәм данга сусаган Шакиров гаебе белән ике арада башланып киткән, озакка сузылган перманент конфликт. Советлар Союзы Герое Александр Матрасовка куелган һәйкәлне алдырып, ул урынга үзенең бюстын куярга хыялланган беренче секретарьга республикадагы ике Алтын Йолдыз иясе һич тә тынгы бирми. Башкортстандагы татар мәктәпләрен туздырткан, үз милләттәшләре хисабына башкортлар санын арттыруга җиң сызганып керешкән бу мөртәт, түземсезләнеп, үзенә икенче Социалистик Хезмәт Герое исеме бирү мизгелләрен көтә һәм фәкать үзенең генә Алланың кашка тәкәсе булып калачына өметләнә. Шөкер, Брежневнең вафаты андый гаделсез гамәлнең тормышка ашу мөмкинлеген юкка чыгара.

Ни аяныч, М.Горбачев хакимияткә килгәч, тагын бер I дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләнгән М.Гәрәев 1987 елның 17 сентябрендә, нибары 65 яшендә мәкерле онкология чиреннән вафат була. Аның вакытсыз үлеменә Шакиров тарафыннан үзен тәмам юкка чыгару өчен даими оештырылып торган пычрак гамәлләр дә төп сәбәпләрнең берсе булуы бик ихтимал. Тик тарихи гаделлекне алдап булмый, вакыт барыбер һәрнәрсәне үз урынына куя: шактый еллар узгач, үз милләтенә карата хыянәтчел гамәлләр кылган пенсионер Мидхәт Шакировны Бөтендөнья башкорт корылтае бинасыннан тибеп чыгардылар. Ә менә М.Гәрәевнең рухы шат, аның якты истәлеге бүген миллионнар күңелендә яши. Каһарман ир-атның исеме Уфа, Стәрлетамак, Нефтекама, Октябрьск, Ишембай, Күмертау, Сибай, Учалы калаларындагы урамнарга бирелгән, ул Башкортстанның башкаласы белән Белоруссиянең Гродно өлкәсендәге Лида каласының мактаулы гражданы, 1988 елдан Агыйдел, Чулман, Идел елгалары буйлап, аккошны хәтерләтүче "Муса Гәрәев" теплоходы йөзә. 1948 елда туган авылы Иләкшидәдә ачылган бюстын 1967 елда Уфага күчерәләр, Иләкшидәдә Хәтер билгесе һәм Илеш районының үзәге Югары Яркәйдәге Үзәк музее янәшәсендә яңа бюст урнаштырылган, Ташчишмәдәге йорт-музееннан да халык өзелми. 1947 елда скульптор Н.Томский тарафыннан М.Гәрәевнең ясалган скульптура портреты Третьяков галереясында саклана. Ике тапкыр Советлар Союзы Герое Муса Гайсә улы Гәрәев Уфаның Агыйдел елгасы ярындагы калкулыкта урнашкан Җиңү паркында җирләнгән.

Алсирә МӨХӘММӘТҖАНОВА

Билләребез хәзер нечкә түгел, Күңел кылларыбыз нечкәрде...

МИЛӘШ ТӘЛГӘШЕ

Тәлгәш-тәлгәш миләш,
Бул син миңа сердәш,
Сары көздә тула җимешең.
Адашты бәхетем,
Көзләрдә өметем,
Бәхетемне эзләп килешем.

Көзләр никтер елак,
Язлар әле ерак,
Кызыл яшьләр тама тәлгәштән.
Әче җимешеңнән
Муенсалар тезәм,
Сагыш тәме килә миләштән.

Тәлгәш-тәлгәш миләш,
Бирче миңа киңәш,
Кире какма мине, миләшем.
Әллә яшим ялгыш,
Гомер үтә ялгыз,
Шуңа ярсу йөрәк тибешем.

Тәлгәш-тәлгәш миләш,
Синме ярым тиңдәш,
Өлешемә тигән көмешем?
Төшләргә керәсең,
Елмаеп көләсең,
Шушы микән бәхет җимешем?

* * *

Сары көзләр тагын килгән икән,
Тамчылары кага тәрәзгә.
Сулган гөлне соңгы тапкыр үбеп,
Бизәк сала кортлар кәрәзгә.
Ак каеннар моңсу, имәннәр дә,
Өрәңгеләр тирән сагышта,
Чыршыларның гына бер гаме юк,
Утыралар оеп кояшта.
Балан белән миләш – ике сердәш,
Икесе дә әче җимешле,
Шыбыр-шыбыр яфрак яңгырында
Уттай янган кызыл тәлгәшле.
Йомшак келәмнәрдә эзем кала,
Аякларга яфрак урала.
Киек казның каурый җилләрендә
Сулышлары көзнең тарала.
... Сары көзләр тагын килгән икән,
Күңелләрнең тулган чаклары,
Бураннарда әле адашырлар
Хисләремнең ярсу атлары.

* * *

Кагылма иңемә кышларның,
Кагылма, иң усал бураны,
Бирешмим, өрәм дә тынымны,
Җылытам өшегән җанымны.
Кагылма иңемә көзләрнең,
Кагылма өзлексез яңгыры,
Чыланса да керфек, бирешмим,
Сүнмәгән күңелнең ялкыны.
Кагылма иңемә тормышның,
Кагылма, иң ачы җилләре,
Керегез йөгереп кочакка,
Сыясыз, күңелем киң әле.
Кагылып иңемә тын гына,
Хәлемне, туган җир, син сора,
Җилләрдә уйнаган карларың,
Яңгырың тамчысы да дәва.
Кагылды иңемә илемнең
Башлары иелгән таллары...
Бирештем, түзмәде, җанымның,
Суларга түгелде зарлары...

КУЯН ТУРЫНДА КЫЙССА

Дөньялар икән куласа,
Әйләнә дә бер баса.
Бер үк хәлләр, бер үк җирдә
Кабатлана лабаса.
Арыслан, Аю, Төлкеләр...
Аучылар дөньясында
Тынычлап яши алмый, ди,
Бүре дә оясында.
Гел мәшәкать, гел борчудан
Тора икән көннәре,
Уен-көлке, шаяруда
Үтми икән төннәре.
Аучыбызның аяз көндә
Югалган,ди, сарыгы,
Иң симезе, иң майлысы,
Түгел икән арыгы.
Сарык эзләп йөргән, ди,
Эшен ташлап барысы.
Җинаятьчене тотканнар,
Суд бара, ди, ахрысы.
Тикшергәннәр, сорашканнар
Шаһитларны, аучыны.
Сез күрсәгез, исегез китәр
Сарыкны ашаучыны!!!
Хәйләкәр, ди, була икән
Сорысы да, ап-агы,
Үзен яклап ярты сүз дә
Әйталмаган, ди, тагы.
«Ә» димәгән, «Б» димәгән,
Килгән, ди, ыгы-мыгы...
Гафуриның Куянының
Пыра, пыра оныгы!!!
Арыслан, аю, төлкеләр
Аучылар дөньясында
Аркан ишәләр куянга
Бүренең оясында.
Дөньялар икән куласа,
Әйләнә дә бер баса,
Бер үк хәлләр, бер үк җирдә
Кабатлана лабаса.
Дар агачы көтә аны,
Җәзасын алыр куян...
Озын сүзнең кыскасы шул:
Мин дә ноктамны куям.

* * *

Бу дөньяда алга бара тик бер вакыт,
Хөкемдарлар һич үзгәрми – монысы факт
Чорлар үтә, заманалар, буын үзгә,
Һаман бер чүп кадала да керә күзгә.
Сабырлыкта татар алда, күндәм халык,
Ни кушсалар, шуны эшли арып-талып.
Татар халкы тормышында шул ук уйлар:
Идарәче олы абзый итә туйлар.
Татарның бит үз татары башын ашый,
Түрә булгач, гайрәтеннән ачуы ташый,
Элеп куя чабатасын түрләренә,
Байлык җыя алып китәр гүрләренә,
Хөкемдарның бар йомышын үтәп тора,
Әбуҗәһил пычакларын чарлап тора.
Тел кисәләр, күтәрелсен ник бер кашы?!
Милләтенең корып бара чишмә башы...
Хәстәрендә инде халык, бетә ашы,
Сараенда сөяп куйган кабер ташы.

КЕШЕ КИТӘ...

Кеше китә. Җирдә нәрсә кала?
Баскан эзе, эздә – туфрагы.
Шул туфракка төшкән орлык кала,
Ятим кала йөргән сукмагы.
Кеше китә, җирдә сагыш кала,
Җыры кала, җырда – моңнары.
Туган нигез, торган җире кала,
Атмый кала атар таңнары.
Кеше китә, кала нәсыйхәте,
Улы, кызы – нәсел хәтере.
Балаларга әйткән васыяте,
Үтәлергә тиеш нәзере.
Кеше китә, истәлеккә кала
Хатирәләр – кеше әйтере.
Ак кәгазьгә язган сүзләр кала,
Ноктадан соң кала өтере.
Кеше китә. Җирдә нәрсә кала?
Кабер ташы, ташта – исеме.
Салкын ташны кочкан җилләр кала,
Туфрак була кеше җисеме.
Кеше яши бары мизгел генә, –
Яшәү белән үлем арасы.
Онытмасын җирдә калган җаннар,
Мәңгелеккә һәркем барасы!

ПАЛАС ЮУЧЫ КЫЗ

Нигә төшкән татар кызы су буена,
Уйчанланган күз карашы, ни уенда?
Тал-тирәккә иңен куеп ник моңлана?
Ярсу йөрәк дулкыннан су комлана.
Су агышы алып китәр сагышларын,
Җырлы итәр, көйгә салыр камышларым.
Көянтәле чиләкләре авыр түгел,
Кемне көтә сөюләрдән тулы күңел?
Сөйгәненә чиккән ядкәр кулъяулыгын,
Мәрҗәннәре җемелдәшә муенында,
Вәгъдәләшсә ике йөрәк су юлында,
Бүләк итәр, бар да Ходай насыйбында.
Күпме торыр бит очларын яшькә күмеп?!
Өметләрен суга салма, ашык, егет!
Авылымның зөбәрҗәте, таң йолдызы,
Инешемнең бер мәрҗәне – татар кызы!
...Ник моңлана авыл кызы, ни уенда?
Паласларын юып элгән су буенда.

* * *

Телем озын микән әллә –
Кисмәкчеләр,
Тел килешми сиңа хәзер,
Димәкчеләр.
Алар өчен бигрәк яхшы
Сөйләшмәсәм,
Бөтенләй дә телсез булсам
Әйбәт икән.
Телсезләргә колаклар да
Нигә кирәк?
Ике күз дә минем йөзгә
Артык, димәк!
Авызымда телдән башка
Тешләрем бар,
Телләремә үрелгәнне
Тешләвем бар...
Чынлыкта да әллә инде
Озын телем?
...Кысып куйдым телләремне
Тешем белән.

* * *

Гомер үтә – үтмәс төсле һәркемгә дә,
Мәшәкатьләр тулы тормыш һәркемдә дә.
Иренәбез, онытабыз син дә, мин дә,
Яратам дип сөйгәннәргә әйтергә дә.
Чабып барган узыш аттай кыланабыз,
Ашыгабыз, чит ярларга табынабыз,
Ошамаса якыннарның карашы да,
Сызган шырпы төсле кинәт кабынабыз.
Сабыр итче, туктатып тор атларыңны,
Җибәр әле бер-бер артлы хатларыңны:
«Сөям сине, аңлыйсың син җаннарымны,
Балкытасың бары тик син таңнарымны».
...Гомер үтә, үтсен әйдә бәхетләрдә,
Чын сөюне куйыйк әле тәхетләргә!

КАРТАЙМАГЫЗ ӘЛЕ

Картаймагыз әле, замандашлар,
Безгә гомер бушка килмәгән,
Кайнар йөрәк тибә күкрәкләрдә,
Күңелләргә кырау тимәгән.
Билләребез хәзер нечкә түгел,
Күңел кылларыбыз нечкәрде.
Олы юлда хәрәмләшкән дусны
Йөрәк инде күптән кичерде.
Картаерга безгә иртәрәктер,
Әле яши генә башладык.
Җитдиләнә төштек кичә генә,
Җүләрлекне яңа ташладык.
Шаянлыкта тапкырлыкны таптык,
Күңел чая, һаман җилбәзәк.
Моңсу була безгә, гадәтенчә
Күз яшьләре аша көлмәсәк.
Бурычыбыз бизмәннәргә сыймый,
Безгә генә тиеш түгелләр.
Юкка-барга борын төшермибез,
Җырлы-моңлы безнең күңелләр.
Һәр түрәгә зурлап башлар идек,
Урындыгы булгач түрдәрәк.
Куласалар әйләнә дә баса,
Дөнья булган икән түгәрәк.
Мавыкмадык артык мода белән,
Белем бишекләрен тирбәттек.
Тугры дуслар булдык әрсезләргә,
Кәкре каен азмы тераттек?!
Тезгенләдек ярсу хисләрне дә,
Акылларны җиктек арбага.
Урманнарда төнлә йөремибез,
Чәчәк аткан инде абага...
Ашыкмагыз әле картаерга!
Эшләнәсе эшләр бетмәгән.
Иртәгәсен Ходай Үзе белә,
Күрәчәкләр булсын ил белән!

2022 ел Татарстанда цифрлаштыру елы буларак билгеләп үтелде. Бөтен ил белән бергәләп Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуны искә алдык. Яңа ел якынайганда, үтеп барган елга кабат борылып карыйбыз. Ирешелгән нәтиҗәләргә, шатлыклы көннәргә куанабыз. Кызганыч, ел шатлыклы вакыйгалардан гына тормады. Милләтебезгә, халкыбызга гомерләрен багышлаган күп кенә асыл затларыбызны югалттык. Алар арасында күренекле җәмәгать эшлеклеләре дә, галимнәр дә, әдәбият-сәнгать эшлеклеләре дә бар. Бакыйлыкка күчкән кайбер күренекле шәхесләребезне кабат искә алыйк әле.

Халык

2022 ел башында ук бөтен гомерен халыкка хезмәткә багышлаган олуг шәхес **Филзә Гариф улы ХӘМИДУЛЛИН** белән саубуллаштык. Дәүләт һәм күренекле җәмәгать эшлеклесе, ТАССРның элеккеге Премьер-министр урынбасары – икътисад һәм фаразлау буенча дәүләт комитеты рәисе Ф.Хәмидуллин 5 гыйнвар көнне 87 нче яшендә арабыздан мәңгегә китте. Ул икътисад фәннәре докторы, Татарстан Фәннәр академиясенең академигы иде.

19 гыйнварда татар җәмәгатьчелеге киң эрудицияле, үзенчәлекле карашлы әдип – язучы, журналист, режиссер **Заһид МӘХМҮДИ** белән хушлашты. Заһид Мәхмүди Казан дәүләт мәдәният институтында укыганда ук, «Чаян» журналында, «Яшь ленинчы», «Татарстан яшьләре» газеталарында дистәләгән юмористик һәм фантастик хикәяләрен бастыра. Хәрби хезмәттән кайткач, Кукмара район газетасында, аннары Татарстан радиосында, «Шәһри Казан» газетасында эшли. 1993-1998 елларда «Татарстан» журналында, «Татар иле», «Мәдәни җомга» газеталарында хезмәт куя, аннары «Казан» радиосында мөстәкыйль хосусый татар бүлеге оештыра, аның җитәкчесе һәм дикторы була. 2022 ел ахырында Мәхмүдигә «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» исеме бирелде.

Россиянең атказанган, Татарстанның халык рәссамы, республиканың атказанган сәнгать эшлеклесе **Зөфәр Фоат улы ГЫЙМАЕВ** февраль уртасында бакыйлыкка күчте. Аңа 71 яшь иде. З.Гыймаев 2008-2020 елларда Татарстан Рәссамнар берлеге рәисе вазыйфасын башкарды. Ул республиканың әйдәп баручы сынлы сәнгать осталары исәбендә булды. Тематик картина, портрет, пейзаж, натюрморт жанрларында эшләде.

Ягъсуф Долмаган улы ШӘФЫЙКОВ укучыларга республиканың Фикрәт Табиев, Минтимер Шәймиев кебек җитәкчеләренә багышлап язылган тирән эчтәлекле, күләмле китаплары белән таныш. КамАЗ, Чаллы, Волгодонск төзелешләрендә эшләп, Я.Шәфыйков производствоның бөтен нечкәлекләрен үзләштерә, килочәктә шул материалларын әдәби әсәрләрендә, матбугат язмаларында киң файдалана. 1991 елның декабреннән башлап «Татар-информ»ның Төньяк Кавказдагы махсус хәбәрчесе булды, аңа Краснодар, Ставрополь крайлары, Адыгей Республикасы, Ростов һәм Волгоград өлкәләрендә татар тормышын яктырту бурычы йөкләнде. 1999 елдан башлап ул «Татарстан» журналының бүлек мөдире булып эшләде.

Февраль ахырында филология фәннәре докторы, бик күп каләм әһеленең остазы, университет профессоры **Илдар Малик улы НИЗАМОВ** белән хушлаштык. Ул гомере буе журналистлык һөнәренә өйрәтте. Хезмәтләре массакүләм аралашуда сөйләм системасы вазыйфасына, социолингвистикага карый. И.Низамов – журналистика теориясенә караган дәреслекләр һәм уку ярдәмлекләре авторы.

2 март көнне К.Тинчурин театрының сәхнә ветераны, Татарстанның халык артисты **Земфира Исхак кызы ДОСАЕВА** вафат булды. З.Досаева 1937 елның 12 октябрендә Мәскәү шәһәрендә артистлар гаиләсендә дөньяга килә. 1964 елда Казанга чакырыла һәм күчмә театрда артист булып эшли башлый. 1974 елда А.В.Луначарский исемендәге театр сәнгате институтын тәмамлый. Татар театр сәнгате йолдызы З.Досаева иҗатының беренче көннәреннән үк үзен әйдәп баручы артистка итеп таныта, югары профессионализм белән сугарылган бихисап рольләр башкара.

Март башында шагыйрь, С.Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреаты **Рифкать Гаян улы ИМАЕВ** бакыйлыкка күчте. Р. Имаев 1948 елның 12 февралендә Балык Бистәсе районы Татар Казаклары авылында туа. 1967 елдан башлап Түбән Кама шәһәрендә яши. 40 ел «Түбәнкаманефтехим» берләшмәсендә эшли. 2005 елда Татарстан Республикасының атказанган химигы дигән мактаулы исемгә лаек була. «Кама таңнары» әдәби берләшмәсенә йөри. Биш шигырь җыентыгы дөнья күргән.

Түбән Кама татар дәүләт театры Татарстанның атказанган артистын **Наил СӘЙФЕТДИНОВНЫ** соңгы юлга озатты. Тумышы белән Балтачтан булып, ике дистә елдан артык Түбән Кама тамашачысын сөендергән Н.Сәйфетдинов 40 ка якын спектакльдә уйный. Театрның җырчы, гармунчы артисты 60 яшендә вафат булды.



Рамазан аеның уночнче көнендә Татарстан дәүләт радиосының кабатланмас тавышлы дикторы **Мәрьям апа АРСЛАНОВА** бакыйлыкка күчте. «Күпме генә яшәсәк тә, гомер дигәнең чикле шул. Мәрьям апабыз әллә йөзне тутырырмы дип уйлап йөргән идек, туксан алты яшендә – табигать уянган, кояш көләп караган бер вакытта – җир куенында мәңгелек урынын алды». Бу сүзләрнең авторы – М.Арсланова белән озак еллар радиода бергә эшләгән Фоат Галимуллин. Шунысын да өстик, Мәрьям Арсланова күренекле шәхес, шулай ук радиода диктор булып эшләгән Айрат абыйның хатыны иде.

3 майда язучы **Эсфир ЯҺҮДИН (Хәмис Шәмсегали улы Яһүдин)** вафат булды. 1949 елның 4 гыйнварында Башкортстанның Краснокама районы Яңа Хаҗи авылында туган Ә.Яһүдин читтән торып Казан дәүләт университетының журналистика бүлеген тәмамлый. 1974 елда Казанга килеп «Органик синтез» заводына эшкә керә. 1978 елда Казан дәүләт курчак театрына эшкә урнаша. 1979-1984 елларда Татарстан Язучылар берлеге юлламасы белән Мәскәүдә СССР Язучылар берлегенең М.Горький исемендәге Әдәбият институтын тәмамлагач, берничә ел Әлмәт драма театрында эшли.

14 майда халкыбыз зур югалту кичерде. Милләтебезнең танылган улы, Россиянең халык артисты, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты **Ренат Ислам улы ИБРАҺИМОВ** вафат булды. Р.Ибраһимов 1975 елда Сочида узган «Красная гвоздика» конкурсыннан соң таныла. 1993 елда ул «Итальянский контракт» фильмында төшеп актер буларак та атказана. Ренат җырчының талантына баш иючеләрнең йөрәкләрендә тулы бер чорның символы булып калачак. Табигать Ибраһимовка беркем белән дә бутап булмый торган гаҗәеп тавыш бүләк иткән, Ренат бөтен дөнья күләмендә миллионнарча тамашачыларның күңелен яулаган легендар җырчы иде.

9 июньдә журналист, филология фәннәре кандидаты **Муса Гайсә улы МӨЛЕКОВ** вафат булды. Ул 1937 елда Башкортстанның Благовар районы Сынны исемле татар авылында туа. Башкортстан дәүләт университетының филология факультетында укыган елларында «Кызыл таң» белән тыгыз хезмәттәшлек итә башлый. М.Мөлеков «Кызыл таң» газетасында гади хәбәрчедән башлап баш мөхәррир вазыйфасына кадәр юл үтә. 1986-1991 елларда «Кызыл таң»ның баш мөхәррире булып эшли.

24 июньдә 73 нче яшендә партия, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе **Фатыйх Сәүбән улы СИБАГАТУЛЛИН** бакыйлыкка күчте. Арча районының Апаз авылында туып-үскән малай үз тырышлыгы белән һәр вазыйфасында фидакярлек үрнәге күрсәтеп эшләде. Аерым хуҗалыклар, районнар белән җитәкчелек итте, республиканың бик тә җаваплы тармагы – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры вазыйфасын башкарды. Татарстаннан Дәүләт Думасы депутаты булып торды.



күңелендә калдыгыз...

Июнь ахырында Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (1998), Дамир Сиражиев исемендәге премия лауреаты. **Тамара Сөләйман кызы ХАЛИТОВА** якты дөньядан китте. Т. Халитова 1947 елның 7 апрелендә Сарман районы Иске Минзәләбаш авылында туа. 1992 елдан мәдәният өлкәсендә эшли: Әлмәт районы Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы директоры, Әлмәт районы һәм шәһәре мәдәният идарәсе башлыгы урынбасары, туган якны өйрәнү музее җитәкчесе була. 1995 елның декабрь аеннан 2002 елга хәтле Әлмәт татар дәүләт драма театрын җитәкли.

Июль уртасында татар театры дөньясы зур югалту кичерде. Г.Камал театрының танылган актрисасы, Татарстанның халык артисты **Раушания ЮКАЧЕВА** вафат булды.

Раушания Хөснетдин кызы 1959 елның 18 февралендә Питрәч районының Күн авылында туа. 1981 елда Казан театр училищесын тәмамлый һәм Әлмәт театрында эшли башлый. 1983 елдан – Татар академия театрында. Кабатланмас үзенчәлекле табигый таланты, киң сәхнә диапазоны, нечкә сиземләве һәм шәхси сыйфатлары аңа гаҗәеп тормышчан образлар тудырырга мөмкинлек бирде. Раушания Юкачеваның җәсәде туган авылы Күн зиратында җир куенына иңдерелде.

Татарстанның халык артисты, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, композитор **Анатолий Борисович ЛУППОВ та** арабыздан мәңгелеккә китте.



Ул 1954 елдан башлап, 64 елдан артык, Н.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясендә укытты. 22 ел композиция кафедрасы мөдире, музыка һәм композиция теориясе кафедрасы профессоры булды. Аның иҗатында опера һәм балет зур урын алып тора.

17 сентябрьдә график, Россиянең атказанган рәссамы **Рәшит Әскәр улы ГОСМАНОВ** вафат булды. Р.Госманов 1937 елның 4 августында Казанда туа.

Казан, Чабаксар сәнгать училищеларында укый. 1970-1980 елларда СССР буйлап рәсем сәнгате осталарының иҗат төркеме составында бик күп сәяхәт ясый. 1996-1997 елларда Сан-Франциско шәһәрендә яши һәм эшли. Бөтенроссия күргәзмәләрендә, халыкара күргәзмәләрдә катнаша.

Сентябрь уртасында шагыйрь, күп кенә популяр җырлар авторы, танылган эшмәкәр, Татарстан Дәүләт Советының экс-депутаты **Илсур ХӨСНЕТДИНОВ** вафат булды. Татарстанның Арча районы Сикертән авылында туган И. Хөснетдинов күп еллар «Казан» совхозын, «Салмачы» ширкәтен җитәкли, 1998 елда «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исемгә лаек була.

Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты сентябрь ахырында танылган әдәбият галиме, профессор, институтның 2001-2006 еллардагы директоры **Нурмөхәммәт Шаһвәли улы ХИСАМОВ** белән хушлашты.

Н.Хисамовка 85 яшь иде. Ул Татарстанның Чүпрәле районында дөньяга килә. Казан дәүләт университетын тәмамлагач, «Коммунар» редакциясендә эшли, аннары аспирантурада укый. 1980 елның апрелендә ул «Кыйссаи Йосыф» поэмасына багышланган кандидатлык диссертациясен яклый. Гомумән, Кол Гали иҗатын өйрәнүгә аеруча күп көч куя. 1967 елда «Яз миңа чәчәкләр китерә» дигән мөстәкыйль җыентыгы дөнья күрә. Татарстанның атказанган фән эшлеклесе. Халыкара төрки академиянең хакыйкый әгъзасы Н.Хисамов әдәбият белеме һәм әдәби тәнкыйть өлкәсендә дә эшли.

Күренекле татар шагыйрәсе, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе **Резеда ВӘЛИЕВА** 92 яшендә бакыйлыкка күчте.

Башкортстанның укытучылар гаиләсендә туып-үскән Резеда урта мәктәпне тәмамлагач, Казанга килә, Университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Бирадә диплом алып чыккач, 1952-1986 елларда, 34 ел дәвамында Татарстан китап нәшриятенең үсмерләр һәм балалар редакциясендә эшли. Р.Вәлиеваның беренче шигырьләр җыентыгы 1960 елда дөнья күрә. Ике дистәдән артык китап авторы. Аларда шулай ук җырлар, әкиятләр, хикәяләр, сәхнә әсәрләре, табышмаклар да тупланган.

Октябрь аеның соңгы көнендә республиканың иң сәләтле театр артистларыннан берсе – **Наил ДУНАЕВ (Николай Иванович Дунаев)** вафат булды.



1961 елда Мәскәүдә М.С.Щепкин исемендәге югары театр училищесын тәмамлагач, ул Г.Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында эшләде, күп кенә төп рольләрне башкарды. Н.Дунаев Г.Тукай, М.Җәлил премияләре лауреаты, Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты иде. Н.Дунаев артист хезмәтен башкару белән бергә Казан мәдәният һәм сәнгать университетында шәкертләренә дәресләр бирде, күпсанлы артистлар әзерләде. Буш вакытларында умартачылык белән дә шөгыльләнде.



Ноябрь уртасында күренекле галим, Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы, техник фәннәр докторы, Казан илкүләм фәнни-тикшеренү техник университетының (КАИ) гомуми физика кафедрасы профессоры **Гали Юныс улы ДАУТОВ** вафат булды. Ул өйрәнгән түбән температуралы плазма бүгенге көндә плазмотроннарда, нанотехнологияләрдә, тузган детальләрне яңартуда, көндезге яктылык лампаларында, лазерларда, декоратив һәм функциональ пленкалар булдыруда һәм бик күп башка өлкәләрдә кулланыла. Татар җәмәгатьчелеге Гали Даутовны 90нчы елларда милли мәгарифне торгызуда иң зур өлеш керткән шәхес дип тә белә.

Октябрь ахырында журналист, «Таң» газетасы баш мөхәррире, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре **Эльмарт Шәйхи улы УРАЗОВның** үлеме турында хәбәр килде.

1955 елда Пермь өлкәсе Барда районы Бакчавыл (Чалкау) авылында туган Э.Уразов Казан дәүләт университетын журналистика белгечлеге буенча тәмамлагач,1977 елдан Барда районы «Таң» газетасы редакциясендә эшли. 1993 елның сентябреннән баш мөхәррир вазыйфаларын башкара. Пермь крае татарларының «Халык чишмәсе» газетасын чыгаруга күп көч сала, аның баш мөхәррире була.

Елның соңгы аенда шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе, күпсанлы популяр җырлар авторы **Мансур ШИҺАПОВ** вафат булды.

Мансур Әхмәт улы Шиһапов 1940 елның 1 маенда Балык Бистәсе районы Яншык авылында туа. В.Качалов театры каршында оешкан театр студиясендә белем ала, Казан театр училищесын һәм Казан дәүләт университетының журналистика бүлеген тәмамлый. М.Шиһапов күп кенә еллар дәвамында Курчак театры, К.Тинчурин, Г.Камал театрлары директоры урынбасары, С.Сәйдәшев исемендәге Дәүләт зур концерт залының директоры булып эшләде.

Елның соңгы аенда популяр эстрада җырчысы, Татарстанның атказанган артисты **Эльмира СӨЛӘЙМАНОВАның** кинәт үлеме турында хәбәр ирешә.

Халык арасында «Синең белән», «Сайрамый шул күңел кошым», «Минем язым син икән» кебек җырлары белән популярлык казанган Эльмира 1982 елның 5 февралендә Чаллы шәһәрендә туа. 2016 елда TMTV каналында «Тамашачы мәхәбәте» бүләгенә лаек була. «Татар җыры» конкурсында лауреат исемен яулый.

Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, М.Сәлимҗанов исемендәге премия лауреаты, Минзәлә театрын 28 елдан артык җитәкләгән **Роберт Шәйхел улы ШӘЙМӘРДАНОВ** 19 декабрьдә арабыздан китеп барды.

Ул 1963 елның 23 гыйнварында Мөслим районының Татар Шуралы авылында туа. Алабуга мәдәни-агарту училищесын, Казан мәдәният институтын тәмамлый. Аннан соң 1992 елда Р.Шәймәрданов Минзәлә драма театрының директоры итеп билгеләнә. Театрның матди-техник ягын үстерүгә бик зур тырышлык куя.

Әгъзам ФӘЙЗРАХМАНОВ.

Мәдәни җомга
23 декабрь
№50, 2022

Яшәү белән үлем арасында

(Автобиографик повестьтан)

Нәби ДӘҮЛИ

Сугышның икенче көнендә үк миңа да военкоматтан повестка килде. Инде кичке якта безнең эшелон юлга чыкты. Вокзалда меңләгән куллар, яулык болгый-болгый, безне озатып калды. Без фронтка киттек.

Мин сугышта гади солдат идем. Алдан ук әйтеп куям: ул вакыттагы сугыш стратегиясен тикшерергә яки тәнкыйтьләргә җыенмыйм. Бу минем хәлдән килерлек эш түгел. Ләкин мин шунысын ачык белә идем: бу сугыш безгә көчләп тагылды. Без үз җиребезне дошманнан сакларга, туган халкыбызның азатлыгын якларга гадел сугышка чыктык. Без, теләмәсәк тә, үтерергә тиешле булдык. Югыйсә безнең үзебезне үтерәчәкләр иде. Коллыкка төшкән илдә безгә нәрсә кала иде соң? Хурлыклы газап та сыкрау! Совет солдаты үзенең кечкенә генә окобында менә шулай зур уй йөртте, үзенең соңгы минутына кадәр туган илгә тугрылыклы булып калды.

Сугыш башланганда, көчләр тигез түгел иде. Моннан бер генә ел элек Россия белән Германия арасында төзелгән килешү пактын Гитлер сугышка әзерләнү өчен генә файдаланган. Дөресрәге, палач, шул пакт пәрдәсе артына качып, балта кайраган. Сугышның шулай мәкерле юл белән башлануын беркем дә көтмәгән иде, билгеле. Шул сәбәпле сугышның беренче елы Россия тарихында әле күрелмәгән авырлыклар аша барды.

Шул көннәрдә мин меңләгән иптәшләрем белән Белоруссия кырларында дошман чолганышында калдым. Ләкин бу җиңелү түгел, сугышның бер моменты яки вакытлы бер хәле генә иде. Сугышта йөргән кеше моны яхшы белә. Сугыш һәр көнне яңа эз белән бара. Бүген солдатка котылгысыз булып күренгән хәл иртәгә бөтенләй киресенчә булуы мөмкин. Безгә шунысы билгеле иде: дошман безне чолгап алган, чигенү юлларын бикләгән. Тик бу әле бар да бетте дигән сүз түгел. Чөнки без үз җиребездә аяк басып торабыз. Тирә-ягыбызда үз авылларыбыз, үз халкыбыз яши иде.

Билгеле, сугыш корбансыз булмый. Аны солдат сугышка китәргә повестка алган көнне үк иенә төшерә. Ләкин, әсир булырмын дип, мин уйлый да алмый идем. Киресенчә, дошман безнең җиребездә үзе әсир калган кебек тоела иде миңа.

Чыннан да, әле сугышның беренче айлары гына. Безнең армия үзенең көчен җәеп җибәрергә өлгермәгән. Безне чолганыштан коткарулары мөмкин кебек иде. Дошман армиясе әле үзе чолганышта калмагае дигән фикер безнең күңелләрдә озак яшәде. Сугыш тарихында шундый хәлләр дә булгалаган. Безнең өмет киселмәгән. Үзебезнең армиягә кушылу ышанычы безне юата һәм безгә көч бирә иде.

Без чолганышта күбәү идек. Минем кайбер окопташларым әле ул вакытта ук илгә кайта алганнардыр, яңадан үзебезнең армия белән сугыш юлыннан Берлинга кадәр барып җиткәннәрдер. Ләкин мин башка язмыш белән очраштым. Мин дошман кулына эләктем һәм шул көннән алып бик озак вакытка «хәбәрсез югалып» калган идем. Бу сүзләрне язарга түгел, әйтергә дә авыр. Нишлисең, бу турыда сөйләмәскә мөмкинме соң? Шунсыз мин тыныч кына яши дә алмам, тыныч кына үлә дә алмам.

Яшь кеше!

Син минем яшемә җиткәндә, мин инде җирдә булмам. Бу котылгысыз аерылу алдыннан мин сиңа кечкенә генә хат язып калдырам.

Син әле мәктәптә укыган көннәрдә үк җирнең тарихы белән, халыкларның тормыш юллары белән танышырсың. Синең күз алдыңнан бик еракта калган гасырлар узып китәрләр. Нинди генә исемнәрне күрмәссең син ул тарих битләрендә! Нинди генә хәлләрне очратмассың син ул чорларда!

Ниһаять, син шулай, тарих битләрен берәмләп ача-ача, безнең гасырга, без яшәгән чорга килеп җитәрсең. Һәм син анда «фашист» дигән сүзне күрерсең.

Кем иде соң ул фашист?

Мин сиңа шул турыда сөйләргә телим.

Хәтеремдә: ул көн болытлы иде. Аз гына яңгыр сибәләп тора. Тирә-якта Белоруссия кыры. Урылмаган игеннәрнең башлары түбән иелгән. Алар шулай моңланып, җирнең кайгылы зарын тыңлап торалар кебек. Юл буенда һәм кырда янган машиналар, танклар аунап ята. Арыш арасыннан зенитка көпшәләре күренеп кала. Күз күреме җитә алган һәр җирдә окоплар, базлар һәм балчык өемнәре зур-зур каберләргә охшап торалар. Урманнар өстендә төтен болытлары асылынган, янып каралган агачлар күңелгә авыр моң салалар.

Моннан кичә генә сугыш узган. Кая гына карасаң да, үлгән иптәшләрнең гәүдәләре ята. Алар, күккә карап, гүя кемнедер көтәләр. Алар өстендә инде каргалар өере оча. Ә еракта туплар гөрселдәве ишетелә. Кургаш төсле авыр соры болытлар эчендә яшен ялтырап китә. Һавада самолётлар гөрләве яңгырый. Сугыш үзенең юлын дәвам итә. Сугыш җирдәге бар тереклекне ут белән кырып бара, артыннан көл генә кала.

Без ике яклап юл читеннән барабыз. Ә юлдан немец танклары, солдатлар төялгән машиналар уза. Танкларның күбесенә немец солдатлары сырышкан. Алар шат. Безнең өстебезгә тәмәке төпчекләре атып китәләр. Кайберләре карбыз кабыклары ыргыта. Үзләре ниндидер хайван тавышы чыгарып көлешәләр.

– Русски, капут-капут! – дип акыралар.

Менә бик түбәннән генә самолёт очып үтә, колоннаны буйдан-буйга күзәтеп уза. Түбәннән аңа немец солдатлары нәрсәдер кычкыралар, кул болгыйлар.

Минем белән янәшә баручы бер иптәш:

– Безнең өстә очарга зур кыюлык кирәкми, син әнә тегендә, фронтка бар, канатыңны өтеп җибәрерләр иде синең, – ди.

– Юк шул, юк, өтмиләр. Өтсәләр, биредә киерелеп очып та йөрмәс иде ул. Күрәсең, алар көчле әле, – ди икенче иптәш.

Сүз шуннан артыкка сузылмый. Кем көчле дә кем көчсез – хәзер каян беләсең? Хәзер бу турыда сөйләшүнең нигә кирәге бар? Без инде әсирләр. Безне каядыр алып баралар. Колоннаның як-ягыннан немец солдатлары безгә мылтыкларын төбәгәннәр. Күбебезнең аягыннан итекләре салдырылган, ремеңнәр алынган, тик кайберәүләрдә генә противогаз сумкалары калган. Күбебез яланбаш. Барыбызны да сакал баскан. Читтән караганда, без бик карт булып күренәбездер, мөгаен. Ләкин безнең иң картыбыз да утыздан узмагандыр. Ә күбебезгә егерме ике-егерме биш яшь.

Без бер бүлмәдә утызлап солдат идек. Әле бер-беребезнең исемнәрен дә белмибез. Төрлебез төрле частьлардан. Биредә разведчиклар да, артиллеристлар да һәм пехотачылар да бар. Авыр язмыш безне бик тиз берләштерде. Без тиз арада бер-беребез белән танышып өлгердек. Бер-берең белән ачыктан-ачык сөйләшү мондый вакытта бик кирәк. Без дошман кулында, һәм безне, бәлки, иртәгә әллә нинди язмыш көтәдер. Мондый көннәрдә янындагы иптәшеңнең кем булуын белергә теләвең аңлаешлы хәл.

Барысы да әйтелде, тик бер генә нәрсә турында сер ачылмый калды: ул да булса – кемнең коммунист яки комсомолец булуы. Бу хакта беркем дә сорашмады, һәркемнең бары тик үз йөрәгендә генә сакланырга тиешле сер иде бу. Әле алда газаплы сынаулар аша үтәсе бар. Анысы көн кебек ачык. Мондый чакта кешенең андый серләрен башкаларның белми торуы хәерлерәктер.

Барыннан да элек, милләтебез нинди булуга карамастан, немецлар каршында без рус солдатлары идек. Бу авыр көннәрдә шул уртак исем безнең дуслыгыбызны тагын да ныгытты.

Минем белән янәшә сары чәчле яшь кенә солдат утыра. Бер кулын бинт белән бәйләп аскан. Кан гимнастёрка җиңе аша саркып чыккан, ярасыннан яман ис килә. Кәефе начар, бөтенләй сөйләшми. Ара-тирә авыр сызланып куя, йөзен җыера, янып көйгән иреннәрен теле белән ялап ала.

– Хәлегез авыр, ахры? – дидем мин аңа.

– Җиңел түгел, – диде ул, елмаерга тырышып.

– Ярагыз зурмы?

– Кулбашын осколка китеп алды, нәләт төшкере, – диде күршем, йөзен җыерып.

Без танышып киттек. Бу солдат минем якташ булып чыкты. Ул сугышка кадәр Юдино станциясендә депода эшләгән. Мин дә аңа Казаннан икәнлегемне әйттем.

Бу хәбәр аның йөзен ачып җибәрде. Мин дә сөендем. Чөнки мондый вакытта якташыңны очрату – әйтеп бетермәслек бәхет ул.

Иптәшемнең исеме Миша иде.

– Ә синең исемең ничек? – дип сорады ул.

– Нәбиулла.

– Димәк, татар. Башта ук шулай уйлаган идем. Якташларны таныйм мин…

Миша авыз эченнән генә минем исемемне әйтеп карады.

– Авыр исем, тиз онытыла. Мин сине Николай дип йөртермен.

– Нигә Николай, нигә Павел түгел?

– Юк, Павел ярамый. Чөнки синең исемең «Н» га башлана. Димәк, Николай була.

Шул көннән алып мин башка иптәшләрем өчен дә Николай булып калдым.

– Тәмәке тартасыңмы? – диде Миша.

– Бик тартасы иде дә, юк, бетте.

– Ә мин тартмыйм. Шулай да тәмәкем бар. Мин бүтән вакытта үз порциямне иптәшемә бирә торган идем. Ә ул…

– Үлде, – дидем мин.

(Ахыры киләсе санда).

БӨРКЕТ ЯЛГЫЗ ОЧА

Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Исхакый, Җ.Вәлиди һәм Һ.Атласи исемендәге әдәби бүләкләр иясе, Җирдә кешелеклекне яклаучылар конференциясенең «Ак лачын» халыкара ордены кавалеры Айдар Хәлимнең 80 яшьлек юбилей кичәсе Казанның «Сәйдәш» мәдәният сараенда үтте.

А.Хәлим иң элек көчле публицист һәм Татарстанда милли хәрәкәт лидерларының берсе буларак билгеле. Аның «Өч аяклы ат» әсәре буенча режиссер Нурания Җамали куйган фильмны хәтерлибез. А.Хәлим – күп проза китаплары авторы, һәм ул яхшы прозаик буларак кадерле.

Әмма бу юлы кичәне оештыручылар аны эти кеше һәм шагыйрь буларак ачу максаты куйган. Программада җырлар күп яңгырады – аларның күбесен А.Хәлимнең кызы Зөлфия Тәхаветдинова язган. Шуңа да бу кичә, ялкынлы публицист һәм милли күтәрелеш лидерын күрсәтүдән бигрәк, шәхеснең гаилә җылысын, ата белән балалар мөнәсәбәтләрен чагылдырган мәҗлес иде. Без милләткә 3 талантлы кыз бала үстергән атаны күрдек. Бер үк вакытта аның 2000 ләп шигырь язган шагыйрь булуын да онытмадык.

А.Хәлим кичә барышында безне дулкынландырырдай сүзләр әйтте: «...Мин арбада барам... Бөтен дөнья зәп-зәңгәр... Минем алдыма корама юрган салган, уң кулыма – кашык, сул кулыма калай тәлинкә тотып, Балалар йортына барып ятам. Мин шушы вакытта 80 яшемә җитәрмен, сезнең белән очрашу насыйп итәр дип уйламый идем».

Бөтендөнья татар конгрессының башкарма комитет рәисе Данис Шакиров та җылы сүзләрне һич кызганмады: «Һәр милләтне шәхесләр билгели. Татар тарихында тирән эз калдырачак Айдар абый – шундыйлардан. Иҗатына килгәндә, ул бик үзенчәлекле һәм киңкырлы шәхес. Әмма аның татар җанлы булуына басым ясар идем. Бигрәк тә Башкортстан татарларының мәнфәгатьләрен яклаучы сез булдыгыз. Бер шигырегездә: «Тормыш мине шактый суккалады», – дип яздыгыз. 80 яшегездә мәркәзебезнең иң матур залларының берсендә елмаеп утырасыз икән, димәк, тормышыгыз заяга узмаган».

Татарстан Язучылар берлеге рәисе, халык шагыйре Ркаил Зәйдулла да сәхнәгә күтәрелде: «Сезгә шәмаил бүләк итәм. Корьәни-Кәримдә «Шагыйрьләр» дигән сүрәне искә төшерик. Мөхәммәд галәйһиссәләмгә дошманнары: «Син пәйгамбәр түгел, шагыйрь генә», – дип нахак яла яккач, Аллаһтан шагыйрьләр турында вәхи иңә. Анда: «Шагыйрьләрнең колагына Иблис пышылдый, һәм алар сахрада үзләре дә саташып, кешеләрне дә саташтырып йөри», – диелгән. Ахырында безнең өчен юаныч булган сүзләр бар: «Әмма араларында иман китергәннәре дә бар. Аларның сүзенә колак салырга кирәк». Айдар абый – шундыйларның берсе. Рәхмәт сиңа яшәвең вә иҗатың өчен! Ул үзенең кем икәнен белә. Үзенә сыйфатламаны барыбызга караганда да әйбәтрәк итеп әйткән. Аның сүзләрен кәгазьдән карап укыйм: «Мин үзем турында татарның киләчәге булган һәм, һичшиксез, Тукай йолдызлыгыннан булган зур шагыйремен дип уйлыйм. Мин бүген – татарның иң күп укыла торган шагыйре, прозаигы... Минем үземне болай итеп тануымнан миңа күңеллеме соң? Юк. Күңелсез, ай-һай, моңсу миңа! Миңа иптәшкә тагын бер-ике, өч-дүрт язучы табылса, әйбәт булыр иде!»

Сәхнәгә Башкортстандагы якташлары исеменнән Миякә районы мәдәният бүлеге җитәкчесе Хәлил Махиянов, Уфа шәһәренең «Ихлас» мәхәллә җыены рәисе Мөхәммәт хәзрәт Галләмов чыгып басты. Хәлил әфәнде Айдар абыйга районташлары Айдар Галимов, Нурия Ирсаева, җитәкчеләрдән сәлам тапшырса, Мөхәммәт хәзрәт үзгәрмәс турылыгы белән ярып салды: «Безнең алда чыгыш ясаган Данис Шакиров бөркет, дип олылаган иде, Айдар абый үзен «ялгыз», диде. Әйе, караңгылык – ятлыктан, ялган тугрыдан кача. Мин ялгыз, дип өзгәләнмә, агай, каргалар – көтү белән, ә бөркет ялгыз оча».

Сәхнәгә Камал театрының 3 легендар артисты – Равил Шәрәфиев, Әзһәр Шакиров һәм Илдус Әхмәтҗанов чакырылды. Күңелләрендә каһарман әдипкә багышланган сүзләре күп иде, берсе Айдар абыйны халыкара әдәби бүләкләргә тәкъдим итәргә чакырды, икенчесе әдипнең рус теленд гаҗәеп камил иҗат итә алуына соклану белдерде. Күмәк фикерләре дә матур яңгырады: «Айдар туган, син – алтын каләм әһеле, син – каһарман!»

Кичәне алып баручы Фәнис Җиһанша тамашачыларга яңа мәгълүматлар да җиткерде: «Айдар Хәлим – 3 баланың бәхетле атасы. Өч кыз – өч тормыш чәчкәсе: Илсөяр, Зөлфия һәм Кадрия. Өлкән кызы Илсөяр Казанда туып, Түбән Камада үсә. Казан дәүләт мәдәният институтының Театр режиссурасы һәм актерлык бүлеген тәмамлый, гимназиядә актерлык осталыгы дәресләре алып бара. Гаиләсе белән Казанда яши. Уртанчы кызы Зөлфия, Уфада сәнгать көллиятен тәмамлап, Казан дәүләт консерваториясендә Татар музыкасы һәм этномузыкология бүлегендә белем ала. Музыка белгече. Уфада яши. Кече кызы Кадрия Чаллы шәһәрендә туып-үсә. Казан федераль университетының Төрки-мөселман дөньясының сәнгать тарихы юнәлеше буенча укып, әлеге вакытта аспирантурада укый. Татар халкының дәүләтчелеге тарихы музеенда эшли».

Айдар Хәлим язганнардан юллар: «Минем язмыш гаҗәеп булып чыкты. Өчегез өч анадан тудыгыз. Өч сеңелкәш, гүя бер анадан туган кебек. Мин рәхмәтле сезгә биргән өчен бертуганлык дигән сәнгатьне... Мин сезләргә җиһан бүләк итәм, белеп тотсагызчы кадерен».

Концертта А.Хәлим шигырьләрен Тинчурин театры артистлары Зөфәр Харисов һәм Ирек Хафизов укыды. Кичәдә җырларны Руслан Сәйфетдинов, Алинә һәм Азат Кәримовлар, Сәйдә Мөхәммәтҗанова, Алмаз Хөсәенов башкарды. Аналы-уллы Гүзәл һәм Арслан Сибгатуллиннар чыгышы кичәгә ямь өстәде. Концерт буена сәхнәдән «Казан нуры» оркестры төшмәде.

А.Хәлимнең «көрәшче холкын» ачып бирү өчен сәхнәгә Чаллы җырчысы Флера Талипова-Коләхмәтова чыкты. Концерт, әлбәттә, шагыйрьнең «Без исән!» җыры белән тәмамланырга тиеш иде. Бас-баритон тавышлы Рөстәм Насыйбуллин ошбу рухка бик тә тәңгәл килде.

Кичәне продюсер Рөстәм Сәрвәров командасы оештырган, режиссеры – аның хатыны Әлфия Һадиева.

Рузилә МӨХӘММӘТОВА,
intertat.tatar.

«Самавырлар җырласын, халкым моңы тынмасын!»

2022 ел – Россия халыклары мәдәни мирасы елы кысаларында татар халкының мәдәниятенә мәхәббәт тәрбияләү, көнкүрешенә игътибарны арттыру, борынгы йолаларыбызны, халкыбызның ихласлыгын, юмартлыгын, уңганлыгын чагылдырган кунакчыллык йоласын саклау, ихтирам итү максатында, Теләче районы Айдар авылы мәдәният хезмәткәрләре «Самавырлар җырласын, халкым моңы тынмасын!» дип исемләнгән фольклор кичә уздырдылар. Китапханәдә кичәбезнең бизәге булып, әби-бабайларыбызның мирасы булган самавырлар, китаплар, табышмак-мәкальләр урын алган «Чәй өстәленең матурлыгы һәм горурлыгы ул – самавыр» күргәзмәсе тәкъдим ителде.

Халкыбыз самавырны рухи кыйммәтләргә тиңли. Тарихтагы иң катлаулы чорларда да туган нигезен ташлап китәргә мәҗбүр булган кешеләр үзләре белән самавыр һәм китап алган. Кичәбез кунаклары – берләшмәләргә йөрүчеләр балачагында әти-әниләренең ничек самавырга салып йомырка пешерүләрен, аның ярдәмендә ничек итеп бөгәрләнгән тасмалар һәм пионер галстукларын «үтүкләү»ләрен искә алдылар, үзләре алып килгән самавырларның тарихлары белән таныштырдылар.

Кичәгә тәкъдим ителгән экспонатлар формалары, бизәлеш төрлелеге, декорның үзенчәлекләре белән аерылып тора иде. Барлыгы 14 самавыр тәкъдим ителде, шуларның иң борынгысы 1912 елда, ә иң яңасы 2019 елда эшләнелгән. Кичә самавыр турында мәкальләр, табышмаклар әйтешү, яшьлек хатирәләрен яңартып, халкыбызның моңлы җырларын җырлау, шигырьләрен уку, кызыклы уеннар белән үрелеп барды. Гел шулай самавырлар җырлап торсын, халкым моңы тынмасын, борынгы йолаларыбыз онытылмасын!

Алсу ФӘЛӘХОВА,
китапханәче.
Теләче районы



Кылкаләм остасы Әлфия

Борынгы бабаларыбызның сәнгатькә сәләте тәрәзә йөзлекләрендә, йортлар бизәлешендә, чигүле күлмәк-алъяпкычларда, калфакларда, тәрәзә пәрдәләрендә дә чагылыш тапкан. Татарстан рәссамнар берлеге әгъзасы Әлфия Нурхәмммәтованың да Аксубай районнында яшәгән ерак бабасы Сәгытдин Сәйфетдинов, аның улы Нуретдинның кулы шушы эшкә ятып тора, алар бик матур итеп тәрәзә йөзлекләре ясый. Әтисе ягыннан икенче бабасы Габдулланың да рәсем ясарга бик сәләтле булуы турында сөйлиләр. Буяулар да юк чак вакыт бит, ул күмер белән өйләрендәге мич янында ат рәсемнәре ясарга яраткан. Әтисе Рәшитнең бертуган абыйсы Фоат та кылкаләм белән дус.

● Әлфия Нурхәмматова үз картиналары күргәзмәсендә.

Нәсел тамырлары буйлап килгән сәләт-холык беркая да китми, ул барыбер спираль кебек киләчәк буыннарга әйләнеп кайта тора. Әлфиянең кулы бик кечкенәдән буяу каләмнәренә тартыла. Балалар бакчасындамы, өйдәме – сабыйның иң яраткан шөгыле – рәсем ясау. Кылкаләм остасының хәтеренә бер вакыйга уелып калган. Әтисе Рәшит кызчыкны балалар бакчасыннан ала да, авылга кайтачакларын, анда әбисе көтүен, аңа булышырга кирәклеген әйтә. Ә Әлфиянең рәсем ясыйсы килә, әтисенә әйтеп карый, ә ул һаман авылга ашыктыра. Кызчык үпкәләп, бакча башындагы таллар артына кача.

Тәрәзә йөзлекләре ясау остасы Нуретдин бабасының алар белән бергә яшәве Әлфиянең тагын бер бәхете булгандыр. Ул сөйләгән әкиятләр кызчыкны хыялый дөньяларга алып кереп китә. Бабакайга иҗат куәсе дә мулдан салынган. Дүрт ел буе концлагерь михнәтләрен кичкән, әмма күңеле каралмаган бабасы әкиятләрне үзе уйлап чыгарып сөйли торган була. Аннары Мюд авылына – әбисе янына кайтулар... Әлфиянең хәтерендә әбекәе белән бергәләп чишмәгә суга барулары, чират җитеп, болында малларны көтүдә йөртүләре, бергәләп миллек бәйләүләре бүген генә булган кебек. Ә инде кура җиләкләре пешә башлагач, аларны әбиләре, җиләк коела дип, иртүк җиләк җыярга уята.

Әлфиянең рәсем ясау осталыгы елдан-ел үсә. Мәктәптә стена газеталарын бизәү, плакатлар язу, башка сурәтләр ясау – Әлфия кулында, аны шушы осталыгына күрә Артекка да җибәрәләр. Кыз үзе дә кызыксынучан, ул мәктәптә укыганда ук, рәссамнарның киндерне ничек тартуын китаплардан укып өйрәнә, майлы буяулар белән рәсем ясау техникасын үзләштереп, беренче картиналарын тудыра.

Әлфия Нурхәмматова Лениногорск сәнгать-педагогика училищесында яхшы остазлар кулына эләгә. Шәһәр балалары рәсем сәнгате мәктәбен тәмамлап килгән. Ләкин тәҗрибәле укытучы, сез авыл кызлары әле аларны узып китәчәксез, дип рухландырып тора. «Шулай булды да, кызыл дипломга тәмамладык», – дип искә төшерә Әлфия ханым. Аннары Чаллы педагогика институтының художество-графика факультетында белем алу... Әмма эзләнүнең тукталганы юк. Ясалган картиналар тулысынча канәгатьлек китерми, нәрсәнедер эшләп бетерәсе бар кебек. Ә.Нурхәмматова, картина 3-4 ел эленеп торгач та, аны киредән төшереп, аңа нәрсәдер өстәргә мөмкин. Вакыт узгач, рәссам үзенең иҗатына да икенче төрле карый башлый бит.

Күңелендә тулып ташыган хисләр җанга тынгылык бирми торган халәт. Ә инде күз алдыңа картина булып килеп баскан уйларыңны киндергә төшерү тирә-як дөньяны, мәшәкатьләрне оныттыра, күңеленә кергәне картина булып киндергә ятса, кәеф тә күтәрелеп китә. Аның бу эше кешегә ошыймы-ошамыймы, бу әлегә иҗатчыны борчымый. Бер тапкыр көзге кояшлы көндә Әлфия үз бакчаларында кып-кызыл җимешләре белән «янган» миләш агачына игътибар итә. Яфраклары – сап-сары. Рәссамның шушы матурлыкка күзе төшә дә ул бар дөньясын оныткандай итә. Ә аның район туган якны өйрәнү музеенда директор чагы, эшкә барырга кирәк. Хис-тойгыларын йөгәнләп чыгып китә. Кабинетына барып утыра, кулы эшкә йокмый. «Ике сәгатькә китим, этюд ясап киләм», – ди ул хезмәттәшләренә. Әлфиянең иң яраткан темасы исә – кояш кебек сап-сары көнбагыш чәчәкләре. Ул аларны ел саен үзе утырта һәм картинага төшерә. «Мин аларны ел да икенче төрле күрәм», – ди ул.

Без Ә.Нурхәмматованың бу көннәрдә дә Кооперация институтының татар мәдәнияте үзәгендә бара торган күргәзмәсен тамаша кылабыз. Йөзләрчә картиналар арасында төрле темага, төрле жанр белән ясалганнары бар, табигать күренешләре, натюрмортлар да урын алган. Әнә, Г.Тукайның «Тау башына салынгандыр безнең авыл» дигән шигъри юллары буенча иҗат ителгән картина. «Нурлы җомга» дип исемләнгәне исә сәгадәтле татар тормышын күз алдына китереп бастыра. Әбекәй картын җомга намазыннан көтә. Ул менә-менә кайтып керергә тиеш. Бәлеш мичтән алынган, чәйләр дә ясалган. Бер почмакта – мендәрләр өйгән сәке, шамаил, сандык, аның янында комган күренеп тора. Ә бер картина «Шәһребану» дип исемләгән. Аны рәссам Шәрбән авылында туган Әнвәр Хәйригә багышлап эшләгән. Ул тарихи вакыйгаларны искә төшерә. Элек Шәрбән авылы урынында Шәһребану дигән шәһәр булган. Аның аша Биләргә кәрваннар юл тоткан. Кәрваннар Шәһребану-Шәрбәндә туктап, ял да иткән. «Самавыр» картинасы исә әбекәйләребезнең самавырдан чәй эчәргә яратуы белән бәйле. Әлфия ханымның әбисе дә чәйне чыжлап кайнап торган самавырдан ясап эчәргә яраткан. «Әбием гөлләре» дип исемләнгән мальва чәчәкләре төшерелгән картина авыл гөлбакчалары белән бәйле. Туган якларыбызда андый чәчкәләр авылларга ямь бирә иде. «Аларны хәзер үзем дә үстерәм», – ди Әлфия ханым. Татар Тинчәлесе авылына багышланган картинада елга янындагы тирәлек сурәтләнә. Бу – ястү намазы вакыты. Көтүләр кайткан, маллар ябылган, өйләрдә утлар кабынган, мәчеткә картлар җыелган. Ислам динен рәсми кабул итүгә 1000 ел тулуга багышланганында Коръән саклана торган бина югары күтәрелгән, аннан бөтен дөньяга яктылык сибелә кебек, ул – Коръәннән килгән нур. Алгы планда исә елга порты, ул шәһри Болгарга су юлы аша барлык мәмләкәтләрдән килүләрен белдерә.

Әлфия Нурхәмматова мәчетләр темасына зур серия эшләгән. Ул үзе абыстайдан дәресләр алып, гарәп графикасын да өйрәнгән.

● Дәрдемәнд исемендәге мәдәният үзәгендә.

● Дума авылы.



● Шәрбән авылы Шәһребану чишмәсендә каз өмәсе.

● Бакчасарай күренеше.

● Колакча чигү ысулы белән бизәкләнгән татар калфагы.

Аксубай районында 28 мәчет бар, аларның өчесе – архитектура истәлеге. Рәссам аларның кайберләрен икешәр тапкыр ясаган, тарихларын да барлап язып куйган. Бу – үзе аерым китапчык итеп чыгарырлык хезмәт. Аларның берсендә Яңа Думаның, ягъни Нәҗип Думави авылының мәчетен күрәбез. Хәзер инде аны үзгәрткәннәр, тышлаганнар. Яңа Үзи авылындагы мәчеттә азан тавышлары совет хакимлеге елларында да туктамаган. Мәчет манаралары киселә башлагач, авыл халкы җыелып күмәк хуҗалыкка тиз генә амбар төзеп бирә. Картинада сурәтләнгән борынгы бабаларыбыздан калган агач мәчеткә хәзер 120 елдан артык. Ул – авылның архитектура истәлеге. Картинада ерактарак яңа буяулар белән заманча корылган таш мәчет тә күренә. Кошлар да китеп бара. Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе Нәҗип Нәккаш рәссамның мәчетләрне табигатьнең төрле фасылларында сурәтләвенә игътибар итә. Аларның кояш баеганда, таң атканда, кышын агачларны бәс сарганда, яисә җәен көндезге челлә вакытындагы мәлләре кылкаләмгә алынган. Әйтик, Хәсән Туфан авылы Иске Кармәттә кичке азан яңгыраганы ишетелгәндәй була. Мюд авылындагы манзарада яз сулышын тоясың. Ә инде кышкы матур көндә иҗат ителгән мәчеткә кар кунган кып-кызыл миләшләр гаҗәеп матурлык бирә. «Картиналар татарга якын төсләр белән эшләнгән. Әлфия ханымның үз төбәгендәге авылларга йөреп мәчетләр сурәтләве – аларны тарихка теркәп калдыру да бит ул» – дип йомгаклый Нәҗип әфәнде.

Шул ук вакытта күргәзмәдә бик матур панно һәм калфаклар – борынгы татар колакча чигү техникасында башкарган эшләр игътибарны җәлеп итә. Бу техниканы Ә.Нурхәмметова үзе торгыза.

Рәссам Аксубай рәсем сәнгате мәктәбендә эшләгәндә, укучылары белән Казанга килә, Фешин исемендәге училищега да керәләр. Анда танылган чигү остасы Нурзия Сергеева белән очрашу була, ул үзенең эшләрен күрсәтә, колакча чигү буенча осталык дәресе дә үткәрә. Сәнгатьнең бу төре Әлфиянең дә күңеленә кереп кала. Аннары бу чигү турында китаплар да укый. Колакча чигү техникасы заманында искиткеч югары дәрәҗәгә ирешкән булган. Татарстан милли музеенда колакча чигү техникасы белән XIX урталарында чигелгән берничә калфак кына саклана. Колакча чигү ысулы XX гасырда юкка чыккан, аны беркем дә яңартмаган. Рәссамның колакча чигү алымына яңа сулыш бирәсе килә. Аксубайга кайткач, катлаулы үрнәкне эшләп карый, әлбәттә, бу – үтә дә четерекле, зур сабырлык таләп итә торган техника. Чөнки һәр колакча аерым бөкләнә һәм беркетелә. Әлфия ханым шулай да бер укучысы белән бергәләп панно чигә. Аны Санкт-Петербургка конкурска җибәрәләр. Бу чигеш жюри өчен зур яңалык була. Аның белән бик кызыксыналар. Нәтиҗәдә панно беренче урын яулап кайта. Бу да алга таба эшне дәвам итүгә бер этәргеч була. Рәссам колакча ысулы белән паннолар чигүне дәвам итә. Бармаклар шомара, чигү сиземлеге, тәҗрибәсе арта. Әйтик, бизәкләрнең колакчалар тыгыз урнаштырылса да, араларын киң калдырсаң да әйбәт чыкмавы ачыклана. Аннары анда төсләр бәйләнеше бик әһәмиятле.

Күргәзмәгә куелган бер паннода Идел юлы чигелгән. Аңа тармакланып киткән чәчәкләр булып елгалар кушыла. Алар Иделгә коя. Ә бер картина Татарстанның 100 еллыгына багышланган. Өстә – чәчәк. Бу республиканың чәчәк атуын күрсәтә. Шунда ук игътибарны триптих җәлеп итә. Уртада – Аллаһ сүзе. Ике якта – чәчәк. Монысы Раббыбызның матурлыкны яратуын белдерә. Панно чәчәк белән уратып алынган. Алга таба рәссам колакча чигү ысулы белән намазлык бизәкли, аны «Лә иләһә иллә Аллаһ» сүзләре белән матурлый. Инде кулы тәмам шомарган рәссам иҗатын колакча чигү ысулы белән борынгы милли калфакларыбызны, изүләрне бизәкли башлый. Алар исә матурлыгы белән теләсә кемне хәйран итәрлек. Бу инде әби-бабаларыбызның бизәкләре, чигү сәнгате киләчәк буыннарга барып җитәчәк, дигән сүз. «Затлы калфак гомергә бер алына. Шуңа да күңелемне биреп, зәвыклы итеп эшлисем килә. Ул мирас булып балаларга калырга тиеш. Изү дә шулай», – ди рәссам. Аның колакча чигү ысулы белән, матур итеп бизәп, шәмаилләр дә эшләү нияте бар. Рәссам картиналар иҗат итүдән дә аерылмый, күңеленә фикерләр килгән саен кылкаләмен кулына ала.

Ә.Нурхәмметованың картиналары Кырымда, Төркиядә шәхси коллекцияләрдә урын алган. Рәссамның шәхси күргәзмәләре Татарстан халыкларының дуслык йортында, Норлат, Чистай, Буа, Лениногорски шәһәрләрендә сәнгать сөючеләргә тәкъдим ителгән, кайберләрендә күргәзмәләре хәтта берничә тапкыр булган. Әлфия ханым Чабаксарда рәссамнар берлеге оештырган Бөтенроссия күргәзмәсендә дә катнашкан. Исламны рәсми кабул итүгә 1000 ел тулу уңаеннан уздырылган күргәзмәдә исә рәссамның колакча чигү алымы белән эшләнгән паннолары һәм калфаклары урын алган. Мактаулы кунак булып күргәзмә карарга килгән Татарстан рәссамнар берлеге рәисе Зөфәр Гыймаев рәссам иҗаты турында, «Картиналар югары дәрәҗәдә эшләнгән. Алардан нур, яктылык бөркелеп тора. Шул ук вакытта педагогның иҗади стиле дә сизелә», – дип язып калдыра.

Ә.Нурхәмметова 15 ел Аксубай сәнгать мәктәбендә укыта, галим Әнвәр Хәйринең Шәһребану кыйссасын укып, Аксубай риваятьләре белән кызыксынып китә, туган ягының олы тарихлы икәнен аңлагач, балаларны да кызыксындыра. Алар авылларының исеме, аңа кем беренче булып килеп урнашуы турындагы риваятьләрне туплап, укытучыларына сөйли. Аннары бергәләп шул хикәятләр буенча рәсем ясыйлар. Матур килеп чыга. Әлфия башта районда, аннары Казанда Сынлы сәнгать музеенда балалар белән күргәзмә эшли. Балаларның рәсемнәре югалып бетмәсен, авыл риваятьләре тарихка керсен дип, грант отып, «Ефәк юлы» дигән китап чыгаралар. Бу Аксубай районы аша кайчандыр Ефәк юлы узуын искә төшерә.

«Ефәк юлы» – рәссамның дөнья күргән беренче генә басмасы түгел. Ул үзенең нәсел тарихы турында «Гомер агышы» дигән китап та язган. Нурхәмметовларның гаилә башы – Карасу һәм Татар Сөнчәлесе авылларыннан башлана. Ул әби-бабаларының, туганнарының хатирәләрен, әти-әнисенең нәсел шәҗәрәсен өйрәнгән һәм шуларны барлап язган. Алар татар халкының Бөек Ватан сугышына кадәр, аннан соңгы авыр, михнәтле еллардагы көнкүреше турында. Әмма китап бер нәсел сәхифәләре түгел, алар аша татар халкының моңлы бер тарихы, милләтебез кичергән авыр язмыш бәян ителә.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.

● Күргәзмә ачылышыннан соң.

ГЕОСӘЯСИ УЕННАР ТУКТАМЫЙ

«Көнбатыш һәм Россия бүген, капма-каршы яктан, әмма уртак максатларда эш итә» дигән тезис үзен тулысынча аклар кебек. Һәрхәлдә, байтак фактлар шул хакта сөйли. Игътибарны геосәясәт патриархы Генри Киссинджерның Украинадагы конфликтны җайга салу буенча яңа инициативасы җәлеп итә. Күптән түгел дөнья күргән мәкаләсендә ул, әгәр Украина һәм Россия низагны хәрби юл белән яки сөйләшүләр аша җайга сала алмыйлар икән, бәхәсле территорияләрдә аларның үзбилгеләнүе турында халыкара күзәтүчеләр катнашында референдумнар үткәрергә туры киләчәк, дип белдергән. Дөрес, бәхәснең нигезендә нәрсә ятуын тәҗрибәле геосәясәтче әйтеп бетермәгән. Әлеге инициатива Кремльдә зур кызыксыну уяткан. Матбугат хезмәте башлыгы Д.Песков бу җәһәттән: «Безусловно, талант, опыт и экспертиза Киссинджера востребованы всегда», – дип сөйләгән. Кирегә сукалаулар бериш Көнбатыш илләре лидерлары (әйтик, Э.Макрон, В.Орбан һ.б.) авызыннан да еш ишетелә. Алмания канцлеры О.Шольц исә узган атнада, кайчан да булса Россия белән мөнәсәбәтләрне яңартуга исәп тотып, В.Путин белән диалог җепләрен өзмәскә чакырган.

Шул ук вакытта Көнбатыш Россиягә карата санкцияләр сәясәтен дә туктатмый. Узган атнада Европа Берлеге (ЕС) Россиягә каршы санкцияләрнең тугызынчы пакетын кабул итте. Ул үз эченә 200 гә якын физик һәм юридик затка карата чикләүләр кертүне, ЕС территориясендә Россиянең 3 телеканалы эшчәнлеген тыюны, очучысыз очкычлар җитештерү өчен кирәкле технология һәм детальләрне Россиягә кертүне чикләү кебек чараларны да ала икән. Россиягә каршы үз санкцияләрен шулай ук АКШ, Бөекбритания һәм кайбер башка илләр дә керткән.

Башка вакыйгалардан игътибарны (шул исәптә Мәскәүнең дә) АКШның Украинага Patriot зенит-ракета комплексы бирергә җыенуы, Европа парламентының 1932-1933 елларда Украинада булган ачлыкны геноцид дип тануы, Польша сеймының Россияне «террорчылыкка ярдәм итүче дәүләт» дип тануы, Европа комиссиясенең Украинага 500 млн евро күләмендә ярдәм бүлеп бирүе һ.б. җәлеп итә.

Фоат УРАЗАЙ.

«Буада өч легендар шәхес – Борһан Шәһиди, Бакый Урманче һәм Нургали Хәсәнов туган һәм без аларны хәлдән килгән кадәр күтәрергә тиеш» – диде Буа театрының директоры һәм сәнгать җитәкчесе, Татарстанның халык артисты Раил Садриев «Һөнәр» XIV Бөтенроссия яшь режиссура фестивалендә Тимур Кулов куйган «Дәрвиш» спектаклен тәкъдим итәр алдыннан.

Татарстанның халык артисты Раил Садриев.

Дин белгече Нургали Хәсәнов.

Буа «Дәрвиш»е

Буа мәдрәсәсенең хәзерге күренеше.

Кытайда зур дәүләт эшлеклесе булган Борһан Шәһиди исеме күпләребезгә мәгълүм. Олуг рәссамыбыз Бакый Урманче турында хәтерне дә әледән-әле яңартып торабыз. Күптән түгел Бакый аганың 120 еллыгы уңаеннан Буада зур галимнәребез, рәссам, сәнгать белгечләре катнашында берьюлы дүрт өр-яңа китапның презентациясе оештырылуы да, өр-яңа музей булдырырга омтылулары да бу аларның данлыклы якташларын онытмавын раслый. Нургали Хәсәновның исеме исә соңгы вакытларда гына киң җәмәгатьчелеккә кайта башлады. Моңа тарих фәннәре кандидаты Рәшит Амишовның Ш.Мәрҗани институтында әзерләп чыгарган китабы сәбәп булды. Әлеге басма Буада «Апас-Тәтеш-Буа – мәдәни дуга» халыкара сәнгать фестивале кысаларында зурлап тәкъдим ителгән иде. Аны укып, Буа халкы да, киң җәмәгатьчелек тә Оренбургның Госмания, Казанның Касыймия мәдрәсәләрендә белем алган затлы морзалар нәселен дәвам итүче Нургали Хәсәновның Буада 30 еллап мәдрәсә җитәкләвен, бик күп талантлы шәкертләр тәрбияләвен, егермедән артык дини әчтәлектәге хезмәт язып калдыруын, тырышлыклары өчен Николай патша кулларыннан көмеш һәм алтын медальләр кабул итеп алуын, Госманлы солтаны Габделхәмит II тарафыннан 1 нче дәрәҗә «Госмания» ордены һәм 300 лира белән бүләкләнүен, дәүләт эшлеклеләре белән бергә хаҗга җибәрелүен белде. Буаның үз заманында зур дини үзәк булганын 1850 елда салынган һәм бүгенгәчә сакланган таш мәдрәсә бинасыннан һәм Иске зираттагы гарәп язулы кабер ташларыннан да чамаларга була. Нургали Хәсәновны олылап, төреклә дә ике китап нәшер иткән. 170 еллыгы уңаеннан без дә Буада зур

фәнни конференция уздырдык. Киләчәктә Буа урамнарының берсенә Нургали Хәсәнов исемен бирү, сынын кую да ниятләнә.

Буаны зур театр үзәгенә әйләндереп, халыкара дәрәҗәдәге театр фестивальләре, иҗат лабораторияләре үткәрүче, хәтта шуларның берсенә күренекле актер Сергей Безруковны китертүгә ирешкән, гомумән, туган төбәге өчен җанын фида кылырга әзер Раил Садриев Нургали Хәсәнов шәхесенә битараф калса, гаҗәп булыр иде. Ул яшь режиссер Тимур Кулов белән «Дәрвиш» исемле спектакль куйган. Тамаша тулыр-тулмас бер сәгать кенә дәвам итеп, анда нибары бер генә артист – Р.Садриев үзе уйнаса да, күренекле дин эшлеклесенең тормышына һәм эшчәнлегенә якынаерга мөмкинлек биргән бу спектакль фестивальдә зур кызыксыну уятты. Сәхнәгә өстәл, метрика китабы, комган, намазлык ише шартлы реквизит чыгарып, хәтта Госманлы дәүләте солтаны белән күрешү күренешләрендә дә зиннәтле, купшы әйберләрне кулланмаулары белән авторлар дин эшлеклесенең гадилеген, тыйнаклыгын ассызыкларга теләгән булса кирәк. Автор һәм режиссер тамашаны кайчан туган, кайсы мәдрәсәдә укыган һәм геройның тормыш хәленә караган башка шундый хикәяләүләр кертмичә, Хәсәновның рухи эзләнүләрен, икеләнүләрен һәм, ниһаять, дөреслекне табуын чагылдырырга омтылган. Моноспектакльдә яңгыраган кайбер фәлсәфи уйлар бүгенге көн күзлегеннән караганда да кызыклы тоела. Мәсәлән, «Аллаһка якынаер өчен бер адым атласаң, Аллаһ сиңа каршы мең адым ясаячак», – дигән сүзне тыңлап, аякларын дәвалар өчен, геройның Буадан ерак Төркиядәге Бурса шәһәренә чыгып китәргә батырчылык итүе бүгенге тамашачыларга Аллаһка тапшырып яшәүдә, озак икеләнеп вакытны үткәрмичә гамәл кылуда бер үрнәк булырга мөкин. «Адәм баласы чүлмәккә охшаган, нәрсә белән тутырсаң, шул була», – диюе тамашачыны белем алырга, рухны камилләштерергә әтәрми калмас. Ахырдан герой бик мөһим ачыш ясый. Ул интегеп эзләгән нәрсә бик якында булган икән бит, Аллаһка иң туры юл – йөрәк аша, кешенең йөрәге – дөньядагы иң зур гыйбадәт йорты, ди ул.

Илле минут бер мизгел кебек сизелми дә үтеп китүгә карамастан һәм моноспектакльдә яңгыраган һәр фәлсәфә һаман күңелдән китмәсә дә, Нургали Хәсәнов турында байтак сораулар калды, ягъни спектакльдә тарихи җирлек йомшаграк сыман тоелды. Госманлы солтаны ни өчен Нургали Хәсәновны шулкадәр зурлаган, орден белән бүләкләгән, Николай патша ни сәбәпле мөселман дин эшлеклесенең түшенә медальләр таккан, ише сораулар әле һаман да башта әйләнә. Программадагы тарихи белешмә тулырак язылып, тамашачы шушындый ише сорауларга да җавап таба торган булса, спектакль тулы камиллеккә ирешәчәк. Хәер, Раил Садриев тотынгач, анысын гына булдырыр. Кечкенә Буада гөрләтеп театр эшләткән, инде менә дин эшлеклесе турында спектакль куйган шәхеснең вак-төяк кимчелекләрне камилләштереп бетерәсенә берәүнең дә күңелендә шик тумас. Ислам дине мәсьәләләре, аларны өйрәнгән Нургали Хәсәнов кебек шәхесләребезнең сүзләре шулай зур сәхнәләрдә яңгыравы үзе күңелне җилкендерә торган вакыйга түгелмени!? «Дәрвиш» спектаклен 14, 15, 16 гыйнварда Г.Камал театрының кече сәхнәсендә дә карарга мөмкин булачак.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Күнче Вайсил

Кайчагында якын кешеңә нәрсә бүләк итәргә белмичә йөдәп бетәсең. Кибетләрдә нәрсә телисең, шул бар, ләкин күңел ниндидер аерата җылы, үзенчәлекле, кадерле дә, сыйфатлы да бүләк табарга тели. Үзем дә шул хисләрне кичердем. Эзли торгач, бирәм дигән колына, чыгарып куяр юлына дигәндәй, җаным эзләгән нәрсәне коеп кына куя торган остага тап булдым.

Яшь кенә останың танылган итальян, француз брендлары товарларыннан бер нәрсә белән дә аерылмаган, берәмтекләп кулдан тегелгән күн эшләнмәләре җитештерүен күреп шаккаттым. Хәер, татар халкының күннән гүзәллек тудыру сәләте борынгыдан лабаса, шуңа күрә дә буыннар аша күчеп килгән бу маһирлыкның роботлар, компьютерлар белән җансызландырылган көнебездә яшь кешедә бәреп чыгуы гына бераз гаҗәпләндерә. Таныш булыгыз – Вайсил Мөхәммәтуллин, күн остасы. Аның кебекләр турында кулыннан гөлләр коя, диләр. Ул теккән берсеннән берсе затлы сумка, портфель, биштәрләргә карап, эчләрендә җаннары гына юк бит, диясе килә.

Вайсил – тумышы белән Чиләбе өлкәсенең Арслан авылыннан. «Безнең авыл борынгы, 400 елдан артык тарихы бар, – ди ул горурланып. – Казан ханлыгы яулап алынгач, ул яклардан күп халык качып китә, безнең авылга шул чакта нигез салына». Менә шул авылда туып үскән, инде машина төзелеше буенча белгечлек алырга өлгергән татар егете 2015 елда Казанга, дини белем эстәргә дип килеп төшә. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә керә, соңрак укуын Россия ислам университетында дәвам итә. Мәдрәсәдә уку елларында ук күн эше белән кызыксынып китә ул, бу эштә тәҗрибәсе булган осталар янында ярдәмче булып эшләп, борынгы һөнәрнең серләренә төшенә, тәҗрибә туплый. Кайчандыр үзенең күн эшләнмәләре белән дан тоткан башкалабызда бу һөнәрне дәвам итүчеләрне санар өчен ике кулның бармаклары да җитә… Инде тәмам остаргач, ышаныч барлыкка килгәч кенә, Вайсил тәвәккәлләп үз эшен башлап җибәрә. Башта зурдан купмый: каешлар, акча янчыклары, паспорт тышлыклары ясый, иң мөһиме – сыйфатлы, затлы булсын дип тырыша. Иҗат җимешләрен башта үз якыннары, дуслары сатып ала. Аннары «сарафан радиосы» үз эшен эшли башлый: кемдәдер күреп кызыгып, башкалар да сорап мөрәҗәгать итә. Аннары егет зуррак, катлаулырак әйберләргә – ирләр өчен, хатын-кызлар өчен сумкалар, биштәрләр тегүгә тотына. Иң беренче теккән сумкасын ул әнисенә бүләк итә. «Бу эш миңа бик ошый. Әлегә ул миңа зур матди файда китерми, дөрес, чөнки әле күптән түгел генә мөстәкыйль эшли башладым. Кулымнан килә, осталыгым бар, ләкин маркетинг, реклама мәсьәләсендә тәҗрибәм җитеп бетми», – ди оста. Ул сумка-биштәрләрне ике катлап чын күннән тегә, сыйфатлары чит илдә эшләнгән затлы брендларныкыннан һич калышмый. Күннең дә яхшысын кайтарырга тырыша.

Вайсилнең күңелендә тагын бер хыял йөри. Казанда технология һәм дизайн көллияте бар, анда күн-галантерея юнәлеше буенча да укыйлар. Яшь оста шунда белем алучы шәкертләргә күн эшендә тәҗрибә туплар, осталыкларын шомартыр өчен, мәйданчык ясарга тели. Бу өлкәдә оста булып җитешү өчен, практик белем, тотып карап кулны шомарту бик мөһим, дип саный ул. Шушы хыялын тормышка ашыру максатында, Вайсил компьютерлаштырылган чигү машинасы да алырга җыена. Заманчаны, күн эшләнмәләргә бизәк чигәргә мөмкинлек бирә торганны. Ул машинада татар милли бизәкләрен программалаштырып, күн эшләнмәләрен бизәүдә кулланырга җыена ул. Тик әлеге акыллы машинаның хакы да шактый шул. Оста милли күн эшләре проектлары белән грант бәйгеләренә катнашып караса да, әлегә ота алмаган. Тик өметсез шайтан гына, ди. Милләтебезнең затлы һөнәре булган күнчелек тармагын шәхси бренд, шәхси тамга дәрәҗәсендә танытырга хыялланучы алтын куллы яшьләргә дә бәхет елмаер әле.

Эльмира СИРАҖИ.

Безнең ватанпәрвәрләр

Казан технология һәм дизайн көллиятендә берничә ел дәвамында «Ватан өчен!» клубы эшләп килә. Алар гаять изге эш – 1941-1945 елларда Бөек Ватан сугышында илебез азатлыгын яклап һәлак булучыларның истәлеген мәңгеләштерү белән шөгыльләнә.

Тарихи-патриотик клуб 2019 елның декабрь ае ахырында оешып, яңа елның гыйнвар аенда эшчәнлеген җәелдереп җибәрде. Хәзерге вакытта «Ватан өчен!» клубы күп эшләр башкара. Әйтик, клубның архив тикшеренү бүлеге Бөек Ватан сугышы фронтларында «Хәбәрсез югалганнар» исемлегендә йөргән 213 Кызыл Армия сугышчысының һәм командирының һәлак булган урыннарын ачыклады. Клуб әгъзалары республикабызның

Арча һәм Әтнә районнарыннан килгән хезмәттәшләре ярдәме белән Татарстан шәһәр-авылларыннан Ватан сугышына чакырылган якташларыбызның туганнарын тапты һәм аларга тантаналы шартларда каһарманнарны җирләү хәбәрләрен тапшырдылар.

Клуб әгъзалары Президент гранты хисабына үткәрелә торган Бөтенроссия Ватан эзләнүчеләр мәктәбендә,Татарстанның фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Россия Хәрби фәннәр академиясе әгъза – корреспонденты Михаил Черепанов җитәкчелегендәге Хәрби Дан Клубында белемнәрен дә камилләштерделәр.

«Ватан өчен!» патриотик клубы тантаналы чараларны үткәрү һәм оештыру өчен агитация бригадасын да булдырды, алар клубның Күзәтчелек советы вәкиле, Россия кинематографистлар берлегенең Татарстан буенча әгъзасы Павел Соколовский җитәкчелегендә шөгыльләнә. Бригада Бөек Ватан сугышында катнашкан геройларга багышланган «Эфир – Татарстан 24» телеканалы тапшыруында да катнашты.

«Ватан өчен!» клубына безнең көллият студентлары гына түгел, башка мәгариф учреждениеләре студентлары да әгъза булып керүе исә тарихи-патриотик эшчәнлекне тагын да киңрәк җәелдерергә мөмкинлек бирә.

Ике ел эшләү дәверендә катнашучыларыбыз 600 дән артык сугышчы, фронтларда хәбәрсез югалган дип саналган якташларыбызның язмышларын ачыклады.

2021 елда клуб әгъзалары Герой шәһәр Керчька эзләнү-тикшеренү экспедициясенә ике тапкыр барды һәм тагын 2700 сугышчы турында мәгълүмат табып, туганнарына хәбәр итте. Шул ук вакытта аларның исемнәре мәгълүмат базасына да кертелде..

Эзләнү экспедицияләрендә катнашучылар Татарстанда 1941-1945 елларда Бөек Ватан сугышы вакытында сугышларда һәлак булган Ватан сакчылары истәлеген мәңгеләштерү эшчәнлеген уңышлы алып барулары, патриотик хәрәкәтне үстерүгә керткән өлешләре өчен, Яшь Армия Бөтенроссия хәрәкәте штабының Татарстан буенча башлыгы фәрманы белән, «Ватан өчен!» Бөтенроссия хәрәкәтенең 3 нче дәрәҗә медале белән бүләкләнде.

Көллиятебездә илнең чын патриотларын күрү, алар белән аралашу студентларыбыз өчен үзенә күрә бер дәрес тә.

Алинә БИКЧӘНТӘЕВА,
Казан технология һәм дизайн көллияте студенты.

Мәдәни җомга
23 декабрь
№50, 2022

Хезмәттә яуланган

(Галим Әнвәр Шәриповка 80 яшь)

Ике ягына да Кәрәкәшле авылы сыенып утырган Ютазы елгасында боз кузгалган чорда була бу хәл. Шул елны гына укырга кергән бәләкәч Әнвәр Шәрипов агач күтәрмә тагылган чабаталарын киеп, бишгәр сымак итеп тегелгән чүпрәк сумкасын аркасына асып, мәктәпкә барырга чыга. Күтәрмәләр исәбенә буе дәү булып китүенә куанып, юлында очраган күлдәвекләрне юри ера-ера бара бу. Нигедер якын-тирәдә яшәүчеләр җыелган, шау-гөр килгән яр буена барып җитсә, елганы тутырып, актарыла-актарыла боз агып ята. Ул гына да түгел, елганың бу ягында бүленеп яшәгән күрше авылдашлары чыгып йөри торган күперне ташу алып киткән. Аның урынында бары ике ярны тоташтырып торган ике тимер торба гына чекрәеп калган.

Инде нишләргә? Елганың икенче ягында урнашкан мәктәпкә юл ябылган. Ә аргы баштагы зур күпер аша урап барса, дәрескә соңга калачак. Алай ярамый, укытучы апасы соңга калырга кушмый. Малай бераз карап тора да тәвәкәлли: аслы-өсле сузылган торбаларның астагысын басма, өстәгесен тотынгыч итәргә ниятләп, ташкын өстендә асылынып торган «сират күпере»нә кереп китә. Ярдагылар абайламый да кала. Кемнәрнеңдер арттан, җүләрләнмә, чык, дип кычкыруына карамастан, юлын дәвам итә малай. Елга уртасына якынлашканда болай да үз авырлыгыннан сыгылырга торган астагы торба тирбәлә башлый. Малайның башы әйләнеп китә, упкынга егылмас өчен ике кулы белән дә өстәге торбага ябыша. Ләкин инде кире борылырга соң була. Як-якка чайкалырга торган торбага кемдер кереп, ярдәм итә дә алмый. Ярдагылар каушап калган малайны кыюландырырга теләп, берсен-берсе куәтли-куәтли кычкыралар:

– Курыкма-курыкма, аска карама.

– Акрын гына, аякларыңны шуыштыра-шуыштыра атла.

– Торба тибрәлә башласа, көтеп тор. Туктый-туктый бар.

Әйе, сабантуйларында нык чайкала торган колга буйлап барганда да, аска егылмас өчен шулай итәләр. Әмма сабантуйда аста каты җир, ә монда – ажгырып аккан бозлы ташкын. Тик бу очракта да янаган афәттән котылып калуның бердәнбер юлы шул ук. Бәләкәч батыр калган юлын өрекмәскә тырышып, кабаланмыйча үтә. Аякларын шудыра-шудыра, салмак адымнар ясап, икенче як ярга барып чыга.

Бу беренче класс укучысы Әнвәрнең әле башланып кына килгән гомер юлында ирешкән иң тәүге җиңү була. Ләкин иң мөһиме, шушы сынауны үткәндә, кечкенә Әнвәрнең табигатендә килачәктә шәхси йөзен, холкын билгеләячәк һәм зур җиңүләргә юл ачачак тәвәккәллек, максатчанлык, ихтыяр көче кебек сыйфатлар бөреләнүе дә ачыклана.

Әнвәрнең башлангыч мәктәп еллары әнисе килен булып төшкән Ютазы районының Кәрәкәшле авылында үтә. Әтиләре фронтта үлеп калганнан соң, гаилә әниләренең туган төбәгенә – хәзерге Лениногорск районының Зәй-Каратай авылына күчеп килә. Әнвәрнең шәхес булып җитлегү чорлары әлеге авылның урта мәктәбендә уку, ә аннары Казан дәүләт университетының татар филологиясе бүлегендә белем алу елларына туры килә. Университетта ул дүртенче-бишенче курсларда доцент Нил Юзиев җитәкчелегендә махсус план буенча укуга күчерелә һәм «Язучы-әдипнең иҗат процессы» дигән яңа курслар тыңлап, шушы ук темага Хәсән Туфан иҗаты мисалында өйрәнергә алына. Җитәкче кушуы буенча Х.Туфанның Маяковский урамындагы фатирына йөреп, аның белән күзгә-күз әңгәмәләшеп, шагыйрьнең иҗат лабораториясен, үз әсәрләре өстендә ничек эшләвен һәм шигырьләренең вариантларын, караламаларын өйрәнә. Шунда аның Кәрәкәшледә бала чагында ук тернәкләнә башлаган һәм инде ныгыган тәвәккәллек, максатчанлык кебек сыйфатларына фәнни фикерләү, ачышлар ясарга омтылу сыйфаты килеп ялгана. Нәтиҗә дә, билгеле, эшнең фәнни дәрәҗәсенә туры килә – диплом эшен ул «бишле»гә яклый.

Яшь галимнең кандидатлык диссертациясе яклавы Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында эшләгән чорына туры килде. Монда эшләгәндә ул татарлар яши торган төрле төбәкләргә үткәрелгән археографик экспедицияләрдә катнашып, революциягә кадәрге чорларга караган гарәп шрифтлы кульязма китаплар һәм язмалар җыю, аларга бәяләмәләр язу белән шөгыльләнде. Бернинчә ел эчендә ул алты йөзгә якын кульязма текст табып, институтның «Мирасханә»сенә тапшырды һәм сигез йөзгә якын шундый борынгы язма ядкәр үрнәкләренә тасвирламалар язды. Шулай ук Төмән өлкәсенә озак сроклы командировкага баргач, Тубыл шәһәренең туган якны өйрәнү музее архивында тупланган гарәп язмалы китаплар һәм кульязмалар да аның кулы аша үтте, тасвирламалар белән тулыланды. Узган мирасны барлау һәм кире кайтару кебек мондый изге эш башкарырга, әлбәттә, Әнвәр Мәгъдәнур улына Ленинград университетының көнчыгыш факультетында фәнни стажировка вакытында гарәп һәм фарси телләрен күренекле ориенталист, профессор Габдрахман Таһирҗанов җитәкчелегендә өйрәнүе дә ярдәм итте.

Белемен туктаусыз камилләштерү, күпкырлы белгеч булырга омтылу аны фәнни-тикшеренү эшен педагогик эшчәнлек белән үреп алып баруга этәрде һәм ул Алабуга педагогика университетында өлкән укытучы булып эшли башлады. Биредә дә басылып фән белән дә шөгыльләнде, Утыз Имәни иҗатын өйрәнүне дәвам итеп һәм әсәрләренең хәзерге әдәби телдә сүзмә-сүз тәрҗемәләрен дә биреп, яңа табышлары белән тулыландырып, шагыйрьнең «Шигырьләр һәм поэмалар» (Казан: ТКН, 1986) дигән җыентыгын бастырып чыгарды. Ул фәнни-мәдәни җәмәгатьчелек тарафыннан хуплап каршы алынды, газета-журналларда аңа багышланган уңай рецензияләр дөнья күрде.

Шушыннан соң Әнвәр Шәрипов үзенең игътибарын тагын да элгәрек чорда яшәгән, Казан ханлыгының атаклы имам-сәете һәм шагыйрь Кол Шәриф иҗатына юнәлтте. Моңа Ленинградта Көнчыгышны өйрәнү китапханәсендә борынгы чыганаклар белән танышып утырганда, әлеге дин һәм иҗат әһеленең мирасына бәйләнешле кульязмага юлыгуы сәбәп була. Шуңа нигезләнеп, ул «Кыйссаи Хөбби Хөҗа» поэмасы ушбу авторныкы булырга тиеш, дигән үз версиясен тәкъдим итте һәм «Бакыргани китабы»нда бирелгән газәлләрен дә бергә туплап, аларны да юлга-юл бүгенге әдәби телебезгә тәрҗемә итеп, 1997 елда Кол Шәрифнең «И күңел, бу дөньядыр...» дигән шигыри әсәрләр җыентыгын җәмәгатьчелеккә ирештерде. Әнвәрнең бу изге гамәле, һичшиксез, узгандагы әдәби мирасыбызны халкыбызга кире кайтаруның тагын бер кәттә үрнәге булды. Әлеге җыентык татар әдәбияты тарихында Кол Шәриф иҗатына багышланган, өстәвенә, төзүченең фәнни кереш мәкаләсе һәм җитди искәрмәләр белән тулылындырган иң беренче басма хезмәт иде.

Ә инде галимнең күп еллык эзләнү-тикшеренүләре нәтиҗәсендә туган «Борынгы төрки һәм төрки-татар әдәбиятында шигъри жанрлар системасы (VIII–XIV гасырлар)» дигән монографиясе һәм шуның буенча яклаган докторлык диссертациясе аны тәмам житлеккән, тюркология масштабындагы проблемаларга теше үтә торган галим итеп танытты. Чөнки автор һәм диссертант әлеге капиталь хезмәтендә гомумтөрки һәм төрки-татар язма шигъриятендә кулланылган поэтик жанрларның яралу һәм эволюцион үсеш баскычларын тикшерә. Әлеге жанрларның фольклорга һәм гарәп, фарсы-таҗик әдәбиятларына бәйләнешле гасырлар тирәнлегеннән килә торган чыганакларын һәм төрки-татар әдәбияты җирлегенә аларның ничек ярашуын, нинди үзгәрешләр кичерүен анализлый. Автор күптөрле лиро-эпик жанрларның норматив поэтикага нигезләнгән структур сыйфатларын, шулай ук аларның социаль-әхлакый һәм сәнгати-эстетик үзенчәлекләрен бер-бер артлы ачып сала.

Ә.Шәриповның ошбу зур хезмәте тууга күпмедер дәрәҗәдә кереш һәм әзерлек роле уйнаган ике җитди тикшеренүен дә күрсәтеп китәргә кирәктер. Алар – «Татар әдәбияты тарихы»ның (Казан: Татар. кит. нәшр., 1984) беренче томында басылган урта гасырлардагы мәдәни мөһитне һәм әдәби хәрәкәтне гәүдәләндерә торган «Культура һәм тормыш», шулай ук «Әдәби бәйләнешләр» дигән хезмәтләр. Боларда Шәрык классик әдәбиятына һәм фольклор казанышларына бәйләп, мәдхия, мәрсия, газәл, касыйдә, мәснәви, робагый, фәрд, язма рәвештә иҗат ителгән илаһи бәет, җыр кебек уннарча жанрлар һәм аларның үрнәкләре турында да сүз бара, янә килеп, һәр чорның гарәп-фарсы яки гомумтөрки әдәби традицияләренә нигезләнеп туган әсәрләре атап күрсәтелә. Ә инде югарыда исемләнгән монографиясен язганда, рус тюркологлары белән беррәттән, без фәкыйрегезнең «Шигърият бишеге. Гомумтөрки поэзиянең яралуы һәм иң борынгы формалары» (Казан: Мәгариф, 2001) дигән хезмәтенә дә кат-кат таянуына һәм шуны ассызыклап күрсәтүенә килгәндә, монысы инде, әлбәттә һун чорында ук тернәкләнгән йола гимны, ода-алкыш, келәү-алгыш, сыгыт-сыктау, тарихи җыр, лирик җыр, әйтеш, мәкаль, әйтем, ырым, арбау, каргыш, ант кебек уннарча иң борынгы поэтик, афористик һәм магик жанрларның беренче башлап шушы китапта яктыртылуы һәм исбатлануы белән бәйле. Фәнни тикшеренүләр менә шулай бер-береңнең табышларына таяну һәм үз казанышларың белән кушып, алга таба үстерү рәвешендә бара бит!

Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан әзерләнгән «Татар әдәбияты тарихы»ның сигез томлык яңа чыгарылышында да Әнвәр Шәриповның җитди өлеше бар. Беренче томда аның «Орхон-Енисей язмалары», «Борынгы уйгур язулы истәлекләр» дигән, икенче томда (фәнни мөхәррире Х.Миңнегулов) Утыз Имәни иҗатына, бишенче томда (фәнни мөхәррире Д.Заһидуллина) Сирин (Хәниф улы Батыршин) иҗатына багышланган саллы мәкаләләре шуны раслап тора. Белешмә әдәбият төренә карый торган «Татар энциклопедиясе» томнарында исә галимнең тикшеренүләренә бәйле «Балалар әдәбияты» дигән һәм күренекле шәхесләр турында язылган текстлары урын алган.

биекләкләр

● Лениногорскида Чишмә әдәби түгәрәгенең 60 еллыгын билгеләп үткәндә.

Киң эрудицияле галимнең Г.Тукай, Г.Исхакый, Н.Думави, Х.Туфан, С.Хәким кебек татарның классик язучылары иҗатына багышланган мәкаләләр сериясе, моңарчы тиешле бәясен алмаган Сирин иҗатын барлау һәм тулыландыруга, шулай ук төрек авторларының аерым әсәрләрен пропагандалауга юнәлдерелгән рисалә-язмалары булуын ассызыклап үтү да урынлыдыр.

Ә.Шәриповның педагогик эшчәнлеге аерым яктыртуны сорый. Чөнки ошбу зат коеп куйган галим генә түгел, ә талантлы остаз-педагог та. Алабуга педагогия институтында эшләгәндә ул «Борынгы татар әдәбияты», «XIX гасыр татар әдәбияты» «Халык авыз иҗаты», «Әдәбият белеменә кереш», «Татар балалар әдәбияты» дигән махсус курслар укыта. 1990 елда исә, Яр Чаллы педагогия институты төзелгәч, доцент дәрәҗәсен алып, әлеге курсларын шунда дәвам итә. Шул чорда филология факультетының деканы да булып ала. Аннары инде, ягъни дүрт елдан соң, аны шәһәрдә яңа гына оешкан Өзлексез белем бирү институтына фәнни эшләр буенча проректор итеп чакыралар. Монда ул укытучылар белемен күтәрүне юлга салу, төрле оештыру эшләре белән шөгыльләнә, шулай ук филология буенча курсларда дәресләр дә алып бара.

Үзе эшләп киткән педагогия институтына янә доцент булып әйләнеп кайткач, вуз мөгаллиме Әнвәр татар филологиясе кафедрасында укытуын дәвам иттерә. Докторлык диссертациясен яклап кайтуга ук аны шул кафедраның мөдире итеп куялар. Тиздән филология фәннәре докторы һәм профессор дигән гыйльми дәрәҗәләр дә ала. Әлбәттә инде, профессор абыйларының тирән эчтәлекле лекцияләрен студентлар яратып тыйлый, гамәли дәрес һәм семинарларын да укытучылары җанлы итеп уздыра. Остаз-галим студентлар һәм укытучылар өчен бер-бер артлы методик кулланмалар һәм уку-укыту әсбаплары да төзеп чыгара. «Әхлак белеме» дигән хрестоматия, «Татар филология бүлегенә керүче абитуриентлар өчен программа», «Татар балалар әдәбияты» дигән кулланма, «Борынгы татар әдәбиятының авыр үзләштерелә торган мәсьәләләре» дигән ярдәмлек – аларның иң характерлылары. Һәркайсы педагогның күпьеллык бай укыту тәҗрибәсенә таянып язылган. Әйтик, «Татар балалар әдәбияты» дигән кулланмада әлеге төр әдәбиятның XIX гасырдан алып бүгенге көнгә кадәр үткән юлы яктыртылса, «Борынгы татар әдәбиятының авыр үзләштерелә торган мәсьәләләре» дигән ярдәмлектә әдәби мирасыбызга бәйләнешле иң катлаулы сигез тема җиңелләштерелеп, әзерлексез укучыга да аңлашылырлык бәян ителә. Болар бары да Әнвәрнең көчле педагог һәм оста методист булуын раслап тора.

Ә.Шәрипов – күп кырлы талант иясе. Аның табигатьтән бирелгән тагын бер сыйфаты язучылык сәләте белән бәйле. Лениногорск районының Зәй-Каратай урта мәктәбендә укыган чагында ук ул район газетасы редакциясе каршында оештырылган әдәбият-иҗат берләшмәсенә йөри башлый һәм шул ук газетада үзенең тәүге шигырьләрен бастыра. Шулай ук ул Әлмәт Язучылар оешмасы каршындагы Гариф Ахунов җитәкләгән әдәбият-иҗат берләшмәсенең утырышларында да катнаша. Әдәбияткә омтылышы аны Алабуга педагогия институтында укыта башлаганнан соң студентларның «Чулман» исемле әдәбият-иҗат түгәрәген оештырып җибәрүгә этәрә. Чаллыдан килеп-кайтып йөрү бәрабәренә булса да, унбер ел буена ул шул берләшмәне җитәкли. Әлеге түгәрәктә Марсель Гыйматдинов, Фазыл Шәех, Гөлзадә Әхмәтова кебек булачак язучыларның канат чыгаруы бер дә гаҗәп түгел.

Язучы буларак, Әнвәр шигырь, җыр, хикәя кебек жанрларны үз итә. Бигрәк тә аның лирик шигырьләре һәм җырлары тәэсирле. Шулай ук аның «Укытучы» дигән поэмасы да күтәренке рухта язылган. Әгәр замандашларының күңел кылларын чиртә белмәсә, авторның байтак шигыренә композиторлар көй язган булыр иде мени?! «Кем идең син» һәм «Тукта, мизгел!» дигән җыр җыентыкларының, шулай ук музыкант Рубис Зарипов белән бергәләп иҗат иткән «Моң дәрьясында» исемле җырлар тупланмасының тиз арада кибет киштәләреннән юкка чыгуы да аның укучылар күңеленә юл табуы турында сөйли.

Ә.Шәриповның әдәби тәнкыйтьче буларак иҗади хәрәкәттә актив катнашуы да мәгълүм. Атап әйткәндә, аның Якуб Зәнкиев, Шәүкәт Галиев. Роберт Миңнуллин, Газиз Кашапов, Кадир Сибгатуллин, Фазыл Шәех, Фидаил Мәҗитов, Мансур Сафин, Ямаш Иканәй, Әлфия Садыйкова, Лениза Вәлиева һ.б. иҗатын анализлаган мәкаләләре бар. Аның төрле уку йортларында, фәнни оешмаларда эшләүче галимнәрнең монография яки дәреслекләренә бәя биреп язган рецензияләре дә җитәрлек. Болар өстенә, галимебез төрле югары уку йортларыннан һәм фәнни-тикшеренү институтларыннан җибәрелгән кандидатлык һәм докторлык диссертацияләренә бәяләмәләр язарга да вакыт таба. Аларның саны 52гә җыела!

Әнвәр Мәгъдәнур улының инициатива күрсәткән, каләм тибрәткән тагын бер өлкәсе – публицистика. Бер генә мисал. 2016 елда ул «Мәдәни җомга» газетасында «Казанга Тукай мәйданы кирәк» дигән баш астында беренчеләрдән булып бик мөһим мәсьәлә күтәреп чыккан иде. Беркадәр вакыттан соң галимебез «Ватаным Татарстан» газетасында «Ә эш һаман сузыла» дигән икенче мәкалә бастырды. Язмалар белән кат-кат чаң сугу йогынтысыз калмады: шәһәр советының карары белән Казан үзәгендәге Куйбышев мәйданы «Габдулла Тукай мәйданы» дигән исемне алды.

Бүген дә Әнвәр Шәрипов – һаман хәрәкәттә. Үзе эшләгән педагогика институты (хәзер университет) белән дә бәйләнешен өзми. Моннан берничә ел элек ул, студентлар өчен кулланма-ярдәмлек итеп әзерләп, «Идел һәм Урал буе халыклары әдәбиятлары» цикльның татар әдәбиятына багышланган беренче кисәген (572 б.) чыгарган булса, хәзер шуның икенче кисәген тәмамларга ниятли. Бусы башкорт, чуаш, мари, мордва, удмурт, коми әдәбиятларына багышлана. Янә килеп, шагыйрь Утыз Имәнинең моңарчы беркайда да дөньяга чыкмаган, меңнән артык юлдан торган «Ахирәтнамә» поэмасының аерым бүлекләрен, сүзмә-сүз хәзерге әдәби телгә күчереп, «Безнең мирас» журналының быелгы саннарында бастырды. Күпкырлы шәхес буларак, ул шигърият мәйданында да ат уйнатуын дәвам итә.

Марсель БАКИРОВ,
филология фәннәре докторы.

Айга карама
кырын

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

24 декабрь (шимбә). ***Җомәдел ахир аеның 1 нче көне. 2 нче Ай тәүлеге. Ай Кәҗәмөгез йолдызлыгында, 9.55 сәгатьтә калка, 15.39 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 7.01 сәгать.***

Яңа туган Ай Җир белән Кояш арасында, үзенең караңгы ягы белән Җиргә караган. Ай идарә итә торган һәрнәрсә – хисләр, кәеф, хәтер, кан басымы зәгыйфь. Кан басымы болай да түбән булган гипотониклар өчен бигрәк тә авыр вакыт. Бу чорда укуда уңышлар, тиз савыгу, югары эшчәнлеккә өметләнергә ярамый. Ашаганда талымлы булу хәерле. Аралашуны чикләү зарур.

Гөлҗимеш сихәте

Ангинадан дәвалану өчен, 8-10 сантиметр озынлыктагы гөлҗимеш тамырын кискәләп, 200 мл кайнар суга салалар, өстен каплап, ярты сәгать төнәтәләр, сөзеп, әз-әзләп эчәләр. Көненә 3 стаканлап эчәргә ярый, авырту басылса, туктыйлар.

25 декабрь (якшәмбе). ***Җомәдел ахир аеның 2 нче көне. 3 нче Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында, 10.37 сәгатьтә калка, 17.13 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 7.02 сәгать.***

Бик актив көн, хәвеф-хәтәр инстинкты, агрессия белән бәйле. Бүген чирләп китү ихтыяр көченең җитәрлек булмавын күрсәтә. Күзне арытмаска кирәк.

Ревматизмнан – мумие

100 г сыек балга 0,5 г мумие кушып, әйбәтләп болгаталар, сызлаган буыннарга төнгелеккә компресс итеп куялар. 10 көн дәвамында иртән, ашарга 1 сәгать кала, 0,2 г мумие эчәләр, аннары 10 көн ял итәләр. 1 курска 6 г мумие кирәк булачак. Тулысынча сихәтләнү өчен исә 2-3 дәва курсы үтү мәслихәт.

26 декабрь (дүшәмбе). ***Җомәдел ахир аеның 3 нче көне. 4 нче Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында, 11.01 сәгатьтә калка,18.54 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 7.02 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Теләсә нинди элемтә, танышулар, күмәк эш бүген кыен кичерелә. Озаграк йоклау хәерле. Тәмләрәк һәм күбрәк ашау теләге зур булса да, чаманы югалтмаска кирәк. Ач торырга ярамый.

Диабеттан дәва

1 аш кашыгы төелгән әстерхан чикләвеген 1 стакан суда 30 минут пешерәләр, чәй кебек, бер эчүдә эчеп бетерәләр. 1 өлеш әстерхан чикләвегә, 5 өлеш карабодай ярмасын он итеп тарттыралар. Кичтән шул катнашманың 1,5 аш кашыгын кефирга салып калдыралар да, иртән ач карынга сыйлаганалар, артыннан уылган 1 алма ашап куялар. Көн дәвамында ашарга 30 минут кала 1 әр аш кашыгы чикләвекле карабодай онын кабалар. Дәва курсы – 5 ай.

27 декабрь (сишәмбе). ***Җомәдел ахир аеның 4 нче көне. 5 нче Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында, 11.17 сәгатьтә калка, 20.32 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 7.02 сәгать.***

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

Бүген юлда булу әйбәт. Ач тору тыела. Күңел нәрсә тели, күпме тели – шулкадәр ашарга була, бигрәк тә яшелчә файдалы. Башлаган эшне ахырына җиткезү зарур. Ашказаны-эчәк авырулары кискенләшү тискәре энергиянең артык күп туплануын күрсәтә. Кан әйләнеше системасы, ияк, муен, бронхлар зәгыйфь.

Алма шифасы

1 стакан сөткә ярты стакан су кушалар, шуңа 2 алма турап салалар һәм 5-7 минут пешерәләр. Эчне йомшарту өчен, иртән ач карынга ашыйлар.

28 декабрь (чәршәмбе). ***Җөмәдел ахир аеның 5 нче көне. 6 нчы Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында, 11.27 сәгатьтә калка, 22.04 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 7.03 сәгать.***

Хисчәнлек арта. Һәртөрле аралашу күңелгә ятышлы. Бу көннәрдә әтиәнигә ихтирам көче аеруча куәтләнә, гаиләдә бергә җыелып, балачакның күңелле хатирәләрен яңарту яшәү көче өсти. Бизләр системасы, җилкә, кул, үпкә, бронхлар зәгыйфь, салкын тию ихтималы зур.

29 декабрь (пәнҗешәмбе). ***Җөмәдел ахир аеның 6 нчы көне. 7 нче Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында, 11.36 сәгатьтә калка, 23.37 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 7.04 сәгать.***

Һава энергиясенә бәйле көн. Тынгысызланырга, гайбәт сөйләргә ярамый. Ялгыз калып уйлану файдалы. Нерв системасы, үпкә зәгыйфь. Ач тору киңәш ителә, танылган им-томчы Ванга атнасына бер көн ач торуны организмны чистартуның иң нәтиҗәле ысулы дип санаган.

Әнис сихәте

1 чәй кашыгы төелгән әнис орлыгын 1стакан кайнар суда 20 минут төнәтәләр, сөзеп, көненә 3-4 тапкыр, ашар алдыннан, чирегешәр стакан эчәләр. Мондый төнәтмә какырыкны бик шәп куптара.

30 декабрь (җомга). ***Җөмәдел ахир аеның 7 нче көне. 8 нче Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында, 11.43 сәгатьтә калка, 0.55 сәгатьтә бата. 2нче фаза. Көн озынлыгы 7.05 сәгать.***

Бүген бигрәк тә ут белән эш иткәндә саклык сорала. Ризык җиңел үзләштерелүчән булырга тиеш. Ашказаны, бизләр системасы зәгыйфь, невралгия һәм стенокардияне кисәтү чаралары уңай нәтиҗә бирә. Колак авыртырга мөмкин. Бу атнада күзне саклау мөһим.

Яңа ел табынына – глинтвейн

1 литр чия согына ярты литр алма согы, 250 мл су, 10 данә канәфер кадагы, 3 дарчин таякчыгы, ярты чәй кашыгы кардамон, бер чеметем төелгән мөшкәт чикләвеге, кабыгы белән телемләп туралган бер әфлисун һәм ярты лимон кушып, кайнатып чыгаралар да, капкачын каплап, 15 минут пешерәләр. Сүндереп, сөзәләр, 1 әфлисун согы өстиләр. Чия согын мүк җиләге яки карасу төстәге йөзем согына алыштырырга да була. Тәмләткечләрнең барысын да салырга кирәк, шул вакытта гына хуш исле һәм тәмле эчемлек килеп чыга. Артык баллы тоелса, су белән сыегайтырга була.

Рухи мирасыбыз кайта

Казанда Дtotиния нәзарәте бинасында татар дини-илаһият мирасының рус теленә тәрҗемәләрен һәм репринт (фотокүчермә) басмаларын тәкъдим итү чарасы булып узды.

Фундаменталь әсәрләр беренче тапкыр рус теленә тәрҗемә ителде, ә димәк, рус телле укучылар хәзер алар белән таныша алачак һәм революциягә кадәрге татар дин галимнәренең фәнни казанышларын бәяли алачак. Уналты хезмәт – репринт басмалар һәм тәрҗемәләр – Россия ислам институтында һәм «Хозур» нәшрият йортында Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулу чаралары кысаларында әзерләнде һәм бастырылды.

Мәрҗани хезмәтләрен рус теленә тәрҗемә итү Россия ислам институты белгечләре тарафыннан башкарылды. Китаплар Татарстан Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты һәм Россия ислам институты катнашында 2005 елдан чыгып килгән Татар дини фикере антологиясен тулыландыра. Тәрҗемә ителгән хезмәтләр – өчәү:

– «Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр» («Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар»). Ике өлештән торган китап – Мәрҗанинең танылган тарихи трактаты. Бу хезмәттә кайбер төрки дәүләтләр (Идел буе Болгарстаны, Хәзәр, Алтын Урда һ.б.) тарихы анализлана, татар халкының этногенез процессы тасвирлана. Икенче томда автор Оренбург дини җыелышының, мәчетләрнең тарихын, шулай ук танылган татар дин әһелләренең һәм имамнарының биографиясен яза. Әлеге саллы трактат борынгы заманнардан бирле татар халкы тарихы турында иң ышанычлы чыганак булып санала. Шунысы игътибарга лаек: бу Мәрҗанинең иске татар телендә язылган бердәнбер хезмәте. (Галимнең калган барлык хезмәтләре гарәп телендә язылган). Ул беренче тапкыр тулысынча рус теленә тәрҗемә ителде.

– «Ата-бабаларга тугрылык һәм алдагы буыннарга сәлам» биобиблиографик сүзлегенә кереш («Мөкаддимәт китаб вәфийәт әл-әслаф вә тәхийәт әл-әхлаф»). Зур «Вәфийәт әл-әслаф...» биобиблиографик сүзлегенә кереш буларак, бу китап укучыны гарәп-мөселман цивилизациясе дөньясына алып кереп китә. Китап башында Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормышы турында сөйләнә, аннан соң автор ислам тарихы терминологиясен, ислам белеменең төрләрен һәм категорияләрен, мөселман галимнәренең дәрәҗәләрен аңлата, ислам дөньясы хакимнәре нәселләрен, дөнья тарихы белән бәйле кайбер мөһим вакыйгаларны санап чыга.

– «Ата-бабаларга тугрылык һәм алдагы буыннарга сәлам» («Вәфийәт әл-әслаф вә тәхийәт әл-әхлаф») – Шиһабетдин Мәрҗанинең иң күләмле әсәре. 7 томлы библиографик кульъязма сүзлек мөселман көнчыгышының һәм татар халкының VII-XIX гасырларда яшәп иҗат иткән 6057 галиме, язучының, философның һәм иҗтимагый–сәяси эшлеклеләрнең биографияләрен туплаган. Хезмәтнең 1 томы, татар дин әһелләре турындагы мәгълүмат сайлап алынып, тәрҗемә ителде.

Әлеге әсәрләр танылган татар дин галиме Шиһабетдин Мәрҗанинең иң танылган хезмәтләреннән санала.

Татарстан мөфтиятенең «Хозур» нәшрият йортында татар һәм классик дини мираска караган тагын 12 хезмәт тәрҗемә ителде һәм репринт рәвешендә басылып чыкты. Алар арасында рус теленә тәрҗемә ителгән әсәрләр: Муса Җаруллаһ Рустуфдуни (Бигиев)ның «Тарих әл-Коръән вә ль-Мәсахиф», Мөхәммәд-Закир Чистави (Камалов)ның «Табсырат әл-Мөршидин», Әбү Ләйс Сәмәркандиның «Тәнбих әл-Гафилин», Әбү Ләйс Сәмәрканди. «Тәнбих әл-Гафилин» әсәрләре бар.

Репринт басмалар арасында – Коръән «Казан басмасы», 1803 ел.; Шәйхел-ислам бин Әсәдуллаһ әл-Хәмидинең 2 томлык «Мәкаләт әл-Бүләга»; Кывам-карый Зөлфәкарыйның «Мәүлид ән-Нәби хакында бер-ике сүз» (Галимҗан Барудиның кереш сүзе белән); Коддус Абдрахмановның «Әхлак»; Атаулла Убәйдуллинның «Мөкаддимә ли ибни әл-Җәзари» тәрҗемәсе; Зариф Әмирханның «Әхәдис нәбавия»; Әбү Җафар әт-Тәхавинең «Бәян әс-Сөннәт» хезмәтләре бар.

Барлык репринт басмаларның оригиналлары Darul-Kutub.com электрон китапханәсе фондында бушлай файдалану, уку һәм күчереп алу өчен урнаштырылган, ул цифрлаштырылган борынгы дин гыйлеме хезмәтләреннән татар, иске татар һәм гарәп телләрендәге 1806 томны үз эченә ала. 2022 елда фонд 237 китапка тулыланды.

Шиһабетдин Мәрҗани – ислам дөньясында иң билгеле шәхесләрнең берсе. «Ул ислам дини фикеренә бик зур өлеш керткән Россия дин белгечләреннән санала. Бүген дөньяда ислам хокукы мәсьәләләре белән шөгыльләнүчеләр арасында, асылда, аның хезмәтләрен белмәгән һәм аларга сылтама ясамаган, аның хезмәтләрен өстәл китаплары итеп файдаланмаган дин галимнәре юк диярлек», – диде Р.Мөхәммәтшин. Рәфикъ хәзрәт сүзләренчә, Мәрҗани фәнни тикшеренүләр методологиясен эшләп чыгарган һәм ул бүгенге көнгә кадәр актуаль санала.

КИУның дини дисциплиналар кафедрасы мөдире, тарих фәннәре кандидаты, фәнни мөхәррир Сәид хәзрәт Шаһавиев сүзләренә караганда, Ш.Мәрҗани – бик тирән фикерле торган галим һәм, беренче чиратта, аның мирасы киң җәмәгатьчелеккә түгел, ә галимнәргә юнәлтелгән. «Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр» («Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар») хезмәтенә килгәндә, ул аны үз халкына бүләк иткән дип әйтергә мөмкин. Бу аның татар телендә язылган бердәнбер әсәре, бүтән китаплары гарәп телендә һәм дөнья күләмендәге гарәп телле галимнәр өчен язылган. Һәм ул күтәрә торган проблемалар нигездә галимнәргә, дин һәм фәлсәфә тоташкан катлаулы мәсьәләләрне өйрәнүче дин галимнәренә, теологларга кызыклы. Шуңа да карамастан, аның мирасын без ислам һәм татар дин гыйлеме белән кызыксынган кешеләргә, татар галимнәренең ислам илаһият фәненә нинди өлеш керткәннәрен белергә теләүчеләргә адреслый алабыз», – диде Сәид хәзрәт.

КИУның гарәп теле һәм гуманитар фәннәр кафедрасы мөдире, тарих фәннәре кандидаты, фәнни мөхәррир Габдулла хәзрәт Әдһәмов Шиһабетдин Мәрҗанинең «Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр» («Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар») һәм Муса Бигиевның «Тарих әл-Коръән вәл-Мәсахиф» хезмәтләрен тәрҗемә итү турында сөйләде. Бу хезмәтләрне тәрҗемә итүгә 3 ел вакыт киткән. Әсәрләр рус теленә тәрҗемә ителеп кенә калмаган, аңлатмалар да бирелгән.

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хозур» нәшрият йорты директоры: мөфти урынбасары Ришат Хәмидуллин сүзләренә караганда, татар дини-илаһият мирасын бастырып чыгару мәсьәләсе күптән өлгереп җиткән һәм Нәзарәт бу юнәлештәге эшне алга таба да дәвам итәчәк. «Татар дин галимнәре хезмәтләрен бөтен дөньяда беләләр һәм өйрәнәләр. Кызганычка каршы, безнең үзебездән яхшырак та», – диде Р.Хәмидуллин һәм «Хозур» нәшрият йортында татарлар арасында XVIII-XIX гасырларда киң таралган хезмәтләрнең кабат бастырылуы һәм тәрҗемә ителүен сөйләде. «Агымдагы елда Россиянең китап базарында 200 гә якын мөселман китабы басылып чыкты. Аларның татар дини мирасына караганнары бик аз. Шуңа күрә мин китап сөючеләрне, яшь галимнәрне, дини мирас белән шөгыльләнүче студентларны хезмәттәшлеккә чакырам. Ягъни без бу эшне көчәйтергә һәм ахыр чиктә бергәләп гамәлгә ашырырга телибез», – диде Р.Хәмидуллин.

Эльмира СИРАҖИ.

ТАНСЫК БАСМА

● «Суворовча кысрыклау» газетасы редакциясе. Сулдан уңга: хәрби корреспондент Абдулла Әхмәт, җаваплы сәркатип Афзал Шамов, җаваплы мөхәррир урынбасары Минһаҗ Гыймадиев, хәрби корреспондент Котдус Әхмәров, корректор Фазыл Басыйров. Байкал арты фронты. 1945, август.

Беркөн кичтән Әлфия апа Шамова сөенечен яшерә алмый шалтырата:

– Яңа китабым басылып чыкты, энем, «Ут эчендә туган матбугат», – ди.

Ә мин Әлфия апа өчен сөенеп туя алмыйм. Башка берәр автор шәхси яңалыгын хәбәр итсә, ул кадәр үк шатланыр идемме икән, әзеп әйтә алмыйм. Ә Әлфия апаның дан өчен, йә каләм хакы өчен, дип түгел, җан таләбе, кешелеклелек таләбе буенча, инде өзми һәм куймыйча, Бөек Ватан сугышы чорындагы фронт матбугаты турында гомере буе эзләнүен беләм.

Әлфия апа – фронтовик әдип Афзал Шамов кызы. Әтисе сугышка чыгып киткән чакта, аңа нибары биш-алты яшь булган, шулай да Афзал аганың окопларда язган хат һәм открыткаларының берсен дә югалтмыйча җыеп туплаган бит. Аннары әтисе, исән-сау көе фронттан кайтып кергәч, байтак кына еллар буе республиканың Язучылар берлеген җитәкләгән. Сүз дә юк, Афзал ага яшүсмер Әлфияне демонстрация, өмәләргә чыккан чагында да үзе белән алган, аңлашыла булыр, өйләренә дә кунакка бик күп шагыйрь-прозаиклар килгән. Исәннәр генә түгел, фронтта ятып калган Фатих Кәрим, Муса Җәлил, Гадел Кутуй, Фәрит Яруллин, Нур Баян кебек талант ияләренең дә, яудан исән-сау көенә әйләнеп кайткан Габдрахман Әбсәләмов, Шәрәф Мөдәррис, Шәйхи Маннур, Риза Ишморат, Гариф Гали, Ибраһим Гази кебек әдипләрнең балалары, туганнары белән дә гомер буе дус вә бер-берсенә терәк булып яши белгәннәр.

Афзал ага Шамов Калинин фронтындагы «Алга, дошман өстенә!» исемле, ә япон милитаристларына каршы 1945 елның августында яңа сугыш башлангач, Байкал арты фронтының «Суворовча кысрыклау» исемле газетаның хәбәрчесе булган. Шушы хатирә үзе үк Әлфия апаны Бөек Ватан сугышы чорында 20 фронтта татар-башкорт солдатлары өчен татарча чыгарылган 16 хәрби газета язмышын һәм эшчәнлеген өйрәнү юлына этәрә.

Бөек Җиңүнең 75 еллыгына әзерләнгән чакта без «Мәдәни җомга» газетасы битләрендә Әлфия апа әзерләп биргән дистәләгән мәкаләләргә дә, сугыш вакытында әдипләрнең бер-берсенә һәм гаиләләренә юллаган йөзләгән хатларына да урын бирдек. Бу бәйрәмне Әлфия апа «Ут эченнән юлланган хатлар» дип исемләнгән, үз эченә әдипләр язышкан меңнәрләгән хатларны туплаган ике томлы үтә саллы китапны дөньяга чыгарып каршылады. Ул чакта ук шаккаттык, хәзер дә сокланабыз: фәнни институт галимнәре махсус шөгыльләнергә һәм шуның нигезендә яшь буында ватанпәрвәр хисләр тәрбияләргә, әдипләрнең гомер юлларын һәм иҗатын һәрбер өтеренә тикле өйрәнергә тиешле Каф тавыдай зур һәм гыйбрәтле хезмәтне Әлфия апа Шамова берьялгызы көе ерып чыкты, әле аның каһарман адымын да юньле-рәтле бәяли белмәгән туң йөрәкле чинуша хезмәткәрләр алдында йөз суын түгеп, татар әдипләренең фронттагы батырлыгын китап-хатирә рәвешендә халыкка һәм тарихка кайтарып бирә алды.

Әлфия апаның яңа китабы «Ут эчендә туган матбугат» дип атала. Җыентыкка 16 фронт газетасының канлы сугыш айларында дөнья күргән иң күренекле язмалары, фронтовик әдипләрнең дусларына һәм гаиләләренә язган хатлары, хәтта фронт газеталарында басылган юмор-сатира үрнәкләре дә тупланган. Шигебез юк: Әлфия апаның әлеге хезмәте дә татар әдипләре һәм татар солдатларының Бөек Ватан сугышында кылган батырлыкларын туплаган хәзинә генә түгел, тулаем татар матбугаты тарихын да тәпле чагылдыра алырдай гадел үрнәк булыр.

В.ИМАМОВ.

МК тамаша заллары чакыра

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

23 декабрь – Премьера. «Рәшә» (Ә.Еники).
24 декабрь – Зур залда – «Рәшә» (Ә.Еники). Кече залда – «Исәнме, улым!» (Б.Абдуразоков).
25 декабрь – «Санаулы кичләр» (А.Володин).
27 декабрь – зур залда – «Бабайлар чуагы» (И.Зәйниев). Кече залда – «Томан» (Г.Сәгыйтова).
28 декабрь – «Сагынырсызмы?» (А.Шәйдуллин).
29 декабрь – 11.00, 14.00 – «Кәҗә, сарык һ.б.» (И.Зәйниев).
30 декабрь – «Өйләнәм.tat» (И.Зәйниев).

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

23, 24, 24 декабрь – «Летучая мышь» (И.Штраус).
28, 29, 30 декабрь – Казан хореография училищесы укучылары башкаруында «Снежная королева» спектакле (XIX-XX гасыр композиторлары музыкалары кулланылган).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

23 декабрь – 13.00 – «Тылсымлы арена» (Ш.Фәрхетдинов). 18.30 – «Хан кызы Турандык» (К.Гоцци, К.Тинчурин).
24 декабрь – 12.30 – «Тылсымлы арена» (Ш.Фәрхетдинов). 17.00 – «Син бит минем бергенәм» (И.Мәхмүтова).
25 декабрь – 10.00, 12.30 – «Тылсымлы арена» (Ш.Фәрхетдинов). 17.00 – «Назлы кияү» (К.Тинчурин).
27 декабрь – 13.30 – «Тылсымлы арена» (Ш.Фәрхетдинов). 18.30 – «Беренче театр» (Г.Камал).
28 декабрь – 13.30 – «Тылсымлы арена» (Ш.Фәрхетдинов). 18.30 – «Ак тәүбә, кара тәүбә. Безнең көннәр» (Т.Миңнуллин).
29 декабрь – 11.00 – «Тылсымлы арена» (Ш.Фәрхетдинов). 18.30 – «Хыялый» (С.Әбүзәров).
30 декабрь – «Кияү урлау» (С.Юзеев әсәре, Х.Ибраһим тәрҗемәсе).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

23-26 декабрь – «Галәм кунаклары һәм Яңа ел» дип исемләнгән Яңа ел тамашасы һәм чыршы тирәсендә әйлән-бәйлән.
27 декабрь – 13.00 – «Галәм кунаклары һәм Яңа ел» дип исемләнгән Яңа ел тамашасы һәм чыршы тирәсендә әйлән-бәйлән. 18.30 – «Шәй-бу! Шай-бу!» (К.Кәримов).
29 декабрь – «Матур City» (А.Әхмәтгалиева).
30 декабрь – «Ак чәчәкләр кебек» (Р.Мухина).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

23-31 декабрь – «Сон в новогоднюю ночь» дип исемләнгән Яңа ел тамашасы һәм чыршы тирәсендә әйлән-бәйлән.
24 декабрьдә тамаша татар телендә башкарыла.

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

24 декабрь – «Бременские музыканты» исемле Яңа ел тамашасы.
25 декабрь – «Новогоднее путешествие Красной Шапочки» исемле театральләштерелгән концерт-тамаша.
26 декабрь – «Аленький цветочек» дип исемләнгән Яңа ел тамашасы.
27 декабрь – «Новогоднее путешествие Красной Шапочки» исемле театральләштерелгән концерт-тамаша.
28 декабрь – «Кварто» төркеменең Яңа ел бәйрәменә багышланган концерты.
29, 30 декабрь – «Снегурочка 2.2» Яңа ел спектакле.

С.СӘЙДӘШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

24 декабрь – Татарстан Республикасы дәүләт симфоник оркестрының Яңа ел концерты. Дирижер – Константин Чудовский, солист – Валерия Абрамова (скрипка).
25 декабрь –10.00, 12.30 – «Золушка» Яңа ел спектакле. 15.00, 18.00 – Наталья Железных ансамбле башкаруында Яңа ел концерты.
28 декабрь – 10.00, 12.30 – «Золушка» Яңа ел спектакле. 18.00 – Раштуа фестивале кысаларында «Жизнь в ритме танго» исемле концерт. Катнашалар – Азат Нургаянов (скрипка), Сәйдәш Фәйхразиев (баян), Серафим Лаврентьев (виолончель), Алиса Лабзина (фортепиано, тангерос), Сергей Белянкин һәм Рената Санникова.
30 декабрь – 10.00, 12.30 – «Золушка» Яңа ел тамашасы. 18.00 – Раштуа фестивале кысаларында «Ирония судьбы, или С Новым годом!» исемле концерт. Катнашалар – Татарстанның атказанган артисты Юлия Җиһаншина һәм С.Гобәйдуллина исемендәге заманча музыка үзгәнең дирижер Анна Гөлишамбарова җитәкчелегендәге оркестры.

Казаннан – Катарга

“Иннополис” махсус икътисади зонасы резиденты быел Катарда үткән футбол буенча дөнья чемпионатында “Әхмәд ибн Али” стадионын турникетлар һәм мобиль сканерлар белән тәэмин иткән. Стадионның эчке периметрына барлыгы 94 “Horizon” смарт-турникеты, 30 автоматлаштырылган 30 “Navigare” смарт-капкасы һәм “Contour Classic” премиаль турникеты урнаштырылган. Әлеге электрон контроль системасы нибары дүрт ай эчендә җитештерелгән һәм Казаннан Катарга китереп җиткерелгән, ул биредәге эссе, комлы һәм дымлы һава торышы шартларына яраклаштырып ясалган.

(“Бизнес Online”).

Кайда яшәү яхшырак?

РФ Хөкүмәте каршындагы Финанс университеты төзегән рейтингтан күренгәнчә, Казан тормыш дәрәҗәсе Россиядә иң югары булган шәһәрләр исемлегенең беренче дистәсенә кертелмәгән. Анда беренче урындагы Мәскәү башка калаларны барлык күрсәткечләр, шул исәптән матди байлык күләме һәм медицина хезмәте күрсәтү сыйфаты буенча да артта калдырган. Икенче урында – Сочи. Өченче урынга куелган Грозный шәһәрендә яшәүчеләр биредәге ТКХ эшен, бизнес алып бару уңайлыгын һәм юллар сыйфатын югары бәяләгән. Яшәү өчен иң уңайлы шәһәрләр исемлегендә дүртенче урында – Санкт-Петербург, аннары Нижневартовск, Калининград, Төмән, Владикавказ, Мурманск һәм Череповец килә.

(“Российская газета”).

Киборглар заманы җитәме?

Илон Маск.

Америка эшкуары, космик техника җитештерә торган SpaceX компаниясен оештыручы һәм Twitter челтәренең яңа хуҗасы Илон Маск үзенең Neuralink нейротехнологияләр компаниясендә компьютер һәм смартфонны кулга алмыйча идарә итү мөмкинлеге бирәчәк чипны кешенең баш миенә куярга җыенуы хакында белдергән. Сынау ярты елдан башланачак. Электродлы чыбыклар һәм бик кечкенә җайланмадан гыйбарәт әлеге чипны моның өчен махсус ясалган робот кешенең баш сөяген кисеп үзе урнаштырачак. Маск аңлатуынча, әлеге чипны куюның максаты – инсульттан соң параличланган авыруларга ярдәм итү, алар үз фикерләрен компьютер аша белдерә алачак. Эшкуардан, чипны үз балагызның миенә куяр идегезме, дип сорагач, ул: “Әгәр ул параличланган һәм ярдәмгә мохтаҗ булса, һич икеләнмичә куйдырыр идем”, - дип җавап биргән. Маск әйтүенчә, мондый нейроинтерфейслар кешегә ясалма интеллектка каршы торырлык киборгка әйләнергә мөмкинлек бирәчәк һәм фикер көче ярдәмендә турыдан-туры компьютер белән идарә итәргә өйрәнергә булышачак. Әлегрәк Neuralink баш миенә ике меңнән артык электродтан гыйбарәт чип кертелгән маймылны менталь пинг-понг уйнарга өйрәтүләрен күрсәткән иде инде. Миллиардер үз компаниясенең арка миенә куя торган чиплар ясау планы турында да хәбәр иткән – бу очракта йөри алмаучы кешенең андый мөмкинлеге пәйда булачак. 2016 елда оештырылып, Маскның иң яшерен бизнесы саналган Neuralink стартабы галимнәре күзне алыштырачак имплант ясау белән дә шөгыльләнә икән.

(“Bloomberg”).

Рәшит Сөнниев.

Али Сөнниев.

Шамил Сөнниев.

Данлыклы милләттәшебез

Атаклы астрофизик, РФ һәм ТР Фәннәр академияләре академигы Рәшит Гали улы Сөнниев (Сөнәев) “астрофизика һәм космологиягә керткән фундаменталь хезмәтләре өчен” Макс Планк медале белән бүләкләнгән. Медаль аңа 2023 елның мартында Дрезденда тапшырылачак. Галим үзенең остазы академик Яков Зельдович белән берлектә космостагы реликт нурланышының электроннар тәэсирендә әкренләп таралуы турында Сөнниев-Зельдович эффекты буларак мәгълүм теория тудырган, шулай ук башлангыч Галәмне өйрәнү буенча башка мөһим тикшеренүләрдә катнашкан. Макс Планк медале 1929 елда булдырылган. Аның беренче лауреаты – Альберт Эйнштейн. Әлеге медаль физика өлкәсендә иң абруйлы бүләкләрдән санала. 79 яшьлек милләттәшебезнең гаиләсе дә күпләргә үрнәк булырлык, аның өч улы, бер кызы бар: олы улы Шамил – генетик, АКШтагы Гарвард медицина мәктәбе профессоры, Brigham and Women’s Hospital тикшеренү лабораториясе җитәкчесе (аның Рәуф исемле улы һәм Алия исемле кызы бар); икенче улы Усман Мәскәүдә яши, компьютер белгече, банкта IT бүлеген җитәкли (Алия һәм Алсу исемле кызлары бар); кече улы Али – Карлсруэ технология институтында информатика профессоры, Гамәли информатика институты директоры; кызы Зөлфия – табиб.

(“Die Presse”).

Рәшид Сөнниев гаиләсе ТР Фәннәр академиясендә кунакта (2013 ел).

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

26 декабрь
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Онытa алмыйм...»
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «БӘХЕТЛЕМЕ СИН?» 12+
10.00, 23.00 «КОГДА ПАПА ДЕД МОРОЗ». 12+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
11.30 «Заман көзгесе». 6+
12.00, 22.10 «25 НЧЕ СӘГАТЬ». 16+
13.00 «Семь дней». 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә».
16.00 «Переведи!» 6+
16.30 «Татарлар». 12+
18.00 «Әдәби хәзинә». 6+
19.00, 0.20 «Таяну ноктасы». 16+
20.00 «АЛМАШ». 12+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.50 «Каравай». 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.35, 18.50, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 18.20, 21.25 «АЛМАШ». 12+
8.40, 23.05 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30 «Родная земля». 12+
12.05 «Әниемнең җылы кочагы». 6+
15.30, 20.30 «Заман көзгесе». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
0.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ПТИЧКА ПЕВЧАЯ». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ВЫ ВСЕ МЕНЯ БЕСИТЕ». 16+
10.30, 21.00 «ВЕРЮ НЕ ВЕРЮ». 12+
11.30 «ЭФФЕКТ БОГАРНЕ». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «ЗОЛОТЦЕ». 12+
15.00 «Вокруг света во время декрета». 12+
15.30 «Битва оружейников». 12+
16.15 «Кошечки-собачки».
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.50 «Пусть говорят». 16+
21.00 «Время».
21.45 «КАЗАНОВА В РОССИИ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ДАМА С СОБАЧКОЙ». 12+
23.15 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Невский ковчег. Теория невозможного. Анатолий Кони.
7.35 «Запечатленное время».
8.00 «Звезда Любови Орловой». Рассказывает Мария Миронова.
8.20 «ВОЛГА-ВОЛГА».
10.15 «Наблюдатель».
11.10, 23.50 ХХ век. «Концерт в честь артиста. Юбилейный вечер Аркадия Райкина».
12.35 «ЛЮДИ И МАНЕКЕНЫ».
13.55 Цвет времени. Жан Этьен Лиотар. «Прекрасная шоколадница».
14.05 Народные артисты СССР. Владимир Минин.
15.05 Новости. Подробно. АРТ.
15.20 «Агора».
16.25 Народные артисты СССР. Людмила Чурсина.
17.20 Юбилейный концерт к 90-летию Родиона Щедрина.
18.45 «Девчата». Фигуры может и нет, а характер - налицо!»
19.45 Главная роль.
20.05 Линия жизни. Наталья Варлей.
21.00 «По следам сирийских мудрецов».
21.40 «ПЕРВАЯ СТУДИЯ».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.45 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «АГЕНТСТВО «СПРАВЕДЛИВОСТЬ». 16+
22.00, 0.05 «ПЁС». 16+

Сишәмбе

27 декабрь
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Онытa алмыйм...»
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «БӘХЕТЛЕМЕ СИН?» 12+
10.00, 23.00 «КОГДА ПАПА ДЕД МОРОЗ». 12+
11.00 «Азбука долголетия». 6+
11.15 «Память сердца». 12+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «25 НЧЕ СӘГАТЬ». 16+
13.00 «Родная земля». 12+
13.30 «Юлчы». 6+
14.00 «Путь». 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
15.15 «Төймә».
16.00 «Казанское суворовское. Школа патриотов». 12+
18.00 «Казаннан - казанга». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00 «АЛМАШ». 12+
21.00 «Черное озеро». 16+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.50 «Видеоспорт». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 18.20, 21.25 «АЛМАШ». 12+
8.40, 23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
9.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
12.35 «Ватандашлар». 6+
15.30 «Йөрәктән-йөрәккә». Венера Шәрипова турында телеочерк. 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
18.50, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
0.15 «Тамчы-шоу». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ПТИЧКА ПЕВЧАЯ». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ВЫ ВСЕ МЕНЯ БЕСИТЕ». 16+
10.30 «ВЕРЮ НЕ ВЕРЮ». 12+
11.30 «ЭФФЕКТ БОГАРНЕ». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «ЗОЛОТЦЕ». 12+
15.00 «Вокруг света во время декрета». 12+
15.30 «Битва оружейников». 12+
16.15 «Кошечки-собачки».
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.50 «Пусть говорят». 16+
21.00 «Время».
21.45 «КАЗАНОВА В РОССИИ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ДАМА С СОБАЧКОЙ». 12+
23.15 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Невский ковчег. Теория невозможного. Пётр Первый.
7.30 «Запечатленное время».
7.55 «Звезда Марины Ладыниной». Рассказывает Валерия Ланская.
8.10 «КУБАНСКИЕ КАЗАКИ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10, 23.50 ХХ век. «Золотой шлягер. Песни прошлых лет».
12.25 Цвет времени. Караваджо.
12.40 «ЛЮДИ И МАНЕКЕНЫ».
14.05 Народные артисты СССР. Тамара Синявская.
15.05 Новости. Подробно. Книги.
15.20 «Весёлый жанр невесёлого времени».
16.00 Народные артисты СССР. Юрий Соломин.
17.00 «Рассекреченная история».
17.30 Вручение Премии имени Дмитрия Шостаковича.
18.15 «Испания. Тортоса».
18.45 «Зигзаг удачи». Я, можно сказать, её люблю».
19.45 Главная роль.
20.05 Линия жизни. Максим Никулин.
21.00 «По следам сирийских мудрецов».
21.40 «ПЕРВАЯ СТУДИЯ».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.45 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «АГЕНТСТВО «СПРАВЕДЛИВОСТЬ». 16+
22.00, 0.05 «ПЁС». 16+

Чәршәмбе

28 декабрь
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Онытa алмыйм...»
5.50, 7.00, 18.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.00 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «БӘХЕТЛЕМЕ СИН?» 12+
10.00, 23.30 «КОГДА ПАПА ДЕД МОРОЗ». 12+
11.00, 0.45 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.40 «СӨЮЛӘРЕМ СИНЕ ХАК МИНЕМ». 12+
13.00 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Если хочешь быть здоровым». 12+
14.15 «Туган авылым». 6+
15.15 «Бергәләп өйрәник».
16.00 «Переведи!» 6+
18.00 «Таяну ноктасы». 16+
19.30 Хоккей. «Ак Барс» - «Металлург» (Мг). 6+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «Спортивная среда». 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 8.40, 23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 18.20, 21.25 «АЛМАШ». 12+
9.40 «Ачыктан - ачык». 12+
10.40 «Туган авылым». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
12.35 «Ватандашлар». 6+
15.30, 0.15 «Яшьләр тукталышы». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
18.50, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.30 «Юлчы». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ПТИЧКА ПЕВЧАЯ». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «ВЫ ВСЕ МЕНЯ БЕСИТЕ». 16+
11.30 «ЭФФЕКТ БОГАРНЕ». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «ФЛАМИНГО». 12+
14.45 «Театральное закулисье». 12+
15.00 «Вокруг света во время декрета». 12+
15.30 «Трудовой фронт Великой Отечественной». 12+
16.15 «Кошечки-собачки».
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
20.00 «ВСЕ, ЧТО НАМ НУЖНО». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
21.00 «Время».
21.45 «КАЗАНОВА В РОССИИ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ДАМА С СОБАЧКОЙ». 12+
23.15 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Невский ковчег. Теория невозможного.
7.35 «Запечатленное время».
8.05 «Звезда Веры Марецкой». Рассказывает Олеся Судзиловская.
8.20 «СЕЛЬСКАЯ УЧИТЕЛЬНИЦА».
10.15 «Наблюдатель».
11.10, 23.50 ХХ век. «Кинопанорама. Нам 30 лет».
12.25 Дороги старых мастеров. «Вологодские мотивы».
12.40 «ЛЮДИ И МАНЕКЕНЫ».
13.50 Народные артисты СССР. Владимир Васильев.
15.05 Новости. Подробно. Кино.
15.20 «Весёлый жанр невесёлого времени».
16.00 Народные артисты СССР. Алиса Фрейндлих.
16.45 «Рассекреченная история».
17.15 XIV Международный конкурс артистов балета. Гала-концерт лауреатов.
18.45 «Снежная королева». Оживи, милый!»
19.45 Главная роль.
20.05 Линия жизни. Надежда Бабкина.
21.00 «По следам сирийских мудрецов».
21.40 «ЭТОТ МЕХ НОРКИ».
23.20 Цвет времени. Жорж-Пьер Сёра.

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.45 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «АГЕНТСТВО «СПРАВЕДЛИВОСТЬ». 16+
22.00, 0.05 «ПЁС». 16+

Пәнҗешәмбе

29 декабрь
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Онытa алмыйм...»
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «ЯҢА ЕЛДА БЕРГӘ БУЛЫЙК!» 12+
10.00, 23.00 «КОГДА ПАПА ДЕД МОРОЗ». 12+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00 «СӨЮЛӘРЕМ СИНЕ ХАК МИНЕМ». 12+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Туган авылым». 6+
14.15 «Рыцари вечности». 12+
15.15 «Шома бас» һәм «Алты хәреф».
16.00, 21.00, 0.15 «Соотечественники». 12+
18.00 «Юлчы». 12+
19.00 «Точка опоры». 16+
20.00 «АЛМАШ». 12+
21.20 «Газпром трансгаз Казань. Итоги года». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «СӨЮЛӘРЕМ СИНЕ ХАК МИНЕМ». 12+
23.50 «Видеоспорт». 12+
0.40 «Каравай». Игрушки. 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 18.20, 21.25 «АЛМАШ». 12+
8.40, 23.05 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Кунак БИТ Шоу». 12+
10.40 «Туган авылым». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05 «Таяну ноктасы». 16+
12.35 «Ватандашлар». 6+
15.30, 0.15 «Халкым минем». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
18.50, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Йөрәктән - йөрәккә». Әхәт Гаффар турында телеочерк. 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30 «ПТИЧКА ПЕВЧАЯ». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ВСЕ, ЧТО НАМ НУЖНО». 12+
11.30 «НОВОГОДНИЙ ПАССАЖИР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «ФЛАМИНГО». 12+
14.30 «Театральное закулисье». 12+
14.45 «Архивы истории». 12+
15.00 «Вокруг света во время декрета». 12+

15.30 «Трудовой фронт Великой Отечественной». 12+
16.15 «Кошечки-собачки».
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
23.00 «НОВЫЙ СТАРЫЙ ДОМ». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.50 «Пусть говорят». 16+
21.00 «Время».
21.45 «КАЗАНОВА В РОССИИ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ДАМА С СОБАЧКОЙ». 12+
23.15 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Невский ковчег. Теория невозможного. Борис Кустодиев.
7.35 «Запечатленное время».
8.00 Цвет времени. Жорж-Пьер Сёра.
8.10 «Звезда Валентины Серовой». Рассказывает Марина Александрова.
8.25 «СЕРДЦА ЧЕТЫРЕХ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. «Бенефис Людмилы Гурченко».
12.40 «ЛЮДИ И МАНЕКЕНЫ».
14.05 Народные артисты СССР. Людмила Семеняка.
15.05 Новости. Подробно. Театр.
15.20 «Весёлый жанр невесёлого времени».
16.00 Народные артисты СССР. Вера Васильева.
17.00 «Рассекреченная история».
17.30 100-летие российского джаза. Игорь Бутман, Московский джазовый оркестр и участники проекта «Большой джаз».
18.35 Цвет времени. Альбрехт Дюрер. «Меланхолия».
18.45 «Морозко». Нет! Не прынцесса! Королевна».
19.45 Главная роль.
20.05 Линия жизни. Виктор Добронравов.
21.00 «По следам сирийских мудрецов».
21.40 «В ЕГО ПРИЯТНОЙ КОМПАНИИ».
23.50 «Москва».

«НТВ»
5.00 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.45 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «АГЕНТСТВО «СПРАВЕДЛИВОСТЬ». 16+
22.00, 0.05 «ПЁС». 16+

Җомга

30 декабрь «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35, 14.45 «Оныта алмыйм...»
5.50, 7.00, 18.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.00 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «ЯҢА ЕЛДА БЕРГӘ БУЛЫЙК!» 12+
10.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
11.00 «Нәсыйхәт». 6+
11.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «СӨЮЛӘРЕМ СИНЕ ХАК МИНЕМ». 12+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 6+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я». 12+
15.15 «Тизрәк! Алга! Җитезрәк!» һәм «Алты хәреф».
16.00 «Аулак өй». 6+
16.30 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Туган җир». 12+
19.30 Хоккей. «Ак Барс»- «Нефтехимик». 6+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.50 «ПУТЬ СКВОЗЬ СНЕГА». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 20.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
8.40, 23.05 «Ком сәгате». 12+
9.40, 15.30, 0.15 «Нәсыйхәт». 6+
10.30 «Казаннан казанга». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30 «Татарлар». 12+
12.05 «Яралы язмышлар». 12+
12.35 «Уткәннәр сагындыра». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 0.40 «Калеб». 6+
18.20 «Әниемнең җылы кочагы». 6+
19.15 «Туган җир». 12+
19.40 «Заман көзгесе». 6+
21.25 Спектакль «Хәйләсез - дөнья файдасыз». 12+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30 «Спасите, я не умею готовить!» 12+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «ВСЕ, ЧТО НАМ НУЖНО». 12+
11.30 «НОВОГОДНИЙ ПАССАЖИР». 12+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.50 «ПОЙМАННЫЙ В РАЮ». 16+
15.00 «Спасти Санту». 6+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.30 «Fam TV». 16+
20.00 «С НОВЫМ ГОДОМ, МАМЫ!» 6+
21.40 «Театральное закулисье». 12+
23.00 «НОВЫЙ СТАРЫЙ ДОМ». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 «Голос. Дети».
23.20 «Джентльмены удачи». 12+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 21.15 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30 «КРАСНЫЙ ПРОЕКТ». 12+
13.50, 16.30 «УКРОЩЕНИЕ СВЕКРОВИ». 12+
21.30 «КОНЁК-ГОРБУНОК». 6+
23.35 «ПОСЛЕДНИЙ БОГАТЫРЬ». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 10.00, 15.00, 19.30, 23.10 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Невский ковчег. Теория невозможного. Николай Гоголь.
7.30 «Запечатленное время».
8.00 «Звезда Фаины Раневской». Рассказывает Агриппина Стеклова.
8.15 «ВЕСНА».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Москва».
12.10 Цвет времени. Рене Магритт.
12.20 «13 ПОРУЧЕНИЙ».
13.30 «Юбилей на Марсовом поле».
14.10 Народные артисты СССР. Александра Пахмутова.
15.10 «Весёлый жанр невесёлого времени».
15.55 Народные артисты СССР. Олег Басилашвили.
17.00 «Рассекреченная история».
17.30 Гала-концерт «Наследники традиций».
19.15 «Первые в мире».
19.45 Главная роль.
20.05 Линия жизни. Нина Мозер.
21.00 «По следам сирийских мудрецов».
21.40 «БЕГЛЕЦЫ».
23.30 «2 Верник 2». Ильдар Абдразаков.

«НТВ»
4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
9.25, 10.35 «ЛЕСНИК». 16+
12.00 «Хочу жить вечно!» 12+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «ДНК». 16+
17.55 «Жди меня». 12+
20.00 «АГЕНТСТВО «СПРАВЕДЛИВОСТЬ». 16+
22.00 «ПЁС». 16+
23.00 «VK под шубой». 12+

Шимбә

31 декабрь «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...»
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
7.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00, 16.10 «ЯҢА ЕЛДА БЕРГӘ БУЛЫЙК!» 12+
10.00 «Казаннан - казанга». 12+
10.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
11.00 «Яңа ел уенчыкларының тылсымлы сере». Республиканская новогодняя ёлка.
12.00 «Год культурного наследия народов России в РТ».
12.10 Мультфильмы. 6+
12.30 «Видеоспорт». 12+
13.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
14.00 «АЛМАШ». 12+
16.00 «Итоги года».
17.00 «СӨЮ КӨТӘ ЙӨРӘК». 12+
18.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30 Новости в субботу. 12+
20.00 «Кәмит Җәвит». 16+
21.00 «Җырлыйк әле!» 6+
22.05 «ХӘСИТӘ». 6+
23.50 Новогоднее обращение Президента РТ Р.Н.Минниханова.
23.55 Новогоднее обращение Президента РФ В.В.Путина.
0.05 «Яңа Гасыр» да Яңа ел төне». 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». Әхәт Гаффар турында телеочерк. 6+
7.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Кәмит Җәвит». 16+
10.00 «Йөрәктән - йөрәккә». Фердинанд Сәләхов турында телеочерк. 6+
11.00, 18.40 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.35 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 «Туган авылым». 6+
13.20 «Яңа ел уенчыкларының тылсымлы сере». Республика Яңа ел чыршысы. 6+
14.20, 17.30 «Тылсымлы бәйрәм мизгелләре». 6+
14.50 «2022-й – Год культурного наследия народов России в РТ». 6+
17.00 «Халкым минем». 12+
18.30 «Итоги года». 12+
20.35 «ЯҢА ЕЛ ТӨНЕНДӘ». 12+
22.05 «ХӘСИТӘ». 6+
23.50 Татарстан Президенты Р.Н.Миңнеханонвың Яңа ел котлавы. 6+
23.55 Россия Федерациясе Президенты В.В.Путинның Яңа ел котлавы. 6+
0.01 «Яңа Гасыр»да Яңа ел төне». 6+

«ЭФИР»
5.00 «Архивы истории». 12+
5.10 «Театральное закулисье». 12+
5.25 «НОВЫЙ СТАРЫЙ ДОМ». 12+
7.00 «Лео и Тиг».
8.00 «Вокруг света во время декрета». 12+
8.30 «НОВОГОДНИЙ ПЕРЕПОЛОХ». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «С НОВЫМ ГОДОМ, МАМЫ!» 6+
14.30 «ПРАЗДНИК ВЗАПЕРТИ». 16+
16.00 «90-Е. ВЕСЕЛО И ГРОМКО». 16+
19.00, 2.00, 3.00 «Город». 16+
21.00 «МАМЫ 3». 12+
22.35 «Новогодний парад звезд». 12+
0.00 «Золушка». 12+
1.30 «Вместе по России». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00, 6.10 «ПОЛОСАТЫЙ РЕЙС». 12+
6.00, 10.00, 12.00, 18.00 Новости.
6.30 «ДЕВУШКА БЕЗ АДРЕСА».
7.55 «ВАРВАРА-КРАСА, ДЛИННАЯ КОСА».
9.15, 10.15 «ЗОЛУШКА».
10.50, 12.15 «ДЕВЧАТА».
12.40 «ОПЕРАЦИЯ «Ы» И ДРУГИЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ ШУРИКА».
14.15 «ДЖЕНТЛЬМЕНЫ УДАЧИ». 12+
15.40 «БРИЛЛИАНТОВАЯ РУКА». 12+
17.15, 18.15 «ЛЮБОВЬ И ГОЛУБИ». 12+
19.15 «ИРОНИЯ СУДЬБЫ, ИЛИ С ЛЕГКИМ ПАРОМ!» 12+
22.22, 0.00 Новогодняя ночь на Первом. 20 лет спустя. 16+
23.55 Новогоднее обращение Президента РФ В.В.Путина.

«РОССИЯ»
4.45 «ДОЯРКА ИЗ ХАЦАПЕТОВКИ». 12+
6.35 «УПРАВДОМША». 12+
9.45 «КАРНАВАЛЬНАЯ НОЧЬ».
11.00, 20.00 Вести.
11.20 Вести. Местное время.
11.30 «МОСКВА СЛЕЗАМ НЕ ВЕРИТ». 12+
14.00 «СЛУЖЕБНЫЙ РОМАН». 12+
16.50 «КАВКАЗСКАЯ ПЛЕННИЦА, ИЛИ НОВЫЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ ШУРИКА». 6+
18.10, 20.30, 23.00 «Песни от всей души». 12+
21.30 «ИВАН ВАСИЛЬЕВИЧ МЕНЯЕТ ПРОФЕССИЮ». 6+
23.55 Новогоднее обращение Президента РФ В.В.Путина.
0.00 Новогодний голубой огонёк - 2023.

«КУЛЬТУРА»
6.30 Мультфильмы.
7.55 «ТАЙНА СНЕЖНОЙ КОРОЛЕВЫ (СКАЗКА ПРО СКАЗКУ)».
10.15 «Передвижники. Павел Третьяков».
10.55 «Волшебные мгновения в дикой природе».
11.50 Международный фестиваль «Цирк будущего».
13.15 «УСАТЫЙ НЯНЬ».
14.30 Всероссийский конкурс юных талантов «Синяя птица».
16.15 «Марк Захаров. Технология чуда».
16.55 «ОБЫКНОВЕННОЕ ЧУДО».
19.15 Новогодний вечер с Юрием Башметом.
21.05 «ДУЭНЬЯ».
22.35 «Романтика романса».
23.55 Новогоднее обращение Президента РФ В.В.Путина.

«НТВ»
5.30 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.15, 8.20, 10.20, 13.20, 16.15 «ПЁС». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00 «Сегодня».
18.35 «НОВОГОДНИЙ ПЁС». 16+
20.23, 0.00 «Новогодняя Маска + Аватар». 12+
23.55 Новогоднее обращение Президента РФ В.В.Путина.
2.00 «Новогодний Квартирник НТВ у Маргулиса. Гараж желаний». 16+

Якшәмбе

1 гыйнвар. «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
6.00 «Рәхәт яшибез!» 12+
8.00 «Сәйлән-2022».
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
10.00 «ЯЗМЫШЛАРДАН УЗМЫШ ЮК ИКӘН». 12+
14.00 «Чародей равновесия. Тайна Сухаревой башни». 6+
15.15 «Пар алма». Илназ Баһ һәм Гүзәл Идрисова концерты. 6+
17.00 «Әниемнең җылы кочагы». 6+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00 «Болгар радиосы» премиясен тапшыру тантанасы. 12+
22.30 «МОЯ МАМА СНЕГУРОЧКА». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
6.00 «Түгәрәк бәхет». Айдар Тимербаевның иҗат кичәсе. 6+
8.20 Әсхәт Хисмәтовның 70 яшьлек юбилей кичәсе. 6+
11.00 «Сәйлән» балалар телевизион фестивале. 6+
12.05 «Менә ул бәхет!» 12+
13.30 «Яңа елны ТНВ белән бергә каршылыйк!» 6+
18.00 «Кыр казлары артыннан». Илдар Юзеев турында телеочерк. 6+
19.00 «Болгар радиосы» премиясен тапшыру тантанасы. 6+
22.00 Спектакль «Ут күршеләр». 12+
23.55 Спектакль «Хуҗа Насретдин». 12+

«ЭФИР»
5.00, 14.30 «Вместе по России». 12+
5.30, 15.50 «НОВОГОДНИЙ БРАК». 6+
7.00 «Белка и Стрелка. Тайны космоса».
8.00 «Барышня и кулинар». 12+
8.30 «НОВОГОДНЕЕ СЧАСТЬЕ». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ЗАГАДАЙ ЖЕЛАНИЕ». 12+
15.00 «Загляните к нам на «Огонек». 12+
17.30 «Золушка». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ГОЛОСА БОЛЬШОЙ СТРАНЫ». 6+
22.45 «ЗАЙЦЕВ, ЖГИ! ИСТОРИЯ ШОУМЕНА». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00 «Новогодний календарь».
6.55 «ОПЕРАЦИЯ «Ы» И ДРУГИЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ ШУРИКА».
8.25 «ДЕВЧАТА».
10.00, 12.00 Новости.
10.15, 12.15 «ИРОНИЯ СУДЬБЫ, ИЛИ С ЛЕГКИМ ПАРОМ!» 12+
13.40 «БРИЛЛИАНТОВАЯ РУКА». 12+
15.15 «ЛЮБОВЬ И ГОЛУБИ». 12+
17.00 «Мечталлион». 12+
17.50 «Наш Новый год». 12+
19.05 «КВН». 16+
21.00 «Время».
21.45 «МАЖОР ВОЗВРАЩАЕТСЯ». 16+
23.25 «ИРОНИЯ СУДЬБЫ. ПРОДОЛЖЕНИЕ». 12+

«РОССИЯ»
5.10 «КАРНАВАЛЬНАЯ НОЧЬ».
6.25 «МОСКВА СЛЕЗАМ НЕ ВЕРИТ». 12+
9.00 «СЛУЖЕБНЫЙ РОМАН». 12+
11.45 «КАВКАЗСКАЯ ПЛЕННИЦА, ИЛИ НОВЫЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ ШУРИКА». 6+
13.05 «Песня года».
14.55 «ИВАН ВАСИЛЬЕВИЧ МЕНЯЕТ ПРОФЕССИЮ». 6+
16.30 «ОДЕССКИЙ ПАРОХОД». 12+
18.00 «ПОСЛЕДНИЙ БОГАТЫРЬ. КОРЕНЬ ЗЛА». 6+
20.00 Вести.
20.45 Вести. Местное время.
21.00 «ПОСЛЕДНИЙ БОГАТЫРЬ. ПОСЛАННИК ТЬМЫ». 6+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Двенадцать месяцев».
7.30 «ПОХИЩЕНИЕ».
10.25 «Запечатленное время».
11.00 «Маленький бабуин и его семья».
11.55 «ПРО КРАСНУЮ ШАПОЧКУ».
14.15 «Пласидо Доминго и друзья». Гала-концерт в театре Ковент-Гарден.
15.45 «БЕГЛЕЦЫ».
17.15 «Сокровища Московского Кремля». «Избранный, но не Призванный...»
18.10 Гала-концерт звёзд «Под сказочным небом «Геликона».
19.45 «Невероятные приключения Луи де Фюнеса».
20.35 «ЧЕЛОВЕК-ОРКЕСТР».
22.00 Спектакль «Щелкунчик».
23.25 «Рождество в гостях у Тюдоров с Люси Уорсли».

«НТВ»
4.55 «Следствие вели...» 16+
5.55 «ДЕД МОРОЗ. БИТВА МАГОВ». 6+
7.45, 9.50 «В ЗОНЕ ДОСТУПА ЛЮБВИ». 16+
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.50 «АФОНЯ».
12.20, 17.00, 19.20 «АБСУРД». 16+
15.30 «Новогодний миллиард».
19.00 «Сегодня».
21.00 «Суперстар! Возвращение». 16+
23.45 «ВЕЗЁТ». 16+

Язма мирасны өйрәнүче булырмы?

Татарстан Милли китапханәсенең борынгы китап һәм кулъязмалар җыю тәҗрибәсе чагыштырмача зур түгел. Китап йорты бу юнәлештә эшчәнлеген 1992 елда кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге оешуга бәйле рәвештә кабызып җибәрә һәм хезмәткәрләр фәнни-археографик экспедицияләр дә уздыра башлый.

Быел Милли китапханәнең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге оешуга 30 ел тулды. Шушы уңайдан кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегенең өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Раиф Мәрданов «Милли китапханәнең археографик экспедицияләре» дигән хезмәт тә әзерләп чыгарган. Ул – кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегенең утызынчы китабы. Шушы вакыйгалар уңаеннан китапханәнең күргәзмәләр залында археографик экспедицияләрдә катнашкан тарихчы галимнәр, журналистлар, археографлар, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкертләре һ.б. катнашында зур сөйләшү узды. Аны Татарстан Милли китапханәсенең директоры урынбасары Ирек Һадиев алып барды.

Галимнәребез рухи байлык язма мирасыбызны җыю белән шөгыльләнә. Кулъязмаларны һәм сирәк китапларны халыктан җыю кайбер чорларда бик актив барса, бу эшнең тынып торган еллары да була. Хәзерге вакытта Татарстан милли китапханәсендә археографик экспедицияләрне кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге мөдире Айрат Заһидуллин алып бара.

Әлбәттә, археографик экспедицияләргә ел саен чыга торгач, шактый кыйммәтле байлык җыелган, алар арасында фәнгә билгеле булмаган дастаннар да, тарихи сәхифәләрне тәгаенләрдәй көндәлекләр да табыла тора. Әйтик, Арча районы Урта Пошалым авылында Нургали абзый бик каләм булмаган, бик әйбәт саклан-маган бер китап тапшыра. Ул әдәбият тарихында билгесез дастан булып чыга. Шул ук районның Яңа Сәрдә авылында «Солдат Ярулла дәфтәре» – кызыклы табылдыклардан. Татарстан Милли китапханәсенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, тарих фәннәре кандидаты Ильяс Мөстәкыймов 1997 елда китап сөючe бер бабайдан калган берничә кулъязма арасында XVI гасыр шагыйре Пирмөхәммәт Зәгыйфинең үз кулы белән күчергән шигъри һәм тезмә әсәрләре җыентыгын табып ала. Шуңа охшаш хәл 2003 елда да була. Волжск мәчетеннән алып кайтылган кулъязмалар арасыннан саргаеп беткән, 1920 еллар ахырында язылган бер бит кәгазь чыга. Аның күренекле дин эшлеклесе, шагыйрь Мөхәммәтсадыйк Иманколыйның әлегә кадәр мәгълүм булмаган шигыре икәне ачыклана. Археографларны куандыра торган мондый хәлләр булгалый. Билгеле ки, чормаларда, сандыкларда кулъязмалар әрәм булачак, бу инде сирәк булса да очрый торган әнҗе бөртекләре дә юкка чыгачак, дигән сүз. Ә китапханәләрдә, мирасханәләрдә алар махсус шартларда саклана, галимнәребез тарафыннан өйрәнелә, фәнни әйләнешкә кертелә.

Бүген Казан университеты китапханәсендә 15 меңнән, Милли китапханәдә 8 меңнән артык берәмлек кулъязма саклануы мәгълүм. Моннан тыш Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының язма һәм музыкаль мирас үзәгендә XII–XX гасырлар дип тамгаланган иске татар, госманлы, үзбәк, гарәп, фарсы, калмык телләрендәге кулъязма һәм сирәк очрый торган китаплар рәвешендә 50 мең ядкәр саклана. Шулай ук Милли музей фондларында һәм Татарстан архив эше буенча дәүләт комитетында да кулъязма ядкәрләр хәтсез.

30 еллык тарих – күп вакыт түгел, әмма адәм баласының хәтере бу еллар дәвамында булган, шушы юнәлешкә кагылышлы вакыйгаларның, саннарның, шәхесләрнең табылган табышларның һәммәсен дә исендә калдыра алмый. Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклана торган байлыкны фәнни әйләнешкә кертү, күбрәк халыкка җиткерү максаты белән китапханәдә 2008 елдан башлап «Татар археографиясе» дигән серия нәшер ителә. 30 китапның барысы да бер рәвештә бизәлгән, бер төрле тышлык белән эшләнгән. Шул ук вакытта кулъязмаларны, борынгы китапларны тасвирлау, цифрлаштыру эше дә бара. Хәзерге вакытта сигез меңнән артык берәмлекнең өч меңнән артыгы цифрлаштырылган. Димәк, һәркем, бүлек сайтына кереп, куъязмаларның электрон варианты белән түләүсез таныша ала.

Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты директоры Искәндәр Гыйләҗев археографик экспедицияләрнең төп асылы – халыкта сакланган рухи байлыкны саклап калу, аны киләчәк буынга җиткерү икәнлеген ассызыклады. Әмма алга кулъязмаларны өйрәнүдә өзеклекләр килеп тумасмы, дигән сорау килеп баса. Республикада бүген гарәп, фарсы телләрен белүчеләр бармак белән белән генә санарлык. Хәзер хәтта үз туган телендә сөйләшүчеләр, татарча китапларны укучылар да кими. «Кулъязмаларны җыябыз, сакларга тырышабыз, әмма кем аларны өйрәнер, кем аларны алдагы буыннарга тапшырыр? Без «татарлар – мәдәниятле халык» дип мактанабыз, ләкин бөеклекне һәрвакыт исбатлап торырга кирәк. Китапка хөрмәт милли традиция булып кына сакланып калмасын, хәзерге яшьләр дә шуны алып барсын иде. Бөек дип кенә бөек булып калып булмый. Байлыкка таянып эш алып барылырга тиеш», – диде И.Гыйләҗев.

Галим үзе университетта белем алып йөргән вакытта, Лобачевкий исемендәге китапханәгә Германия, Америка, Франция, Япониядән галимнәрнең килүенә игътибар иткән. «О-о-о сездә нинди китаплар бар!», – дип алар соклану белдергән. Бу галимнәр гарәп, төрек, фарсы телләрен белә, кулъязма байлыкны барлап, немец, инглиз, япон телләрендә безнең мәдәниятка багышланган китаплар яза. Археографик экспедицияләрнең соңгы максаты җыелган, махсус шартларда сакланган кулъязмаларны өйрәнү, анализлау, барлау, халыкка җиткерү булырга тиеш. Китапханәдә бу көнне тәкъдим ителгән «Татар археографиясе» сериясендә чыккан 30 нчы китапның тиражы исә – нибары 100 нөсхә. Әлбәттә, ул сайтта да бар. Әмма бар кеше дә сайтка керми. Татарстан Президентының матбугат үзәге җитәкчесе урынбасары, үзе дә 2000 елларда археографик экспедицияләрдә катнашкан Ләззәт Хәйдәров Энциклопедия институты, Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Милли китапханә һ.б. оешмалар арасыннан санап карагач, утызлап белгеч кенә булуы ачыклана. Бу исәпкә керүчеләрнең иң яше дә – гомер уртасын узган кешеләр. Бүген аларны алыштырырга яшь белгечләр юк. Археографлар Казан дәүләт университетында Татар филологиясе һәм Көнчыгыш телләре факультеты эшләгән вакытта әзерләнгән. Анда студентлар нәкъ менә археограф булып эшләгәндә кирәкле гарәп һәм иске татар язуларын өйрәнү, палеография, тарих белеменең кулъязмаларга кагылышлы дисциплинасы, хронология кебек нечкәлекләре буенча да белем алган. Ирек Һадиев искәрткәнчә, кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегенә күпмедер дәрәҗәдә шушы юнәлештә укыган яшьләрне эшкә чакырып, тагын күпмедер күнекмәләр өстәп, хезмәткәрләр әзерләгәннәр. Әмма, кызганыч ки, соңгы вакытта мондый белгечләр китапханәгә килми. Китапханәнең үзенең эчке резервларыннан файдаланып, кайдадыр башка бүлекләрдә эшләүче, татар телен камил белгән, тарих һәм фән юнәлешен беркадәр үзләштергән кешеләрне Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегенә күчереп, элек гарәп язуын белгән булса, исенә төшереп, юк икән бераз өйрәтеп, шул юллар белән әлегә кыен хәлдән чыгалар. «Әмма бу – мәсьәләне хәл итүнең дөрес юлы түгел. Махсус уку йортларында белем алган яшьләр кирәк. Дөрес, алар белгечлекне камил дәрәҗәдә үзләштермәгән булырга, шундук эшкә керешә алмаска да мөмкин, әмма гамәли күнекмәләр аша шомарачаклар. Безгә хәзер иске татар язуын белә торган кешеләр эшкә килми. Яшьләр арасында андый кешеләр юк», – ди И.Һадиев.

Ә инде азмы-күпме гарәп, фарсы телләрен, язуын, татар әдәбиятын белгән, тарихтан, әдәбияттан мәгълүматлы кеше табылган очракта да, аны китапханәләр, мирасханәләрдәге хезмәт хакы канәгатьләндерерме? Мәдәни-гыйльми учреждениеләр әлегә әллә ни югары хезмәт хаклары белән мактана алмый. Авыл-районнардан килгән яшь белгечләрнең торак мәсьәләсе хәл ителмәү сәбәпле дә, башка урыннарга да күчеп китүе кебек очраклар күп. Айрат Заһидуллин яшь егет яки кызның бүлектәге эшнең акчасына да риза булган очракта, көне буе кәгазь тузаны эчеп утырырга теләмәү ихтималы булуын да кисәтте. «Кеше иң әүвәл китапны шул дәрәҗәдә яратырга, ул кулъязманы кулына алганда ниндидер яңа ачыш ясаячагына инанырга, сөенергә тиеш».

Әмма республика күләмендә планлы әзерлек алып барылмый. «Әгәр шушы мирасны саклап калырга телибез икән, махсус белгечләр әзерләү дәүләт программасына кертелергә, Казан федераль университетында укытылырга тиеш. Эшли башлагач, аларга нормаль хезмәт хакы билгеләү мәслихәт. Без бу эшләрне башкармыйча, беркая да бара алмыйбыз», – ди И.Гыйләҗев.

Л.Хәйдәров исә югары даирәләрдә Татарстанның Кулъязма үзәген булдыру турында сөйләшүләр баруын әйтте. Әлеге максаттан инде революциягә кадәр Кәримовлар типографиясе булган бина (соңрак ул «Эбиволь» галереясы исеме белән билгеле) күз уңына алынган. Ул – «Мөхәммәдия»дә укучылар өчен күрше бина буларак билгеле. «Киләчәктә Галиев мәчете, Диния нәзарәте каршында булган шул матур бинада, аны заманча төзекләндереп, кулъязмалар, китаплар саклану өчен шартлар тудырып, татар халкының борынгы китап үзәге ачу хыялы бар», – диде Л.Хәйдәров. Анда нинди китаплар (музей кулъязмаларымы, Милли китапханәнекеме) сакланачагы әлегә тәгаенләнмәгән (Милли китапханәнең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге дә элекке комсомол комитеты бинасында яраклаштырылган, әмма махсус саклау үзәге буларак төзелмәгән бинада эшли).

Күптән түгел узган киңәшмәдә кешеләрнең үз милкендә булган истәлекле кулъязма китапны, яисә документны, мираска карата шәхси милек хокукларын саклап, кулъязма китаплар үзәгенә тапшыра алу мөмкинлеге турындагы фикер дә әйтелгән. Бу очракта да мирасханә да әлеге китап өчен үзенә җаваплылык ала, шул ук вакытта аңардан галимнәр, фәнни хезмәт язучылар да файдалана ала. Әмма ул аны сата да, алыштыра да алмый.

Археографлар белдергәнчә, әлегә татар халкында язма мирасыбыз бар, чормаларда, сандыкларда юкка чыгып бара торган байлыкны җыю, бер урынга туплау мәслихәт.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.

«Рөстәм маҗаралары», *яки* Күләгәдә калган бала күңеле

«Һөнәр» XIV Бөтенроссия яшь режиссура фестивалендә тамашачыларга тәкъдим ителгән премьераларның берсе Г.Кариев исемендәге Татар дәүләт яшь тамашачы театрында куелган «Рөстәм маҗаралары» спектакле сугыш темасын күтәрүе белән көн кадагына суга. Спектакль фронтовик шагыйрь, язучы, публицист Гадел Кутуйның 1944 елда язылган һәм тәмамланмый калган «Рөстәм маҗаралары» фантастик-хыялый повестенә нигезләнгән. Язучының улы шулай ук язучы һәм тәрҗемәче Рөстәм Кутуй 1960 елларда аны рус теленә тәрҗемә итә.

Әмма әсәрне сәхнәгә куярга тотынгач татар һәм рус телендәге нөсхәләр арасында аерма барлыгы ачыклана, шуңа күрә инсценировка авторы Айдар Әхмәдиев һәм режиссер Тимур Кулов язучының фронт хатларына һәм көндәлекләргә дә мөрәҗәгать итәргә була. Спектакльне куйганда килеп чыккан кыенлыклар бер яктан әсәрнең тәмамланмый калуы белән бәйле булса, абага чәчәге ашап күзгә күренмәскә әйләнгән малайны сәнгать чаралары белән сурәтләү шулай ук иҗатчыларны байтак вакыт эзләнергә, уйланырга мәҗбүр итә.

Спектакльдә персонажлар күп булса да, аларны Татарстанның атказанган артисты Альбина Гайзуллина һәм Булат Гатауллин гына башкара. Бу ике артистның бер рольдән икенчесенә оста күчүен күрер өчен генә дә карарга мөмкин бу спектакльне.

Татар классикасының куелуы күңелгә сары май булып ятса да, «Рөстәм маҗаралары» пропаганда белән агуланган яшь буынга сугышның чын асылын берникадәр күрсәтсә дә, спектакль дәвамында күңелдә байтак сораулар туды. Режиссер бу сәхнә әсәре белән нәрсә әйтергә теләгән, дигән сорауга әле дә булса анык җавап табып булмый. Тамаша үзе әдәби әсәргә нигезләнгән, шул ук вакытта сәхнәдән укылган фронт хатлары аша язучының тормышы, сугышта күргән михнәтләре дә чагылып үтә һәм спектакль автобиографик төсмер ала. Бередә әтисе үлгәч, Рөстәмне кызганып, фронт хатларын язуны үз өстенә алган ананың баласына карата чиксез мәхәббәте дә калку тасвирланган. Баланың әтисен сагынып, юксынып яшәве дә үзәк өзгеч. Миллионлаган халыкны кырган, хәтта Рөстәм кебек дөньяга күзләре дә ачылмаган сабый балаларның гомерен, тынычлыгын алган сугышның нинди зур афәт булуын да әйтергә теләгән авторлар. Яшьләрнең күңеленә ватанпәрвәрлек орлыгы да салырга омтылганнар. Рөстәм Кутуй гомере буе әтисен юксынып яшәгән һәм аның кебек балалар дөньяда хәттин ашкан. Бу спектакль ата белән баланы кавыштырырга бер омтылыш, дияргә дә мөмкин. Әмма бу темаларның кайсы беренчел соң?

Айдар Әхмәдиев һәм Тимур Кулов тәмамланмаган әсәрне үзләренчә язып бетерергә җөрьәт иткән. Гадел Кутуйның повесте Рөстәмнең абага чәчәге ашап күзгә күренмәскә әйләнгәннән соң фронтта фашистларның башына җитүендә өзелеп калса, спектакль авторлары яңа төсмер биреп, кеше җанын кыйганнан соң абага чәчәгенең көче беткәч, Рөстәмнең кабат гап-гади малайга әйләнеп калуын күрсәткән. Хәзер фашист пулясы аны, һичшиксез, эзләп табачак. Бер җинаять икенче җинаятьне китереп чыгара, дип әйтергә теләүләреме бу? Һәр адымыбыз, хәтта золымга каршы кылынган золымыбыз өчен дә җавап тотарга кирәк булачакмы? Бу мәгънәне ананың ахырдан яңгыраган сүзләре дә көчәйтеп җибәрә: «Бер нәрсәгә карамыйча кешеләрне ярат, улым. Сугышлар бетәр, иң мөһиме, кешеләклегеңне югалтма», – ди ул. Югарыда әйтеп үтелгән темалар барысы да гаять әһәмиятле булса да, сәхнәләштерүчеләр аларның кайсына ныграк басым ясарга белмичә һәм шарж-персонажлар белән мавыгып, өч каен арасында адашкандай, югалып калганнар сыман.

Ирексездән Казанның рус яшь тамашачы театрында В.Богомолов әсәре буенча куелган «Иваново детство» спектакле искә төшә. Анда да гаиләсен сугышта югалткан һәм партизаннарга кушылып фашистлардан үч алырга теләүче бала язмышы сурәтләнә. Партизан землянкасын билгеләгән ярым-караңгы сәхнә, спектакль дәвам иткән ике сәгать буе залда урнашкан тынлык, актерларның ишетелер-ишетелмәс сөйләүләре әле дә күңелдән китми. Сугышны ялган пафостан арындырып, тирән уйга этәргән «Иваново детство»ны карагач күңелгә икеле-микеле уйларга урын калмаган иде. «Рөстәм маҗаралары» бөтенләй башка. Бу очракта сәхнәдәге тоташ караңгылыкны ничек аңларга? Тылсымга ышанып, әбисе әкиятен тыңлаганнан соң, урманга серле абага эзләп киткән сабый баланың күңеле шулай тоташ караңгы төсләр аша тасвирланырга тиеш идеме? Ни өчен Рөстәмнең, сабыйлыгын җуеп, үтерүче җанварга әйләнүе сизелми кала, күңелдәге бу күчеш ким дигәндә сәхнәдәге төсләр аша чагылдырылырга тиеш иде ләбаса. Мең елга бер тапкыр җиде төн уртасында чәчәк аткан абаганы тамашачылар юньләп абайлап та өлгермәде булса кирәк. Бу мизгелдә бөтен сәхнә сихри нурга күмелергә тиеш түгел идемени? Ленин бюстына парик менеп кунаклый, патефон үзеннән үзе бер кабына, бер сүнә, өстәлдәге чынаяк аяклангандай шуышып йөрийөрүен, әмма фантастик-хыялый повестька нигезләнгән бу спектакльнең тышкы сурәте барыбер гап-гади көнкүреш сәхнә әсәрен хәтерләтә. Шул сорауларны бергә җыйгач, «Рөстәм маҗаралары» ничә яшьтәге тамашачыга исәпләп куелган?» дигән тагын бер зур һәм мөһим сорау туа.

Сугыш кебек катлаулы темалар турында балалар белән ачык-аңлаешлы сөйләшә белмәвебез аркасында илдә рәхимсезлек пропагандасына иярәләр дә инде алар. Авыр нәрсәләрне гади итеп әйтеп бирү исә осталык сорый. Бармы бездә сугыш турында ачык-аңлаешлы балалар спектакльләре? Бу юлы режиссер максатына ирештеме, әллә бала күңеле тагын күләгәдә калдымы?

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

● Артистлар А.Гайзуллина, Б.Гатауллин, инсценировка авторы А.Әхмәдиев, композитор М.Хәйруллина.

Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кульязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк, г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмахананең адресы:
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2
E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта:
www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга.
Бу санның чыгу көне 23.12.2022

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2630 данә

Заказ 2784

16+